# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

**6** нчы сыйныф

МЕТОДИК ӘСБАП

Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында
(татар телен өйрәнүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

КАЗАН
«МӘГАРИФ — ВАКЫТ» НӘШРИЯТЫ
2014

УДК 373.167.1:821.512.145*01
ББК 84(2Рос=Тат)я71
М85

**Мотыйгуллина, Ә.Р.**

М85 Татар әдәбияты : рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен методик әсбап. 6 нчы с-ф. / Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов, Э.Х. Гыйзәтуллина, Ә.З. Мифтахетдинова. — Казан : «Мәгариф — Вакыт» нәшр., 2014. — 175 б.

© «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2014
© Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов,
Э.Х. Гыйзәтуллина, Ә.З. Мифтахетдинова, 2014

# К Е Р Е Ш

Күпмилләтле мохиттә татар әдәбиятын укыту махсус методик эзләнүләр таләп итә. Аның нигезләрен рус телле аудиториядә татар теле һәм әдәбиятын укытуның милли, дидактик, психологик, әдәби, культурологик, лингвистик үзенчәлекләрен өйрәнү тәшкил итә. Татар әдәбияты дәресләре Нигъмәтуллина Р.Р., Хәйдәрова Р.З., Фәтхуллова К.С. тарафыннан төзелгән татар теле дәреслекләре белән параллель рәвештә укытыла. Шуңа күрә татар әдәбиятын укыту өчен татар теле дәресләрендәге грамматик минимумны, телнең лексик-синтаксик составын белү таләп ителә.

Рус телле аудиториянең аерым үзенчәлекле якларына да тукталу сорала. Гомумилек төрле милләт халыкларында очрый торган образлар, детальләрдә чагылыш таба. Әйтик, мифик образлар грекларда да, русларда да, мариларда да, чувашларда да, татарларда да бар. Әмма һәрбер халык үз милли бизәкләренә өстенлек бирә. Аларны тел чаралары ярдәмендә, төрле калыпларга салып, буыннан-буынга тапшырып килә. Татар әдәбияты дәреслекләрен төзү барышында, күптөрле халыкларның милли табышлары, халыкчан образлары ачыкланды, аларны чагыштырма планда өйрәнү өчен нигез салынды.

Күпмилләтле мохиттә татар әдәбияты укытуның нигезендә мәдәният ара багланышлар технологиясе ята. Бу технологиянең асыл мәгънәсен рус методисты М.В.Черкезова фикерендә очратабыз: «Родная литература, как и родная культура в целом, является основным средоточием духовного опыта народа, формирует мировоззрение, духовно-нравственные представления учащихся, эстетический вкус». Мәдәният ара багланышлар технологиясенең

асылында милли-мәдәни нигездә уку-укыту системасын булдыру ята. Шулай булгач, күпмилләтле мохиттә татар әдәбиятын укытуда төрле методларның синтезы кулланыла ала. Аларның бердәм тормышка ашырылуы мәдәниятара бәйләнешләргә корылып, чагыштырма һәм концептлар методларына таянып укытуга нигезләнә.

Татар әдәбиятын укытканда рус әдәбияты белән чагыштырма анализга таянуга педагогика фәннәре докторы Р.Ф. Мөхәммәтшина игътибар итә, аерым алганда, татар һәм рус халык әкиятләрен, аерым әдипләр иҗатын чагыштырма-типологик планда өйрәнүнең фәнни-теоретик нигезләрен ача. Шул рәвешле, ул татар һәм рус әдәбияты дәресләрендә мәдәният ара бәйләнешләр технологиясенә корылган дәресләрнең методологик юнәлешләрен билгели.

Күпмилләтле мохиттә мәдәният ара бәйләнешләр корылган берничә юнәлеш алгы планга чыга: а) татар фольклорын Россия халыкларының авыз иҗаты җәүһәрләре белән чагыштырып өйрәнү (татар-башкорт, татар-рус, татар-чуваш һ.б.); ә) әдәби әсәрләрдән һәм фольклордан мәдәният-сәнгать, төрле халыкларның яшәү рәвеше турындагы өзекләрне сайлап алу һәм бәяләү; б) әдәби әсәрләрнең теленә бәя бирү аша халыкларның милли-мәдәни байлыгын чагыштыру.

Күреп үткәнебезчә, әдәби белем бирү системасы мәдәният белән тыгыз бәйләнештә яши. Әдәбият фәне мәдәниятнең нигезен тәшкил иткән сәнгатьнең бер төре булып торуын да истә тотсак, әдәби әсәрне мәдәни аспектта бәяләү, шәрехләү үзен аклый.

## Күпмилләтле мохиттә әдәбият укытуның дидактик нигезләре

Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелгән татар әдәбияты дәреслекләре барлык фәннәрне өйрәнү барышындагы фундаменталь төшкә *(фундаментальное ядро)*, универсаль уку гамәлләренә нигезләнә, укучыларның яшь һәм әдәби үсеш дәрәҗәсен исәпкә ала. Укыту һәм тәрбиянең гомуми нәтиҗәләре иҗтимагый, шәхси, танып белү һәм коммуникатив үсешне тәэмин итеп, укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен үстереп, дөньяны танып белүгә әзерләп, хезмәттәшлеккә, үзлегеннән белем алуга, камиллеккә омтылучы шәхес тәрбияләүгә барып тоташа. Аерым алганда, уку-укытуга системалы-гамәли якын килү нәтиҗәсендә, укучыларның **иҗтимагый** үсешенә (халыкның

рухи кыйммәтләрен аңлаучы, үстерүче Россия гражданины тәрбияләү); **шәхси** үсешенә (үзлегеннән белем алырга, иҗади сәләте үскән, компетентлы, үзаңы үскән, үзенең гражданлык карашларын ачыктан-ачык белдерергә сәләтле, үз-үзенә тәнкыйди караштa торган, тормыш авырлыкларына каршы торырлык шәхес тәрбияләү); **танып белү** эшчәнлеген үстерүгә (фәнни дөнья сурәтен аңлаучы, үзенең танып белү һәм интеллектуаль эшчәнлеге белән идарә итә ала торган, уку, белем алу чараларын күзаллый торган, репрезентатив, символик, логик, иҗади фикерләү сәләте үскән, рефлексиягә сәләтле укучы тәрбияләү); **коммуникатив** үсешкә (аралашу компетенциясе үскән, тыңларга, диалогта, гомуми сөйләшүдә катнаша алырлык, туган телен, чит телне камил белүче кеше тәрбияләү) басым ясала. Шул ук гамәлләрне тормышка ашыру барышында, яшүсмерләрнең яшь үзенчәлекләре дә игътибарга алына.

Күпмилләтле мохиттә гомуми әдәби белем бирү барышында универсаль уку гамәлләре *(алга таба — УУГ)* дүрт блокка бүлеп каралды. Алар арасында **шәхси** УУГ — тормышчан, шәхескә юнәлтелгән, һөнәри юнәлештә үз юлын табуга, кешенең эчке потенциалын рациональ файдалана белүенә бәйле блок. **Регулятив** уку гамәлләре шәхес тәрбияләүдә планлаштырырга өйрәтү, фаразлау, коррекция, бәяләү кебек якларны үзәккә ала. **Танып белү** гамәлен алгы планга чыгарган блокта логик, проблеманы кую һәм чишүгә юнәлтелгән, тамга-символик якны иңләгән гомумуку гамәлләренә игътибар ителә. **Коммуникатив** УУГ кешеләр язмышына битараф булмауны, кешеләргә ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияләүне, иҗтимагый компетентлыкны үз эченә ала.

Универсаль уку гамәлләрен рус телле балаларга татар әдәбиятын укыту барышында куллану нәтиҗәсендә, укучыларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтү юнәлеше көчәйде (мәсәлән, өй эше бирү — берничә вариантта).

Шул рәвешле, татар әдәбиятын өйрәнүнең **максаты** да ачыклана: туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес (гражданин) тәрбияләү.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

• Татарстан төбәгендә яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;

• татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияты, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма-типологик аспектта бирү;

• татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;

• татар әдипләре, сәнгать әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны танырга, иҗатларын аңларга, башка халыкларның сүз сәнгатен, культурасын үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;

• татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү.

Әлеге максат һәм бурычларга ирешү өчен, без түбәндәге принципларны истә тотарга тиеш. Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар әдәбиятының асылын төшендерү укытучының сүз сәнгате серләрен яхшы белүен, иҗади эшләү күнекмәләре булуын таләп итә. Мәктәп укучысына сүз сәнгатенең серләрен ачуда **эстетик принцип** (укытучының матурлыкны күрә һәм башкаларны да шуңа өйрәтә алуы), **эзлеклелек** (укучы алган белемнең тулыланып, баеп баруы), **әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнү** (татар телендә язылган әсәрләрдә әдәби образларны ачу үзенчәлекләре, татар теленең матурлыгын күрергә өйрәтү), күләме ягыннан кечкенә булган әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт булдыру, ягъни **психологик принцип** (мәктәп баласының яшь үзенчәлекләрен, әдәби әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып эш итү) ярдәмгә килә. Аерым игътибар **коммуникативлык принцибына** бирелә. Бу принципның өстенлеге рус телендә сөйләшүче укучыларның әдәби әсәр аша татар теленең серләренә тирәнрәк төшенүләре, матур әдәбият әсәре хакында сорауларга нигезләнеп сөйли белүе, үз фикерләрен ачык әйтә алуы, әдәби әсәрнең аралашу чарасына әверелүе белән дә бәйле. Укучыларның әдәби әсәр-не кабул итү һәм әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, **дифференциацияләү** (аерым төркемнәргә аерып, бүлеп эшләү) һәм **интеграцияләү** (татар теле һәм рус әдәбияты дәресләрендә үзләштерелгән теоретик белемнәрне һәм гамәли эш күнекмәләрен файдалану) дә үзәккә алына.

## 6 нчы сыйныф өчен «Татар әдәбияты» фәненнән укыту-методик комплекты (УМК)

Төп мәктәп системасында 6 нчы сыйныф әһәмиятле урын алып тора. Бу сыйныф балаларының яшь һәм әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән УМК үз эченә дәреслекне, укучы өчен мөстәкыйль эш дәфтәрен, укытучылар өчен методик әсбапны ала.

Дәреслек ике кисәктән тора. Укучыларның белем-күнекмәләрен бәяләп бару өчен, һәр кисәк тә дүртәр модульгә бүлеп төзелгән. Һәр модуль бөтен кисәкнең өлешләрен хәтерләтә. Модульгә салынган мәгълүмат та, дәреслек үзе дә хронологик нигезгә корыла. Шул ук вакытта модульләр эчендә тематик-хронологик принцип та саклана.

Һәр модуль укучыларның әдәбияттан мәгълүматлылык үсеш дәрәҗәсен үстерүне, эрудициясен киңәйтүне, әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләп баруны, теоретик төшенчәләрне үзләштереп, сорау-биремнәрне үтәгәндә файдалана алуны күздә тотып урнаштырылган. Дәреслектә модульләр арасындагы бәй-ләнешләр сорау-биремнәр һәм контроль тестлар аша гамәлгә куела. Шулай итеп, дәреслекне әдәби-теоретик төшенчәләр сүзлекчәсе, фразеологик сүзлекчә кебек белешмәләр тәгәлләп куя.

«Үрнәк программа»га кертелгән (төзүчеләре: Ф.Х. Җәүһәрова, К.С. Фәтхуллова) әдәби әсәрләр минимумы (7 әсәр) дәреслекнең ике кисәгенә дә бүлеп салынды. Алар түбәндәгеләр:

1. Г.Тукайның «Шүрәле» әкият-поэмасы, «Туган авыл» шигыре;
2. М.Гафуриның «Ана» шигыре;
3. Һ.Такташның «Мокамай» поэмасы;
4. М.Җәлилнең «Чәчәкләр» шигыре;
5. Ә.Еникинең «Туган туфрак» хикәясе;
6. Г.Бәшировның «Туган җирем — яшел бишек» повестеннан «Сабантуй» өзеге.

Дәреслек, күпмилләтле мохиттә татар әдәбиятын укыту юнәлешендә «Үрнәк программа»га һәм «Әдәбият укыту программасы»на таянып (авторлык), беренче тапкыр төзелде. Аның нигезендә татар әдәбияты, мәдәнияте һәм татар халык фольклоры үреп бирелә, әдәби-теоретик төшенчәләр тәкъдим ителә. Шулай ук, татар әдәбиятын рус һәм Россиянең башка халыклары әдәбияты һәм мәдәнияте яссылыгында өйрәнү өчен, аларның да фольклор үрнәкләре һәм идея-эстетик яктан камил тәрҗемә әсәрләре салынды.

Халык авыз иҗатының язма әдәбият белән бәйләнешен чагылдыру өчен, әдәби әсәрләрдән өзекләр урнаштырылды. Мәсәлән, мифлар турында төшенчә бирелә, миф үрнәкләре китерелә. Шунда ук, әдәбиятның фольклоризмнар белән баетылуын раслап, Рабит Батулланың «Албасты» әсәреннән өзек урнаштырыла.

Бу сыйныфта балалар халык авыз иҗаты өлкәсендә белемнәрен тирәнәйтеп, җырлар да өйрәнәләр. «Халык җырлары» исеме астында бирелгән блокта укучылар җыр төрләре (йола җырлары, лирик җырлар, тарихи җырлар, уен җырлары, такмак-такмазалар) белән генә танышып калмыйлар, теоретик төшенчәне аңлату белән беррәттән, мисаллар ярдәмендә исбатлап барыла. Әйтик, йола җырлары темасы «Сөмбелә» дигән татар, «Чуклеме» дигән чуваш халык йоласы белән тулыландырыла. Укучылар тарихи җырларга мисал итеп «Көзге ачы җилләрдә» китерелә, уен җырларыннан — «Кәрия-Зәкәрия», такмак-такмазалардан «Әпипә» белән танышалар.

Халыкның зирәклеген, тапкырлыгын күрсәткән афористик жанрлардан исәпләнгән мәкаль һәм әйтемнәр башка сыйныфларда аерым мисаллар рәвешендә генә телгә алынып барылган булса, 6 нчы сыйныфта махсус теоретик нигездә өйрәнелә.

Алга таба укучылар танылган әдипләр, аларның бер яки берничә әсәре белән таныша, алар турында фикер әйтергә өйрәнә. Әсәр ахырына төзеп салынган сорауларга җавап биреп, биремнәр үтәп, балалар сүз сәнгате казанышларын күрергә, танырга өйрәнәләр, башка телдә анализ ясау күнекмәләрен алалар. 6 нчы сыйныфта 37 татар язучысының иҗаты, аларның бердән өчкә кадәр әдәби әсәре өйрәнелә, башка халыклар әдәбиятыннан 4 үрнәк тәкъдим ителә.

6 нчы сыйныфта да 5 нче сыйныфта башланган, әдәбиятны сәнгать белән бәйләп бару принцибы саклана. Төрле сәнгать төрләре (әдәбият һәм рәсем, музыка, бию һ.б.) арасындагы бәйләнешне күрү, үзләштерү балаларның дөньяга карашын киңәйтә, матурлыкны күрергә, бәяләргә өйрәтә. Аларның бер нигезгә корылган милли-мәдәни юнәлеш икәнлеге ачыклана. Шул рәвешле, 6 нчы сыйныфта рус телле укучы 3 композитор (Алмаз Монасыйпов, Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшев), бер җырчы (Рәшит Ваһапов), бер рәссам (Лотфулла Фәттахов) иҗаты белән таныша; 3 музей (К.Насыйри, М.Җәлил, С.Сәйдәшев) һәм балалар матбугат органы булган «Сабантуй» журналы хакында мәгълүмат ала. Шулар арасында композитор Салих

Сәйдәшев күпкырлы ачыла: тормыш юлы һәм иҗаты турында Мәгъсүм Латыйфуллинның әдәби әсәре белән танышу күздә тотыла; С.Сәйдәшевкә, аңа куелган һәйкәл күрсәтелеп, мәгълүмат бирелә; бөек композитор исемен йөрткән Зур концерт залы турында белешмә бирелә; С.Сәйдәшев музеена сәяхәт ясала.

Дәреслекне үзләштерү барышында, укучыларның әдәбият белеме белән бәйле теоретик белеме дә үстерелә. Бу сыйныфта әдәби әсәрнең жанрына, әдәби эшләнешенә караган 16 әдәбитеоретик төшенчә үзләштерү күздә тотыла.

Һәр модульның (блок) атамасы аның эчтәлегенә тәңгәл килә. Блок системасы төзек: ул үз эчендә я фольклор материалы белән әдәби әсәрне бергә бәйләүгә, я әдәби әсәрнең сәнгатьнең берәр төре белән бәйләнешенә игътибар итүгә йөз тота. Шул ук материалларга бәйләп, әдәби-теоретик төшенчәләр дә биреп барыла.

Программага салынган мәгълүмат, минимакс принцибын исәпкә алып (материал озак үзләштерүче укучыга да, көчле укучыга да җитәрлек), 70 сәгатькә исәпләнгән. Әгәр әдәбият дәресләре атнага бер сәгать кенә, укытучы үзе сайлап ала. Әдәби әсәрләрне үзләштерү ике юнәлештә бара: төп уку өчен һәм сыйныфтан тыш уку өчен тәкъдим ителгән әсәрләр. Төп уку өчен бирелгән әсәрләр укучы тарафыннан үзләштерелергә, сорау һәм биремнәр, теоретик төшенчә белән бәйләп хәтердә калдырылырга тиеш.

6 нчы сыйныф дәреслеге белән эшләү өчен, укытучыларга әлеге методик әсбап тәкъдим ителә. Ул керештән; максат, бурычлар (шәхси, метапредмет, предмет), җиһазлау, уку мәсьәләсен кую, уку мәсьәләсен чишү, көтелгән нәтиҗәләр дә урын алган үрнәк дәрес эшкәртмәләре салынган төп өлештән; кушымта булып бара торган «Календарь-тематик план»нан, укучыларның белем-күнекмәләрен бәяләү өчен ике варианттагы тест биремнәреннән тора.

Сыйныфтан тыш укуга (өстәмә әдәбият) урнаштырылган әсәрләр, җыр текстлары, картиналар укытучы эшен җиңеләйтү өчен бирелә. Аларны вакыт иркен чакта яки укучыларның мөмкинлекләре югары булганда файдаланырга мөмкин. Шул ук вакытта аларны каникул вакытында өйрәнергә бирергә дә була.

6 нчы сыйныф укучылары өчен төзелгән УМКның тагын бер элементы — укучы мөстәкыйль рәвештә үзләштерә, укытучы консультациясе ярдәмендә башкарып-үтәп чыга алырлык биремнәр салынган «Эш дәфтәре». Анда предметара бәйләнешкә игътибар

ителәә, укучыларга белем биргәндә, индивидуаль һәм дифференциаль якын килүне күздә тоткан биремнәр системасы тәкъдим ителә. Шуңа күрә өй эшләрен бирү түбәндәге юнәлешләрдә бара: а) репродуктив (үрнәк буенча эш); ә) эвристик (ярымиҗади); б) продуктив (иҗади).

Әлеге УМКны төзү барышында, рус телендә сөйләшүче балалар үзләштерә алырлык дип исәпләнгән, татар әдәбиятындагы иң гүзәл, бала күңеленә матурлык орлыклары сала торган әдәби әсәр үрнәкләре сайлау белән беррәттән, бала фантазиясе, аны әйләндереп алган дөнья белән бәйләнешле текстлар сайланды. Укучы әдәби әсәрне укып, эчтәлеген сөйләп, андагы җөмлә конструкцияләрен хәтерендә калдырып кына бармас, ул әдәби әсәрнең корылышын аңларга, сәнгатьчә матурлык тудыру чараларының да кайберләрен күреп таный белергә өйрәнер дип ышанабыз.

## УМК эчтәлеген үзләштерү өчен методик киңәшләр

Әлеге методик әсбап татар әдәбияты укытучысына методик ярдәм күрсәтү максатыннан төзелде. Рус телле балаларга махсус төзелгән дәреслекләр белән эшләү вакытында, әдәбият укыту алымнары, чаралары, ысуллары, технологияләре дә үзгәреш кичерә.

Балаларга татар әдәбиятын укыту барышында файдаланылган методлар арасында өстенлек иҗади уку (сәнгатьле уку), репродуктив (Н.И.Кудряшев классификациясе) методларга бирелә. Бу ысулларга таяну нәтиҗәсендә, укучыларның әдәби әсәр текстын дөрес интонация белән укуы, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыруы, укытучы укыганны үзләштерүе, татар мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында укытучы җиткергән мәгълүматларны тиешле дәрәҗәдә үзләштереп бару күздә тотыла. Балаларның үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен, эзләнү методыннан файдалану уңышлы.

Төрле ысулларга мөрәҗәгать итү нәтиҗәсендә, рус телле аудиториядә әдәбият дәресләрендә киң кулланылышта йөрергә тиешле түбәндәге алымнарны күрсәтик: укытучы сүзе (сөйләве), сәнгатьле уку, портрет белән эшләү, укучы сөйләве, кыскача эчтәлек сөйләү, бер әсәрне икенче әсәр белән чагыштыру, әдәби әсәрдәге вакыйгаларны тормыш-көнкүреш белән бәйләү һ.б. Шуның белән беррәттән метод һәм алымнарны төрләндерү, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, аларның әдәби

үсеш үзенчәлекләренә таяну, башка халыклар әдәбиятын кабул итәргә һәм чагыштырырга өйрәтү әдәбият дәресләренең нәтиҗәлелеген күтәрүгә хезмәт итә.

## Рус телле балаларга әдәби әсәрне укыту, өйрәтү юллары

### 1. Әсәрне уку

PIRLS һәм PISA дип аталган халыкара тикшеренүләр нәтиҗәләренә караганда, башлангыч мәктәпне тәмамлаган Россия балалары — укуда югары нәтиҗәләр, ә төп урта белемне алган укучылар түбән нәтиҗәләр күрсәтә. Чөнки, 5 нче сыйныфтан башлап, уку техникасына да, укучы укуына да игътибар кими. Укуны башлангыч мәктәп программасы материалы гына дип исәпләп, бары тик анализ эшенә генә күчелә. Шул рәвешле, уку гамәленә аерым игътибар кими барып, бөтенләй юкка чыга, бала аерым өзекләрне бернинди мөнәсәбәтсез генә укып чыга һәм берни дә аңламый.

Уку проблемасына физиологлар да игътибар итә башлады. Алар начар укуны, аның нәтиҗәсезлеге белән бәйләп, текстка салынган мәгънәне аңламауга, андагы төп фикерне аерып чыгармауга, эчтәлек сөйләүнең нәтиҗәсезлегенә, эзлекле булмавына, тексттагы фикерне шәхси фикер белән бәйли алмауга игътибар иттеләр. Академик М.М.Безруких җитәкчелегендәге тикшеренүчеләр, күзәтүләренә һәм экспериментларына нигезләнеп, уку күнекмәсе формалаштыру этапларын аерып чыгарып, түбәндәге нәтиҗәләрне тәкъдим иттеләр:

| **Уку күнекмәсе барлыкка килү дәрәҗәләре** | **Күнекмәләр системасы** |
|---|---|
| Элементар уку дәрәҗәсе (уку техникасы) | • Сүзләрне хатасыз уку.<br>• Сүзләрнең мәгънәсен аңлау.<br>• Җөмлә эчендәге сүзләр бәйләнешен һәм җөмләне аңлау. |
| Кычкырып грамоталы уку дәрәҗәсе | • Текстның гомуми эчтәлеген аңлау.<br>• Тексттагы төп фикерне аерып чыгара алу.<br>• Тексттагы вакыйгаларның эзлеклелеген аңлау (текстның логикасы).<br>• Текстган соралган мәгълүматны таба алу.<br>• Текстның төп эчтәлеген сөйли белү. |

| | |
|---|---|
| Үзлектән грамоталы уку дәрәҗәсе | • Текстның гомуми эчтәлеген аңлау.<br>• Тексттагы төп фикерне аерып чыгара алу.<br>• Тексттагы вакыйгаларның эзлеклелеген аңлау (текстның логикасы).<br>• Тексттан соралган мәгълүматны таба белү.<br>• Текстның төп эчтәлеген сөйли белү.<br>• Мәгълүматның эзлеклелеген аңлау, шәрехли алу.<br>• Текстның эчтәлеген рефлексияләү.<br>• Текстның формасын рефлексияләү.<br>• Аңлау һәм текстның кыскача эчтәлеген сөйләү (шәхси күзаллау, фикерләү). |

Рус телле балаларга татар теле чит тел булуын исәпкә алып, әдәби әсәрләрне укыганда, **танышу өчен уку** (*ознокомительное чтение*), **кирәкле мәгълүматны табу өчен уку** (*просмотровое чтение*) төрләре беренче урында тора. Бу вакытта зур күләмле әсәрләрне сүзгә-сүз тәрҗемә итү кирәк түгел, укучылар күп материал арасыннан иң мөһимен аңларга, аерып алырга өйрәнәләр.

Шулай ук әдәби әсәрнең матурлыгын күрергә, эчтәлекне аңларга ярдәм итә торган түбәндәге уку төрләрен аерып чыгарырга мөмкин:

• рациональ һәм эмоциональ;

• функциональ һәм эстетик;

• репродуктив һәм иҗади;

• эш вакытындагы һәм ял итү вакытындагы (ирекле, гедонистик);

• тиз һәм акрын;

• кычкырып уку яки эчтән, ярымтавыш белән уку;

• үзе генә яки чылбыр буенча, рольләргә бүлеп;

• төрле интонация төсмерләре өстәп уку (бер үк шигырьне, истә калдыру өчен, күп тапкыр уку ялыктырмасынга).

Әйтелгәннәргә өстәп, укытучыларның еш мөрәҗәгать итә торган уку төре — экраннан укуга да игътибар итү мөһим. Бу төр укуның түбәндәге уңай якларын аерып күрсәтергә мөмкин: 1) укучы текстны үзе дә яза ала; 2) экранның йөрешен программа белән көйләргә була; 3) электрон текстның төзелеше гипертекст рәвешендә бирелә, ул укучыга уку эзлеклелеген сай-

лау мөмкинлеге тудыра; 4) экрандагы текст хәрефләр, авазлар символы белән генә тәкъдим ителми, ә башка билгеләр (символ, иллюстрация, видиоклип һ.б.) ярдәмендә дә булырга мөмкин.

Әсәрне аңлауны тикшерү традицион укытуда еш кына эчтәлек сөйләүгә кайтып кала. Рус телле балаларга татар әдәбиятын укытканда, бу мәсьәләгә башкача караш булырга тиеш. Күләмле әдәби әсәрнең эчтәлеген сөйләү бары укучының бу әсәр турында гади җөмләләр белән төзелгән үз фикере формасында булу мөһим. Моңа ирешү өчен, дәреслектә дә, эш дәфтәрендә дә гади җөмләләрне текст эчтәлеге белән чагыштыру, дөрес тәртиптә кую, фикернең кайсы геройныкы булуын белү, әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү кебек биремнәр бар. Шундый ук гади җөмләләр белән, анализ элементларын кулланып, әсәрне тикшергәч, укучыларга бу әсәр турында үз сүзләре белән кыскача фикер әйтү авыр булмас.

### 2. Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү

Рус мәктәбендә белем алучы укучылар рус әдәбияты дәресләрендә тирән белем ала, аңлаешлы әдәби әсәрләр белән таныша һәм анлары анализларга, бәяләргә өйрәнә. Укучылар рус әдәбияты дәресләрендә алган теоретик белемнәрне татар әдәбияты дәресләрендә дә уңышлы гына файдалана ала. Шул үзенчәлекне истә тотып, татар әдәбияты дәреслекләренең 5 нче сыйныфтан башлап, һәр сыйныфта рус әдәбияты дәресендәге теоретик төшенчәләр кабатланып барыла. Әдәби-теоретик төшенчәләрне бирүнең эчтәлеге дә үзгәрә: төшенчәнең татарча аталышы гына истә калдырыла, ә аңлатма рус әдәбияты дәресендә бирелгәнчә саклана. Укучылар телне тирәнрәк үзләштергән очракта, укытучы бу теоретик үзенчәлекләрнең әсәрдә барлыгына игътибарны юнәлтә яки аны яхшы әзерлекле балаларга өстәмә эш итеп тәкъдим итә.

Кайбер теоретик төшенчеләр методик әсбапта тулыландырып бирелде.

### 3. Язучыларның һәм сәнгать әһеләренең биографиясен өйрәнү

Әдәбият дәресләрендә рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдипләре турында мәгълүмат бирелә башлый. Әдипләрнең тормыш һәм иҗат сәхифәләре белән таныштыруны түбәндәге дүрт төргә бүлеп карый алабыз:

1) Тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнгәндә, әдип үткән гомер юлы турында сөйләнелә һәм иҗатының барлык якларын иңләгән мәгълүмат бирелә, ләкин укучылардан бу мәгълүматны тулысынча истә калдыру, сөйләү таләп ителми.

2) Биографик белешмәне күз уңында тотканда, әдипнең тормыш һәм иҗат юлындагы аерым сәхифәләре белән таныштырыла. Әдипкә бәя бирү истәлекләргә таянуга, иҗатның аерым якларына бәя бирүгә юнәлтелергә мөмкин.

3) Язучы яки шагыйрьнең язмышы дигән вакытта, иҗат эшчәнлегенә бик кыска гына бәя бирелә, ә аның ил күләмендә һәм әдәбият тарихында тоткан урынын ачыклау алгы планга чыга.

4) Әдип иҗатының бер генә юнәлешенә игътибар итү очраклары да бар. Алар, мәсәлән, «Фәнис Яруллин — шагыйрь» рәвешендә тәкъдим ителә. Шуңа күрә әдип эшчәнлегенең бары тик бер ягын гына аерып чыгарып өйрәнүне күздә тотыла.

Әдәбият дәресләренең төп максаты — балаларны әдәби әсәр укырга тарту, аның турында фикер әйтергә өйрәтү икәнлеген исәпкә алып, әдәби текстны сайлау принципларына һәм аларның дәреслекләрдә бирелү рәвешенә дә тукталыйк. Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар телендә язылган матур әдәбият әсәрләрен үзләштерү эшенең авыр булуын истә тотып, әдәби әсәрләрдән (хәтта шигырьләрдән дә) өзекләр генә тәкъдим итү уңышлы. Ләкин дәреслек төзегән вакытта, әдәби әсәр турындагы тулы мәгълүматны (аңлатма рәвешендә генә булса да) биреп бару күздә тотыла.

### 4. Әдәби әсәрне анализлау

6 нчы сыйныфта рус телендә сөйләшүче балаларның тел белү дә-рәҗәсе әлегә түбән булу сәбәпле, әдәби әсәрне анализлау эше дә катлаулы булачак. Шуны истә тотып, дәреслек төзегән вакытта баланың әсәргә шәхси мөнәсәбәтен ачарлык, аның хисләренә йогынты ясаган якларны күрсәтерлек сорау һәм биремнәр тәкъдим ителде. Әлеге биремнәр ярдәмендә, әдәби анализ элементлары кертеп, эчтәлек буенча фикер алышу оештырыла. Бу вакытта авырсынган укучылар фикерләрен рус телендә әйтергә мөмкин, ләкин укытучы алга таба ул фикерне татарчага тәрҗемә иттерә.

### 5. Язма сөйләм

Әдәбият дәресләрендә балаларны текст укырга, аны сөйләүгә генә тарту җитми. Һәр дәрестә язу эшенә игътибар итәргә кирәк

(эш дәфтәрендә — шундый биремнәр). Бу бигрәк тә сөйләм үстерү дәресләренең дәвамы булып торса яхшы, чөнки балаларның эзлекле фикерли белүе күбрәк язма эшләр башкарганда ачыла.

### 6. Иҗади эш

Рус мәктәбендә укучы рус телле балаларга татар әдәбияты укыту барышында иҗади эшчәнлек төрләренә аерым игътибар итү сорала. Аларның берничә шартын ачыклап китү шарт: беренчедән, укучылар, татар теленнән дә, әдәбияттан да, БДИ тапшырган вакытта, әсәрдән алынган өзек белән очраша, икенчедән, укытучы үзе дә мөстәкыйль әсәр өзекләре сайлый, аларны укучыларга тәкъдим итә, өченчедән, төрле дәрәҗәдә уза торган конкурслар, конференцияләр, олимпиадаларда да шушы юнәлеш алгы планга куела.

Бу юнәлештә дәреслектә һәм эш дәфтәрендә котлау, хат язу, үзләре, туганнары турында язу, әдәби геройга киңәшләр бирү, текстны үзгәртү кебек биремнәр белән бергә проект эшләре дә тәкъдим ителә.

## Әдәбият дәресләренең материаль-техник яктан тәэмин ителеше

Рус телле балалар татар әдәбиятын үзләштерү барышында түбәндәге техник чараларга игътибар итәргә тиеш:

- мультимедия чаралары;
- Интернет ресурслар;
- махсус сайтлар.

## 6 нчы сыйныф укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр

— әдәби әсәрләрне, сүзләрен дөрес әйтеп, йөгерек уку;

— авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;

— әдәби-теоретик төшенчәләрне рус әдәбияты белеме белән тәңгәлләштерү;

— татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;

— авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;

— 6 нчы сыйныф өчен минимумга кергән әсәрләрнең кыскача эчтәлеген, төп геройларын, күтәрелгән проблеманы белү;

— 10—12 татар, рус, чит ил язучысы, шагыйрьләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;

— 3—4 сәнгать әһеленең тормышы, иҗаты турында мәгълүматлы булу;

— Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, концерт залы һ.б.), балалар матбугаты турында хәбәрдар булу;

— төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыра алу;

— төрле халыкларның киң таралган мифларыннан хәбәрдар

## КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Дәрес темасы | Дәрес саны | Төп эчтәлек | Көтелгән нәтиҗә | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | метапредмет | предмет | |
| **Мифлар дөньясыннан — чынбарлыкка** | | | | | | |
| 1 | Халык зур ул, әдип ул, шагыйрь ул... | 1 | Халык авыз иҗаты (әкият, табышмак, мәкаль). | Төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен чагыштырып карау. | Халык авыз иҗатын гомуми күзаллау. | |
| 2 | Һич сине куркытмасыннар шүрәле, җен һәм убыр... | 1 | «Шүрәле», «Шүрәлене ничек алдарга?» мифлары, «миф» төшенчәсе. | Рус, грек һәм татар мифология-сен чагыштыра белү. | Мифлар, мифик геройлар турында төшенчә формалаштыру, миф белән әкиятнең аермасын аңлау. | |
| 3 | Су асты галәмәтләре. | 1 | «Су иясе», «Өй иясе», «Дедал белән Икар» мифлары. | Рус, грек һәм татар мифологиясен чагыштыра белү. | Мифик геройлар турында төшенчә формалаштыруны дәвам итү, миф белән әкиятнең аермасын аңлау. | |

булу, берничә мисал китерә белү;

— 5 мәкаль, 5 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;

— мәкаль белән әйтем, миф белән әкият, халык җыры белән автор җыры арасындагы аерманы белү;

— төрле авторларның 2—3 шигырен яттан сөйли белү;

— сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;

— төрле темаларга проект эше яклау;

— әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

## 6 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН

| | | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Контроль эш төрләре | Үткәрү вакыты план / факт |
|---|---|---|---|---|
| | шәхескә кагылышлы | | | |
| | | | | |
| | Халык авыз иҗаты әсәрләре белән кызыксыну булдыру, сөйләмне алар ярдәмендә баету мөмкинлеген аңлау. | «Халык авыз иҗаты» схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр, рус халык авыз иҗаты белән чагыштырып, мисаллар китерү. | | |
| | Халык авыз иҗаты әсәрләрнә карата кызыксыну уяту. | «Халык авыз иҗаты» схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр, чылбыр буенча уку, чылбыр буенча сөйләү, җөмләләр төзү. | | |
| | Иптәшең белән сөйләшә, башкаларны тыңлый белү — аралашу культурасы тәрбияләү. | Парлап, төркемләп сөйләшү, ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку, сәнгатьле уку, җөмләләр төзү, башка халыкларның мифлары белән чагыштыру. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Мифлар бүген дә онытылмый. | 1 | «Албасты» мифы, Батулланың «Албасты» пьесасы. | Проект әзерләргә өйрәнү. | Язучылар иҗатына мифик геройлар керүе белән таныштыру. | |
| 5 | Әйтем — сүзнең бизәге, мәкаль — сүзнең җиләге. | 1 | Мәкальләр, әйтемнәр. | Татар һәм рус халык мәкальләрен чагыштыру. | Мәкаль һәм әйтем турда теорияне аңлап истә калдыру, аларның аермасын белү, мәкаль, әйтемнәр өйрәнү. | |
| 6 | Нәтиҗә ясарга вакыт. | 1 | Мифлар, мәкальләр, әйтемнәр. | Белгәннәрне кирәк ситуациядә искә төшереп куллана белү. | Миф, мәкаль, әйтем турында теорияне, аларга үрнәкләрне гомумиләштерү, аермаларын таба белү. | |
| **Халык моңнары: җырлата да, елата да...** | | | | | | |
| 7 | Халык җырлары — иң кадерле мирас. | 1 | Халык авыз иҗатында җыр жанры, йола җырлары, Сөмбелә, Чуклеме бәйрәмнәре. | Халкыбызның онытылып бара торган бәйрәмнәре белән таныштыру. | Халык җырлары жанрлары, йола җырлары турында белешмә бирү, Сөмбелә бәйрәмен аңлату. | |
| 8 | Халык җырларында — тарих чагылышы. | 1 | Тарихи җырлар, «Көзге ачы җилләрдә» җыры. | Тарихи вакыйгалар, тарихи шәхесләр белән таныштыру, татар халкының үткәнен, тарихын, язмышын аңлату. | Тарихи җырлар турында белешмә бирү, «Көзге ачы җилләрдә» дигән татар халык җырын өйрәнү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Аралашу культурасы тәрбияләү, экологик тәрбия. | Сорауларга җавап эзләү, ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку, әсәрдә автор әйтергә теләгән фикерне табу, әдәби әсәр турында фикер алышу, проект эшенә әзерлек. | «Табигатьне саклау өчен без нишли алабыз» проекты. | |
| | Халык авыз иҗаты белән кызыксыну уяту, әдәплелек тәрбияләү. | Төркемнәрнең чыгыш ясавы, теоретик материал белән танышу, дәреслек, дәфтәр белән эш, фронталь эш. | | |
| | Халык авыз иҗатына карата кызыксыну уяту, аның кешеләрне тәрбияләүдәге әһәмиятен аңлау. | Монологик сөйләм, мәкаль-әйтемнәрнең башка телдәге эквивалентларын табу, төркемнәрдә сораулар, биремнәр төзү, мөстәкыйль эш. | Тест. | |
| | | | | |
| | Укучыларда халкыбызның йолалары, гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләү. | «Халык авыз иҗаты» схемасы белән эш, ишетеп аңлау, дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү, сүзлек белән эш, җыр тыңлау, өйрәнү. | | |
| | Тарихи җырлар аша чорны, халыкның язмышын аңлау. | Җырлар тыңлау, ишетеп аңлау, яңа сүзләр белән эш, фронталь әңгәмә, дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү — үз фикереңне әйтү, Интернеттан тарихи җырлар турында мәгълүмат табу. | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Уйныйбыз да, җырлыйбыз да. | 1 | Уен җырлары: «Кәрия-Зәкәрия», «Әпипә». | Сәнгать тәрбиясе бирү. | Уен җырлары турында белешмә бирү, «Кәрия-Зәкәрия» уен җырын өйрәнү. | |
| 10 | Шигъриятта — халык көе. | 1 | Г.Тукайның «Туган тел», «Туган авыл» шигырьләре, А.Монасыйпов иҗаты. | Милли үзаңны үстерү, үткәнеңне, тарихны өйрәнү. | Г.Тукайның халык җырлары турындагы хезмәтләре белән танышу, «Туган тел», «Туган авыл» җырларын өйрәнү; А.Монасыйпов турында белү. | |
| 11 | Татарстан Республикасының Дәүләт гимны. | 1 | Татарстан Республикасының Дәүләт гимны. | Дәүләт гимнын тыңлау тәртибен белү. | Дәүләт гимны турында теоретик төшенчә бирү һәм гимнның сүзләрен аңлап истә калдыру. | |
| 12 | Җырсыз кеше — канатсыз кош. | 1 | Халык җырлары, җыр жанрлары, автор җырлары, гимн. | Төрле чыганаклардан кирәкле мәгълүмат таба белү. | Җыр жанрлары, җыр сәнгате турында белемне ныгыту. | |
| **Кадерле син, Кеше туганым!** | | | | | | |
| 13 | Иң кадерле кешеләр. | 1 | Н.Исәнбәтнең «Өч матур сүз» шигыре, «лирик герой» төшенчәсе. | Автор әйтергә теләгән төп фикерне таба, аны тормыш белән бәйли белү. | Язучы Н.Исәнбәт иҗаты белән танышу, «Өч матур сүз» шигыренең эчтәлеген, «лирик герой» төшенчәсен аңлау. | |
| 14 | Ирек кадерлеме? | 1 | М.Гафури иҗаты, «Әтәч белән Сандугач» мәсәле, «сынландыру», «мәсәл». | Татар мәсәлчеләрен рус әдәбиятындагы мәсәлчеләр белән чагыштыра, мөстәкыйль укып, нәтиҗә ясый белү. | Язучы М.Гафури иҗаты, «Әтәч белән Сандугач» мәсәле белән танышу, «сынландыру» төшенчәсен аңлау. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Коллектив белән башкарылган халык җырлары, җыр культурасы белән танышу. | Сәнгатьле уку, чылбыр буенча уку, халык җырына яңа куплет уйлау, җырлы уен өйрәнү, видеоязмада татар биюе карау, милли киемгә орнаментлар ясау. | | |
| | Тукайга хөрмәт, милләтеңә, туган җиреңә, туган телеңә мәхәббәт тәрбияләү. | Бер уен җырын яттан сөйләү, тыңлап аңлау, сәнгатьле уку, фронталь эш, төркемнәрдә эш, аудиоязма тыңлау, дәреслеклек белән эшләү, дәфтәрдә эш, презентация карау. | | |
| | Татарстан Республикасы, аның казанышлары белән горурлану хисләре тәрбияләү. | Фронталь әңгәмә, яңа сүзләр белән танышу, җыр тыңлау, җыр сүзләрен тәрҗемә итү, истә калдыру. | | |
| | Укучыларда җырга, музыкага мәхәббәт тәрбияләү, коллектив башкару, җырлау культурасы үстерү. | Телдән журнал әзерләү, төркемнәрнең чыгыш ясавы, диалогик сөйләм, чылбыр буенча сорау — җавап. | Тест. | |
| | | | | |
| | Әти-әнинең, туган илнең кадере турында аңлау, сөйләм телен үстерү. | Фронталь әңгәмә, язучы турында презентация ясау, карау, шигырьне тыңлап аңлау, сәнгатьле уку, рольләргә бүлеп уку, дәреслек, дәфтәр белән эш. | | |
| | Тормышта ихтыяр көченең, белемнең кирәклеген аңлау. | Биографияне мөстәкыйль укып, сорауларга җавап эзләү, сәнгатьле уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, мәсәлнең моралең табу, рәсемнәр белән эш, дәреслек, дәфтәр белән эш. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Анага бала кадерле, балага ана кадерле. | 1 | М.Гафуриның «Ана» шигыре. | Музыка дәресендә өйрәнгән бишек җырлары яки әниләр турындагы җырларны искә төшереп, әдәбият белән бәйләнешне аңлау. | Язучы М.Гафури иҗаты белән танышуны дәвам итү, «Ана» шигырендә автор фикерен аңлау, сәнгатьле уку. | |
| 16 | Г.Тукайны биргән, җырларда җырланган ямьле Казан арты... | 1 | Г.Тукай иҗаты, «Шүрәле» әкиятпоэмасы. | Географик картадан Тукай туган, яшәгән җирләрне, әкият-поэмадагы «Казан арты» дигән урынны таба белү, аңлау. | Шагыйрь Г.Тукай турында 5 нче сыйныфта өйрәнгәннәрне искә төшерү, тулыландыру, «Шүрәле» әкиятпоэмасының 1 нче өлеше белән танышу. | |
| 17, 18 | Барыбызга да таныш Шүрәле. | 2 | Г.Тукай иҗаты, «Шүрәле» әкиятпоэмасы. | «Аршын» сүзенең мәгънәсен аңлау, кайда кулланылышы турында белү, рәссам Б.Әлменов картинасы белән танышу. | Шагыйрь Г.Тукай биографиясен истә калдыру, «Шүрәле» әкиятпоэмасының 2, 3 нче өлешләре белән таныш булу. | |
| 19 | Дөньяларны «гизгән» Шүрәле. | 1 | Ф.Яруллинның «Шүрәле» балеты. | «Балет», «либретто», «балетмейстер» төшенчәләрен белү. | Г.Тукайның «Шүрәле» әкиятпоэмасына балет язылуы, аның эчтәлеген белү, композитор Ф.Яруллин турында мәгълүматлы булу. | |
| 20, 21 | Чәчәкләр — матурлык һәм үлемсезлек символы. | 2 | М.Җәлил иҗаты, «Чәчәкләр», «Тик булса иде ирек» шигырьләре. | Тарихтан сугыш чоры турында белү. | М.Җәлил биографиясен искә төшерү, сугыш чоры иҗаты белән танышу, «Чәчәкләр» шигырен аңлап уку, «символ», «строфа» төшенчәләре белән танышу. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Әниләргә карата ихтирам тәрбияләү. | Рольләргә бүлеп уку, шигырьне тыңлау, сүзлекчә белән эшләү, сәнгатьле эшләү, парларда яки төркемнәрдә эшләү, яңа материалның таныш әсәрләр белән бәйләнешен табу. | | |
| | Әкият-поэмада сурәтләнгән урман матурлыгы, урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре аша экологик тәрбия бирү. | Презентация карау, төркемнәрдә биремнәр үтәү, әкият-поэманы тыңлау, сүзгә-сүз тәрҗемә итү, ярымтавыш белән уку, сәнгатьле уку, сайлап уку, чылбыр буенча уку, парлап сөйләшү. | | |
| | Экологик тәрбия бирү. | Дәреслек, дәфтәр белән эш, яңа сүзләрне активлаштыру — сүзләр, җөмләләр төзү, рольләргә бүлеп уку, сайлап уку, мультфильм карау. | | |
| | Эстетик тәрбия бирү. | Теоретик төшенчәләр белән танышу, видеоязма карау, композитор биографиясе белән танышу, аның буенча хронологик таблица тутыру, фикер алышу. | | |
| | Туган илне ярату, туган илне саклау — мактаулы икәнен аңлау. | Дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү, шигырьне тыңлап аңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу, шигырьгә анализ ясау. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 22 | Рәхәт булса да торган җир, сагынды-ра туган ил. | 1 | Ә.Еники иҗаты, «Туган туфрак» хикәясе. | Катлаулы текст белән эшләү, иң әһәмиятле-сен таба белергә өйрәнү. | Ә.Еники иҗаты белән танышу, «Туган туфрак» әсәрен укый башлау. | |
| 23—25 | Әби-ба-байлар-ның туган җире оны-кларга кадер-леме? | 3 | Ә.Еники иҗаты, «Туган туфрак» хикәясе, «символик образ», төшенчәсе | План төзи белү. | «Туган туфрак» әсәрен уку, аңлау, Ә.Еники турын-да мәгълүматлы булу, әсәрдән өйрәнгән троплар-ны, символик образларны таба белү. | |
| 26 | Бүлекне кабат-лау, йомгак-лау. | 1 | Н.Исәнбәт, М.Гафури, Г.Тукай, М.Җәлил, Ә.Еники иҗатлары. | Белгәннәрне кирәкле ситуациядә кулланып, тестка җавап бирә белү. | Бүлектә укылган әсәрләрне истә калдыру. | |
| 27 | Энҗе карлар ява. | 1 | Г.Ибра-һимов иҗаты, «Кар ява» хикәясе. | Табигатькә карата күзәтүчәнлек тәрбияләү, һава торышының үзгәрешен аңлау. | Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Кар ява» әсәрен өйрәнү, һава торышы турында сөйли белү. | |
| 28 | Мәрхә-мәтле булыйк! | 1 | К.Нәҗми иҗаты, «Кызыклы хәл» шигы-ре. | Игътибар-ны арттыру, балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләү. | Язучының иҗаты турында белү, «Кызыклы хәл» шигырен өйрәнү, сөйләм телен үстерү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Өлкән буынга карата ихтирам, туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, таблица тутыру. | | |
| | Өлкән буынга карата ихтирам, туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү. | Яңа сүзләрне уку, язу, эчтәлек буенча төркемнәрдә фикер алышу, әсәргә җиңелчә әдәби анализ ясау, сораулар һәм биремнәргә җавап табу, әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү. | | |
| | Туган җирне ярату, туган як кадере, иң якын кешеләребезнең кадере турында аңлап калу. | Укылган әсәрләр турында фикер әйтү, кыскача эчтәлеген сөйләү, викторина сорауларына җавап бирү, мөстәкыйль эш. | Тест. | |
| | Укучыларга экологик тәрбия бирү. | Портретлары буенча язучыларны тану, яңа сүзләрне истә калдыру, язучы биографиясен уку, сораулар төзү, җавап бирү, презентация карау, караган буенча фикер алышу, һава торышы турында сөйләү. | | |
| | Укучыларга экологик тәрбия бирү. | Язучы тормышы белән танышу, презентация карау, кош исемнәрен истә калдыру, дәреслек, дәфтәр белән эш, парларда сөйләшү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 29 | Чыршыларны саклыйк! | 1 | М.Фәйзуллина иҗаты, «Чыршы күлмәкләре» шигыре. | Табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белү. | М.Фәйзуллинаның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Чыршы күлмәкләре» әсәрен өйрәнү. | |
| 30 | Табигать — безнең байлыгыбыз. | 1 | Р.Вәлиева иҗаты, «Нәни чыршы» шигыре. | Чыршылар турында мәгълүмат бирү. | Р.Вәлиеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Нәни чыршы» шигырен өйрәнү. | |
| 31 | Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә, кирәк һәммәбезгә дә! | 1 | Т.Миңнуллин иҗаты, «Акбай һәм Кыш бабай» пьесасы. | Укучыларда татарча җыр-бию, рольләргә бүлеп уку сәнгатен үстерү. | Т. Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Акбай һәм Кыш бабай» әсәрен өйрәнү. | |
| 32 | Бүлекне кабатлау, йомгаклау дәресе. | 1 | Г.Ибраһимов, К.Нәҗми, Т.Миңнуллин Р.Вәлиева, М.Фәйзуллина иҗатлары. | Белгәннәрне кирәкле ситуациядә кулланып, тестка җавап бирә белү. | Бүлектә укылган әсәрләрне истә калдыру. | |
| **Акыл — тузмас кием, белем — кипмәс кое** | | | | | | |
| 33 | Күп укыган — күп белер. | 1 | К. Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре. | Үзеңә кирәкле белемне дөрес итеп таба белергә, китапларны теләп укырга күнектерү. | К.Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Әбүгалисина» әсәрен өйрәнү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү. | Шагыйрәнең тормыш юлы белән танышып, хронологик таблица тутыру, шигырьне тыңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, парлап сөйләшү, проект эшенә әзерлек. | «Чыршыларны саклыйк» проекты. | |
| | Экологик тәрбия бирү. | Проект эшен яклап, төркемнәрнең чыгыш ясавы, яңа әсәр белән танышу, сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу. | | |
| | Җыр, бию сәнгатенә кызыксыну тудыру | Сорауларга җавап эзләү, ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку, әсәрдә автор әйтергә теләгән фикерне табу, әдәби әсәр турында фикер алышу. | | |
| | Экологик тәрбия бирү. | Төркемнәрдә эшләү, викторина сораулары, мөстәкыйль эш. | Тест. | |
| | | | | |
| | Белемгә омтылыш тәрбияләү. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, таблица тутыру. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 34 | Күп укыган — күп белер. | 1 | К.Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре, «кыйсса» төшенчәсе. | География, биология, тарих фәннәре белән бәйләп аңлату. | К.Насыйриның «Әбүгалисина» әсәрен өйрәнү. | |
| 35 | Ни чәчсәң — шуны урырсың. | 1 | К.Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре, К.Насыйри музейлары. | Укучыларны музейлар белән таныштыру, кызыксындыру. | К.Насыйриның Казандагы һәм Олы Ачасыр авылындагы музейлары белән таныштыру, «кыйсса» төшенчәсе белән танышу. | |
| 36 | Тырышкан — табар, ташка кадак кагар. | 1 | Г.Сабитов иҗаты, «Чүкеч» хикәясе, «хикәяләү» төшенчәсе. | Хикәядә очрый торган яңа сүзләрне (эш кораллары атамаларын) тормыш белән бәйләп истә калдыру. | Г.Сабитов турында белешмә бирү, «Чүкеч» хикәясен өйрәнү, «хикәяләү» төшенчәсе белән танышу. | |
| 37, 38 | Эшләгәнең — кешегә, өйрәнгәнең — үзеңә. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз. | 2 | А.Алиш иҗаты, «Әни ялга киткәч» хикәясе, «хикәяләүче» төшенчәсе. | Төрле ситуациядә югалып калмаска кирәклеген аңлату. | А.Алиш турында белешмә бирү, «Әни ялга киткәч» хикәясен өйрәнү, «хикәяләүче» теоретик төшенчәсен истә калдыру. | |
| 39, 40 | Эш кешене тәрбияли, ялкаулык — боза. Ялган әйткән — тотылыр... | 2 | Ф.Яруллин иҗаты, «Кояштагы тап» хикәясе, «притча» төшенчәсе. | Җаваплылык хисләре, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү. | Ф.Яруллин турында белешмә бирү, «Кояштагы тап» хикәясен уку, «притча» төшенчәсен истә калдыру. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Белемнең, акылның тормышта төп рольне уйнавына төшендерү. | Сорауларга җавап эзләү, ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку, әсәрдә автор әйтергә теләгән фикерне табу, әдәби әсәр турында фикер алышу. | | |
| | Белем алырга, кешеләргә файда китерергә, игелекле булырга омтылыш тәрбияләү. | Сүзлек белән эш, парлап сөйләшү, мөстәкыйль укып, төп мәгълүматны аңлау, дәреслек, дәфтәр белән эш, презентация карау, фикер алышу. | | |
| | Хезмәт тәрбиясе бирү, җаваплылык хисләре, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү. | Язучы тормышы белән танышу, презентация карау, инструмент исемнәрен истә калдыру, дәреслек, дәфтәр белән эш, парларда сөйләшү. | | |
| | Укучыларга хезмәт тәрбиясе бирү. | Дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү, яңа сүзләрне төрле фигыль формаларына кую, җөмләләр төзү, план төзү, укыганны гади җөмләләр белән кыскача сөйли белү. | | |
| | Әниләргә карата шәфкатьлелек, хөрмәт хисләрен үстерү. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, хронологик таблица тутыру, план төзү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 41 | Иң элек син Кеше бул, балам! | 1 | Г.Зәйнашева иҗаты, «Кем булырга» шигыре. | Төрле һөнәрләр, аларның үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирү. | Г.Зәйнашева турында белешмә бирү, «Кем булырга?» шигырен өйрәнү. | |
| 42 | Сәйдәшнең юл башы. | 1 | М.Латыйфуллинның «Сәйдәшнең юл башы» хикәясе, «биографик әсәр» төшенчәсе. | Укучыларга төрле һөнәр сайлау юлларын аңлату. | М.Латыйфуллинның «Сәйдәшнең юл башы» өзеген уку, «биографик әсәр» төшенчәсе белән танышу. | |
| 43 | Моңнар чишмәсе Салих Сәйдәшев. | 1 | С.Сәйдәшев иҗаты. | Җыр, музыка сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү. | С.Сәйдәшевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү. | |
| 44 | Син башкаларга үрнәкме? | 1 | Р.Фәйзуллин иҗаты, «Бердәнбер» шигыре. | Төрле яклап үз сәләтләрен үстерүгә омтылыш тәрбияләү. | Р.Фәйзуллин турында белешмә бирү, «Бердәнбер» шигырен уку, анализлау. | |
| 45 | Йомгаклау, кабатлау. | 1 | К.Насыйри, Г.Сабитов, А.Алиш, Г.Зәйнашева, С.Сәйдәшев, Р.Фәйзуллин әсәрләре. | Укылганны искә төшереп, гомумиләштерә белү, командада эшли белү. | Бүлектә өйрәнгән язучы, шагыйрьләр турында иң төп мәгълүматны белү, әсәрләрен хәтердә ныгыту. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Тормышта үз урыныңны, һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга омтылыш тәрбияләү. | Шагыйрәнең тормыш юлы белән танышып, хронологик таблица тутыру, шигырьне тыңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, парлап сөйләшү, бер һөнәр турында сөйләү. | Проект. | |
| | Яңалыкка омтылу, һәрнәрсәне белергә теләү хисе тәрбияләү, милли горурлык хисләре формалаштыру. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү. | | |
| | Төбәгебезнең күренекле шәхесләре белән горурлану хисләре уяту. | Презентация карау, композитор турында музыка дәресендә алган белемнәрне яңа мәгълүмат белән тәңгәлләштерү, дәреслек, дәфтәр белән эш, музыка тыңлау, фикер алышу, парлап сөйләшү. | | |
| | Әти-әни, туган ил алдында җаваплылык хисләре, ватанпәрвәрлек тәрбияләү. | Язучы иҗаты белән танышу, шигырьне тыңлап аңлау, чылбыр буенча сәнгатьле уку, сайлап уку, дәреслек, дәфтәр белән эш, төркемнәрдә фикер алышу. | | |
| | Һөнәр сайлауга, тормышта урыныңны табуга дөрес караш тәрбияләү. | Язучыларның портретлары белән эш, викторина сорауларына төркемләп, парлап җавап эзләү, мөстәкыйль эш. | Тест. | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Илдә илле дустың булсын** | | | | | | |
| 46 | Туган туганга кирәк. | 1 | Дәрдемәнд иҗаты, «Ике туган» әсәрне. | Сәламәт яшәү рәвеше турында мәгълүмат бирү. | Дәрдемәнднең тормыш юлы белән танышу, әсәрне уку. | |
| 47 | Туганнар белән яшәү күңелле. | 1 | Дәрдемәнд иҗаты, «Ике туган» әсәрне. | Бирелгән текст буенча план төзи белү. | Дәрдемәнднең тормыш юлы турында белү, сәнгатьле уку күнекмәләре үстерү. | |
| 48 | Шагыйрь үткән юл. | 1 | Һ.Такташ иҗаты, «Мокамай» поэмасы. | Тарихтан Һ.Такташ яшәгән чор турында мәгълүмат бирү. | Һ.Такташ турында мәгълүмат бирү, «Мокамай» поэмасы белән таныша башлау. | |
| 49, 50 | Әкияттәге ике бала кебек... | 2 | Һ.Такташ иҗаты, «Мокамай» поэмасы, «поэма» төшенчәсе. | Һәр кеше тормышында хатирәләр булуы, аларның нинди булуының кешенең үзеннән торуы турында аңлау. | Поэма турында теоретик төшенчә белән танышу, «Мокамай» поэмасын уку, аңлау. | |
| 50, 51 | Бәхетне, шатлыкны сакларга кирәк. | 2 | Р.Харис иҗаты, «Серле алан» пьесасы, «диалог», «монолог», «символик образ» төшенчәләре. | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | Р.Харис иҗаты белән танышу, пьесаны укып, нәтиҗә ясау, «диалог», «монолог» төшенчәләрен әдәби термин буларак истә калдыру. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | Әхлак тәрбиясе бирү, сәламәт яшәү рәвеше турында мәгълүмат бирү. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, хронологик таблица тутыру. | | |
| | Әхлак тәрбиясе бирү. | Хикәяне рольләргә бүлеп уку, рәсемгә карап сайлап уку, өлешләргә бүлү, план төзү, план буенча кыскача эчтәлекне сөйләү. | | |
| | Туган як кадерле, онытылмас икәнен аңлату. | Презентация ярдәмендә шагыйрь тормышы, ул яшәгән чор белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, сәнгатьле уку. | | |
| | Чын дуслык кадере, ялгыш адым ясамаска кирәклек турында аңлату. | Дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү, поэманы тыңлау, аңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу, поэмага анализ ясау. | | |
| | Үзләре өчен, әйләнә-тирә өчен җаваплылык хисләре тәрбияләү. | Ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку, әсәрдә автор әйтергә теләгән фикерне табу, әдәби әсәр турында фикер алышу, Р.Харисның рәсемнәре буенча җөмләләр төзү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 53 | Дус булуга ни җитә. | 1 | Э.Шәрифуллина иҗаты, «Дуслык, чын дуслык» шигыре. | Шигъри әсәрне җиңел истә калдыру ысулларын өйрәнү. | Э.Шәрифуллина турында мәгълүмат бирү, дуслык турында шигырьне уку, сөйләм телен үстерү. | |
| 54 | Дуслык булса, яшәр тынычлык. | 1 | Ш.Галиев иҗаты, «Дуслык балы» шигыре. | Әдәбият теориясе, җыр, рәсем белән бәйләнеш табу. | Ш.Галиевнең иҗатын, тормыш юлын белү, сәнгатьле уку күнекмәләре үстерү. | |
| 55 | Кабатлау, йомгаклау. | 1 | Дәрдемәнд, Һ.Такташ Р.Харис, Ш.Галиев, Э.Шәрифуллина әсәрләре. | Укыганны искә төшереп, гомумиләштерә белү, командада эшли белү. | Бүлектә өйрәнгән язучы, шагыйрьләр турында иң төп мәгълүматны белү, әсәрләрен хәтердә ныгыту. | |
| **Көлке көлә килә...** | | | | | | |
| 56 | Шәүкәт Галиев — юмор остасы. | 1 | Ш.Галиевнең «Курыкма, тимим!», «Атлап чыктым Иделне» шигырьләре. | Елга башланган җир турында белү. | Ш.Галиевнең юмористик шигырьләре белән танышу, шигырьгә анализ ясау, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү. | |
| 57 | Ике тиен — зур акчамы? | 1 | Ф.Шәфигуллин иҗаты, «Ике тиен акча» хикәясе. | Укылган әсәрне бүгенге көн, көндәлек тормыш белән бәйләнештә күзаллый белү. | Ф.Шәфигуллин тормышы, иҗаты белән танышу, юмор аша язучы әйтергә теләгән фикерне табу. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Дуслыкның кеше өчен мөһимлеген аңлату. | Шагыйрә турында белешмәне уку, сораулар төзү, сорауларга җавап бирү, шигырьне тыңлау, тәрҗемә итү, сәнгатьле уку, сайлап уку, биремнәр үтәү, ятлау. | | |
| | Поликультуралылык, толерантлык хисләре тәрбияләү. | Парлап сөйләшү, шигырьне тыңлап аңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу, шигырьгә анализ ясау, төрле милләт кешеләренең киемнәре, теле, йолалары турында сөйләшү. | | |
| | Туганнар, яшьтәшләр, төрле милләтләр, илләр арасында<br>дуслыкны аңлау, дус яшәүгә омтылыш тәрбияләү. | Төркемнәрдә эшләү, викторина сораулары, мөстәкыйль эш. | Тест. | |
| | | | | |
| | Экологик тәрбия бирү. | Фронталь әңгәмә, язучы турында презентация ясау, карау, шигырьне тыңлап аңлау, сәнгатьле уку, рольләргә бүлеп уку, дәреслек, дәфтәр белән эш. | | |
| | Әхлак тәрбиясе бирү. | Дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү, яңа сүзләрне төрле фигыль формаларына кую, җөмләләр төзү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 58 | Акбай белән Карабай. | 1 | Ф.Шәфигуллин иҗаты, «Акбай белән Карабай» хикәясе. | Көндәлек тормышка юмор белән карый белергә өйрәнү. | «Акбай белән Карабай» хикәясен уку, юмор аша язучы әйтергә теләгән фикерне табу. | |
| 59 | Шаянлык файдасы. | 1 | В.Радловның «Шаян кеше» хикәясе. | Галим В.Радлов турында мәгълүмат бирү. | Хикәяне уку, сөйләм телен үстерү. | |
| 60 | Кабатлау, йомгаклау. | 1 | Ш.Галиев, Ф.Шәфигуллин, В.Радлов, Г.Остер әсәрләре. | Белгәннәрне кирәкле ситуациядә кулланып, тестка җавап бирә алу. | Бүлектә укылган әсәрләрне истә калдыру. | |
| Һәр фасылың гүзәл, табигать! | | | | | | |
| 61 | Җәйге иртә. | 1 | Р.Әхмәтҗановның «Иртә әле...» шигыре, «пейзаж» төшенчәсе. | Рәсем сәнгатендә пейзаж белән әдәбияттагы «пейзаж» төшенчәсен бәйләнештә күзаллау. | Р.Әхмәтҗанов турында мәгълүмат, «Иртә әле...» шигырен укып аңлау, «пейзаж» төшенчәсен белү. | |
| 62 | Дөнья матур булсын өчен, әни кирәк. | 1 | Г.Рәхимнең «Апрель» хикәясе «портрет» төшенчәсе. | Рәсем сәнгатендә портрет белән әдәбияттагы «портрет» төшенчәсен чагыштыру. | Г.Рәхим турында белү, хикәяне укып аңлау, «портрет» төшенчәсен белү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Әхлак тәрбиясе бирү. | Хикәяне уку, төп эчтәлекне аңлау, фикер алышу, парлап сөйләшү, фигыльләрне, сыйфатларны табу, алар белән җөмләләр төзү, төп геройларны сурәтләү, план төзү, план буенча сөйләү. | | |
| | Күп телләр белергә омтылыш, чит телләргә ихтирам тәрбияләү. | Язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, эчтәлекне берничә җөмлә белән сөйләү. | | |
| | Әхлак тәрбиясе бирү. | Язучыларның портретлары белән эш, викторина сорауларына төркемләп, парлап җавап эзләү, мөстәкыйль эш. | Тест. | |
| | | | | |
| | Табигатьнең матурлыгын күрергә өйрәтү, экологик тәрбия бирү. | Шагыйрьнең тормыш юлы белән танышып, хронологик таблица тутыру, шигырьне тыңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, парлап сөйләшү. | | |
| | Әниләргә ихтирам хисләре тәрбияләү. | Дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү, яңа сүзләрне төрле фигыль формаларына кую, җөмләләр төзү, план төзү, укыганны гади җөмләләр белән кыскача сөйли белү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 63, 64, 65 | Көтеп алган Сабантуй. | 3 | Г.Бәшировның «Язгы сабан туйлары» әсәре. | Төрле бәйрәмнәрнең (бу очракта Сабантуй мисалында) тарихы белән кызыксыну. | Г.Бәширов турында белү, «Язгы сабан туйлары» өзеген укып аңлау, сөйләм телен үстерү. | |
| 66 | Сабантуй — картиналарда. | 1 | Л.Фәттаховның «Сабантуй» картинасы. | Рәсем сәнгате белән әдәбиятның бәйләнеше. | Рәссам Л.Фәттахов, аның картинасы турында белү, сөйләм телен үстерү. | |
| 67 | «Сабантуй» дигән журнал бар. | 1 | «Сабантуй» журналы. | Командада эшләргә, проект эше башкарырга өйрәнү. | «Сабантуй» журналы белән таныштыру, сөйләм телен үстерү. | |
| 68 | «Сабантуй» журналы бездә кунакта. | 1 | «Сабантуй» журналы. | Командада эшләргә, проект эше башкарырга өйрәнү. | «Сабантуй» журналы белән таныштыру, язма сөйләм телен үстерү. | |
| 69, 70 | Кабатлау, йомгаклау. | 1 | Соңгы бүлектә үтелгәннәр + ел дәвамында өйрәнелгән әсәрләр. | Өйрәнгәннәрне гомумиләштерә, нәтиҗә ясый белү. | Әдәби әсәрләрне, теоретик төшенчәләрне аңлап истә калдыру. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Халыкның гореф-гадәтләре, йолаларына ихтирам тәрбияләү. | Яңа сүзләрне язу, эчтәлек буенча төркемнәрдә фикер алышу, әсәргә җиңелчә әдәби анализ ясау, сораулар һәм биремнәр, әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү, план буенча гади җөмләләр белән сөйләү. | | |
| | Халыкның гореф-гадәтләре, йолаларына ихтирам тәрбияләү. | Рәссам турында уку, презентация карау, картинаны карау, фикер алышу, сораулар төзү, сорауларга җавап бирү, картинаны сурәтләп сөйләү, парлап сөйләшү. | | |
| | Татар телен өйрәнүгә карата кызыксыну тудыру, татарча журналдан мәгълүмат сайлый белү. | Журнал тарихына, аның Интернеттагы сайтына күзәтү ясау, журнал саннары белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, бер сан белән таныштыру өчен, төркемнәрдә эшне бүлешү, әзерләнү. | Проект. | |
| | Актив яшәү рәвеше турында аңлату. | Әзерләгән чыгышларны тыңлау — проект яклау, журналга хат язу. | | |
| | Әдәбият белән кызыксындыру, тормыш белән бәйләнешне аңлау. | Тест, «Тапкырлар, зирәкләр клубы», викториналар, музейларга экскурсияләр, китапханәдән җәйге каникулга китап алу. | Тест. | |

## ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕ

### 1 нче дәрес

**Тема:** Халык зур ул, әдип ул, шагыйрь ул...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен чагыштырып карау.

Предмет — халык авыз иҗатын гомуми күзаллау.

Шәхескә кагылышлы — халык авыз иҗаты әсәрләре белән кызыксыну булдыру, сөйләмне алар ярдәмендә баету мөмкинлеген аңлау.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 8—9 нчы битләр), эш дәфтәрендә 3 нче бит.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), әкият, табышмак китаплары, слайдлар: 9 нчы биттәге таблица; төрле әкиятләргә иллюстрацияләр.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Әдәбият дәресләре турында укучылар белән әңгәмә:

— Нәрсә ул әдәбият? Узган уку елында әдәбият дәресләрендә нәрсәләр өйрәндегез? Әдәбиятны өйрәнү ни өчен кирәк? Әдәбият ничек барлыкка килгән?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Язу барлыкка килгәнче үк, кешеләр әкият тә сөйләгәннәр, җырлар да җырлаганнар. Әдәбиятның башы халык авыз иҗатына барып тоташа. (Дәрестә халык авыз иҗаты нәрсә икәнен, аның жанрлары турында 5 нче сыйныфта үткәннәрне искә төшерергә кирәк.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Дәрестә кулланылачак төп сүзләрне — әдәби төшенчәләрне искә төшерү.

Тактада (экранда) сүзләр: *халык, иҗат, әкият, җыр, мәкаль, табышмак, әсәр*. Башта укучыларга эш дәфтәрләрендә сүзләрнең

тәрҗемәләрен табарга тәкъдим ителә. Аннары бергәләп укып, тәрҗемә тикшерелә. Сүзләр белән телдән җөмләләр төзелә, берничә җөмлә эш дәфтәренә язып куела.

2. «Халык авыз иҗаты» төшенчәсен аңлату.

Башта укучыларның фикерләре тыңлана, аннары дәреслекнең 8 нче битендәге теоретик төшенчә укылып, төп үзенчәлекләренә игътибар ителә.

3. Халык авыз иҗаты жанрлары турында 5 нче сыйныфта алган белемнәрне ныгыту, үстерү.

Дәреслекнең 9 нчы битендәге схема белән эш:

— барлык жанрларны әйтеп чыгу, русчага тәрҗемә итү;

— 5 нче сыйныфта өйрәнгән әкият жанрын, һәр төр әкиятләргә мисаллар искә төшерү;

— кызыл төс белән бирелгән жанрларга игътибар иттерү: бу уку елында өйрәнәчәкбез;

— рус халык авыз иҗаты белән чагыштыру, мисаллар уйлау.

4. Дәреслектәге (8 нче бит) сорауларга җавап бирү. 4 нче биремне дәвам итәргә була (укытучы укый, укучылар, тыңлап, нинди жанрга керүен әйтәләр).

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау.

2. Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

Дәрескә нинди уку мәсьәләсе куйган идек? Максатка ирештекме? һ.б.

3. Өй эше: а) эш дәфтәрендәге 2, 3 нче биремнәрне эшләргә;

ә) халык авыз иҗатының төрле жанрларына мисаллар табарга;

б) кечкенә әкият яки табышмак уйлап язарга.

4. Алдагы дәрескә проблема кую:

— Икенче дәрескә нинди эшләр планлаштырырбыз? Бу теманы дәвам итеп, тагын ниләр өйрәнербез?

### Укытучы өчен өстәмә материал

Табышмаклар:

* Агач түгел — яфраклы,
Тун түгел — тегелгән. *(Китап)*

* Акчасыз керәсең, хәзинә алып чыгасың. *(Мәктәп)*

* Диңгезе бар, суы юк,
Шәһәре бар, халкы юк,

Урманы бар, агачы юк. *(Карта)*

* Ул булса, көн була.
Ул булмаса, төн була. *(Кояш)*

* Аяксыз, кулсыз — рәсем ясый. *(Суык)*

* Яз килсә — киенә,
Көз килсә — чишенә. *(Агач)*

Мәкальләр:

*Әткәй — шикәр, әнкәй — бал.

* Һәрбер сүзнең урыны бар.

* Азрак сөйләсәң, күбрәк ишетерсең.

*Балык — сусыз, кеше дуссыз тора алмый.

* Сәламәт тәндә — сәламәт акыл.

*Батырга үлем юк.

Әкиятләрдән өзекләр:

1) «...Берзаман Арысланга, Төлке бик оста итеп абзар төзи, дип килеп әйткәннәр. Арыслан Төлкене чакырган... *(«Абзар ясаучы Төлке»)*

2) «...Тиен өченче кыз янына киткән. Ул вакытта кече кыз камыр баса икән. Ул, камырлы кулларын да сөртеп тормаган, чыккан да әнисе янына йөгергән. *(«Өч кыз»)*

3) «... — Кызыкай, ник елыйсың?

— Ничек инде еламаска, Төлке-төкле аяк! Мин бабай белән әбиемнең бердәнбер оныгы Алёнушка булам. Мине кызлар урманга алып килделәр дә ташлап киттеләр...» *(«Төлке белән Алёнушка»)*

4) «...Ике кеше юлга чыккан, ди. Аларга зур урман аша үтәргә туры килгән. Урманда каршыларына бер аю килеп чыккан. Берсе, бик куркып, агач башына менеп качкан...» *(«Куркак юлдаш»)*

5) «... — Кем минем урындыгыма утырган һәм ваткан? Кем минем ашымны ашап бетергән? — дип кычкырган Мишутка...» *(«Өч аю»)*

## 2 нче дәрес

**Тема:** Һич сине куркытмасыннар шүрәле, җен һәм убыр...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — рус, грек һәм татар мифологиясен чагыштыра белү.

Предмет — мифлар, мифик геройлар турында төшенчә формалаштыру, миф белән әкиятнең аермасын аңлау.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — халык авыз иҗаты әсәрләре белән кызыксыну тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 9—12 нче битләр), эш дәфтәрендә 4 нче бит.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), «Татар мифлары» энциклопедиясе, слайдлар: 9, 10 нчы битләрдәге таблицалар; төрле мифларга рәсемнәр, Шүрәленең төрле рәссамнар ясаган сурәтләре.

**Д ә р е с  б а р ы ш ы::**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Партадашыгызга, дустыгызга, барыбызга хәерле көн, уңышлар, яхшы билгеләр теләп, дәресне башлыйбыз.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү.

2. Әңгәмә (Халык авыз иҗаты нәрсә ул? Авторлары кем? Ни өчен күп жанрлар килеп чыккан? Ни өчен бер үк әкиятнең, җырның төрле вариантлары бар? Халык авыз иҗатын ничек өйрәнәләр? Өйрәнү кирәкме?).

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Халык авыз иҗаты әсәрләре арасында төрле күренешләрнең килеп чыгышы турында әкиятләр бар. Ләкин алар әкият түгел, гадәттә кыскарак булалар, боларның элек чыннан да булганына ышандыралар. Аларны «мифлар» дип атыйлар.

— Без дәрестә мифлар турында белербез, кайбер татар мифлары белән таныша башларбыз.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Дәреслектән миф турындагы теоретик төшенчә белән танышу. Схемадан мифларның төрләрен уку, тәрҗемә итү, мисаллар китерү (укучылар тарих дәресендә үткән грек мифларын, үзләре белгән рус мифларын искә төшерәләр, рәсемнәрен карыйлар).

2. Укытучы татар мифларын өйрәнүче галимнәр турында мәгълүмат бирә.

3. Татар мифларыннан Шүрәле турындагы мифны чылбыр буенча уку.

4. Текстны яхшырак аңлау өчен, 12 нче биттәге 1—4 нче биремнәрне телдән эшләү.

5. 12 нче бит, 7 нче бирем. 5 укучы такта янына чыга. Һәркем Шүрәле турында бер җөмлә уйлап әйтә, ләкин, үз җөмләсен

әйткәнче, алда әйтелгән җөмләләрне кабатлый. 5 нче укучы инде 5 җөмлә әйтергә тиеш була. Бу — эчтәлек сөйләүгә әзерлек булып тора. (Мәсәлән: Шүрәле калын урманнарда яши. Ул кешегә охшаган. Аның бармаклары озын. Ул кешеләр белән сөйләшергә, кытыкларга ярата. Шүрәле этләрдән курка. Шүрәлегә тешләрне күрсәтергә ярамый.)

6. Эш дәфтәренә Шүрәле турында җөмләләр язу.

7. Дәреслекнең 11 нче битендәге сорауларга җавап бирү (теоретик материал кабатлана).

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәрсәләр белдегез?

2. Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве, укытучы белән бергә билге кую.

3. Өй эше: а) эш дәфтәрендә Шүрәле турында язылган җөмләләрнең берничәсен истә калдырып сөйләргә;

ә) «Шүрәлене ничек алдарга?» мифын укып, аңларга.

б) «Шүрәлене ничек алдарга?» мифын укып, Шүрәле турында сөйләргә.

## Укытучы өчен өстәмә материал

**Эдуард Тайлор (1832 — 1917)** — этнография, антропология фәннәренә нигез салучыларның берсе, этнограф, культуролог, дини йолаларны өйрәнүче. Дөнья халыкларының мифларын, йолаларын, фольклорын, культурасын өйрәнә. «Первобытные культуры» (1871) дигән китабында башка халыклар белән бергә славян, татар мифлары турында да әйтелә.

**Каюм Насыйри (1825 — 1902).** 1879 елдан башлап, Насыйри гомерен, рәсми рәвештә бер җирдә дә хезмәт итмәстән, тик язучылык эшенә һәм фәнгә хезмәткә генә багышлый. Аның иң яхшы әсәрләре шушы вакытларда языла. Билгеле, Насыйрига ул вакытларда бик авыр булган. Аның кыю эшчәнлеге, гыйльми-популяр, әдәби әсәрләренең басылып чыга башлавы, ул чордагы байларның, руханиларның һәм алар йогынтысында булган Казан мещаннарының дошманлыкларын көчәйткәннән-көчәйтә барган. Аны төрлечә мәсхәрәләп көлгәннәр, урамнарда туктатып тиргәгәннәр, исемсез хатлар язып хурлаганнар, ничек булса да эшеннән туктатмакчы булганнар. Шул ук вакытта аның фәнни хезмәтләрен танучылар да булган. Укучы яшьләрнең алдынгы өлеше, аны белгән рус галимнәре, беренче чиратта, тюркологлар, Насыйриның хезмәтләренә тиешле бәя биргәннәр, аны 1885 елда Казан университеты каршындагы

Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә действительный член итеп сайлаганнар.

К. Насыйриның беренче фәнни хезмәтләре үк Петербург галимнәре тарафыннан уңай бәя ала. Ул, этнография материаллары җыю өчен, гыйльми җәмгыятьләрнең утырышларында каралган программалар белән дә тәэмин ителә. К. Насыйри соңгы көннәренә кадәр Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең актив члены булып эшләвен дәвам итә: татар халык әдәбияты һәм гомумән культурасы буенча материаллар җыеп, җәмгыять карамагына тапшыра, җәмгыятьнең утырышларында докладлар ясый. «Волжский вестник» газетасы 1895 елның, 21 февралендә чыккан 45 нче санында Насыйриның шундый әдәби-гыйльми хезмәтләре турында «Казан татарларының халык әдәбияты памятниклары» исеме белән бер мәкалә урнаштыра. Без анда түбәндәге юлларны укыйбыз: «Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең соңгы утырышына Казан шәһәрендә торучы Габделкаюм Насыйров тарафыннан татар җырлары, табышмаклары җыентыгы куелды. Татар халык әдәбияты әсәрләреннән булган бу җыентык, бу көнгә билгеле җыентыклар арасында, киң рәвештә төзелгән булуы белән аерылып тора».

Ул бик күп иске кабер ташларындагы язмаларны җентекләп укыган, халыкның үз авызыннан җырлар, риваятьләр, мифлар һәм, гомумән, фольклор материаллары җыйган.

Насыйри мифология һәм этнографиягә караган хезмәтләрендә ул вакытка кадәр тарихчылар тарафыннан тиешенчә кузгатылмаган, аз тикшерелгән материалларны табып, фән дөньясына тапшыруны үзенә бурыч итеп куя: «Безнең максатыбыз — рус историясендә булмаган эшләрне, халык авызындагы риваятьләрне мәйданга чыгармактыр», — ди ул. 1883 ел өчен чыгарылган календаренда К.Насыйри легендалар, әкиятләр урнаштыра. Ул кабер ташы язмаларын, төрле шәҗәрәләрне, кулъязма һәм басма китапларны ныклап өйрәнә.

**Хәмит Ярми (1904 — 1981).** 1939 елда Татарстанда Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты ачылгач, Х.Ярми үзенең бөтен хезмәт юлын һәм гыйльми эшчәнлеген шушы институт белән бәйли. Анда татар фольклорын тикшерү буенча өлкән фәнни хезмәткәр (1939 — 1942, 1944 — 1961), институт директоры (1942 — 1944) һәм фольклор секторының җитәкчесе (1961— 1971) булып эшли.

Х. Ярминең 40 елдан артык дәвам иткән иҗат эшчәнлегенең төп юнәлеше татар фольклорын җыю-барлау, системага салу, тарихи яктан аның төрләрен һәм жанрларын өйрәнү, идея-эс-тетик кыйммәтләрен ачу белән бәйле. Сугышка кадәр һәм сугыштан соңгы чорда ул татар халык авыз иҗатын җыю буенча оештырылган экспедицияләргә җитәкчелек итә, күп кенә өлкәләрдә, авылларда

булып, татар халкының борынгы һәм хәзерге заман фольклоры үрнәкләреннән бай материал туплауда һәм бу җыелган хәзинәнең иң кыйммәтле өлешен фәнни аңлатма-искәрмәләр, кереш сүзләр белән бастырып чыгаруда якыннан катнаша. «Халык иҗаты» (1938), «Татар халык иҗаты» (1951), «Татар халык әкиятләре» (I том, 1946; II том, 1956), «Бәетләр» (1960) исемле күләмле җыентыклар әнә шул фидакарь хезмәтнең нәтиҗәләре булып торалар. Бу басмаларга фәнни кереш сүз һәм искәрмә-аңлатмалар Х. Ярми тарафыннан языла.

**Фатих Урманче (1936)** — аерым китап булып басылып чыккан уннан артык фәнни монография, көндәлек матбугатта фольклор, тарих, этнография темаларына, әдәби хәрәкәткә, мәдәниятнең аерым проблемаларына, язучы-прозаикларның, шагыйрьләрнең иҗатларына, конкрет әсәрләренә, гыйльми хезмәтләргә багышланган 270 кә якын фәнни мәкалә, очерклар, рецензия һ.б. төр язмалар авторы. Фатих Урманченың гыйльми эшчәнлегендә төп урынны халык авыз иҗаты әсәрләре алып торса да, аны язма әдәбият, этнография, тарих мәсьәләләре дә тирәнтен кызыксындыра. Ләкин бу мәсьәләләрне ул һәрвакыт фольклор белән тыгыз бәйләнештә тикшерә һәм фәндә яңа сүз булып кабул ителердәй кызыклы нәтиҗәләр ясый. Аны, һич икеләнмичә, татар фольклористикасында яңа бер фәнни юнәлешкә — тарихи-этнографик юнәлешкә нигез салучы дип тәкъдир итәргә мөмкин.

**Галимҗан Гыйльманов (1957)** озак еллар дәвамында татар халкының борынгы мифларын, риваять-легендаларын, им-томнарын, юрамышларын барлау һәм җыю, ияләр-рухлар дөньясын, тәңречелек тәгълиматын өйрәнү юлында гыйльми эзләнүләрен дәвам итә. 1996, 1998 елларда басылып чыккан «Татар мифлары» биш том итеп уйланылган шул җыелманың тәүге ике китабын тәшкил итә.

## 3 нче дәрес

**Тема:** Су асты галәмәтләре.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — рус, грек һәм татар мифологиясен чагыштыра белү.

Предмет — мифик геройлар турында төшенчә формалаштыруны дәвам итү, миф белән әкиятнең аермасын аңлау.

Шәхескә кагылышлы — иптәшең белән сөйләшә, башкаларны тыңлый белү — аралашу культурасы тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 13—15 нче битләр), эш дәфтәрендә 4 нче бит.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), «Татар мифлары» энциклопедиясе, слайдлар: 9, 10 нчы битләрдәге таблицалар; Су анасының төрле рәссамнар ясаган рәсемнәре.

## Дәрес барышы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

— Кәефләрегез ничек? Бүген нинди билгеләр алдыгыз? Дәрестә кемнәр юк? Ул авырыймы? Кай җире авырта? Сез дәрескә әзерме?

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: Шүрәле турында бер-берсенә сөйлиләр яки, такта янында сөйләгән сыйныфташларын тыңлап, яңа җөмләләр белән тулыландыралар.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Татар мифлары Шүрәле турында гынамы икән? Шүрәле кайда яши? Башка урыннарда яши торган мифик геройлар белән танышырбыз.

### II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. — Су иясе турындагы миф сез белә торган «Су анасы» әкияте белән охшашмы? (Су иясе турындагы мифны укытучы сәнгатьле итеп укый, укучылар карап баралар. Сүзгә-сүз тәрҗемә итмичә генә сорауга җавап бирәләр (беренчел аңлауны тикшерү).

2. Текстны абзацлап уку.

1) Һәр укучы башта үзе эчтән укый, аңларга тырыша. (Сораулар: Су иясе кайда яши? Ул балыкчыларны, кешеләрне яратамы? Су анасы базарда нишли? Аның акчасы бармы?)

2) Икенче абзац шулай ук укыла. (Сораулар: Су иясе кешеләргә ышанамы? Бер кеше күл буенда нишләгән? Судан кем чыккан?)

3) Су анасы белән кешенең сөйләшүен укыйлар. (Сораулар: Су анасы нәрсә сорый? Агай нишлим, ди? Бау агайга нәрсәгә кирәк? Күлне киптереп буламы? Су иясе моңа ышанамы? Ул нәрсә ди? Нәрсә бирәм, ди? Агай аннан нәрсә сорый?)

4) Соңгы абзац укыла. (Сораулар: Су анасы акчаны кайдан ала? Бүрек ни өчен тулмый? Су анасы ничә тапкыр акча алып чыга?)

3. Дәреслекнең 15 нче битендәге сорауларга җавап бирү.

4. Мифны рольләргә бүлеп уку.

5. 15 нче бит, 4 нче бирем. Парлап диалог төзү. Диалогны күршедәге парга сөйләп күрсәтү. Күршеләрне тыңлау. Бергәләп, берничә парны тыңлау.

6. Эш дәфтәрләренә Су иясе турында җөмләләр язу.

7. Әңгәмә.

— Рус (славян) мифологиясендә Су иясе бармы? (Водяной)

— Тагын су, елга белән бәйле нинди мифик герой бар? (Нептун)

— Кайсы халыкныкы? (Грек).

Укытучы дөресли, мәгълүматны тулыландыра.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәрсәләр белдегез?

2. Дәрескә гомуми бәя. Үзбәя.

3. Өй эше: а) I вариант — «Өй иясе», II вариантка «Дедал белән Икар» мифларын укырга;

ә) эш дәфтәрендәге сорауларга җавап язарга (шушы мифлар буенча);

б) сорауларга җавапларны файдаланып, мифларның кыскача эчтәлеген сөйләргә.

### Укытучы өчен өстәмә материал

**Водяной —** Дух, обитающий в воде. Водяной (водяник) живёт в воде, откуда он выходит редко; его любимым местом являются речные омуты, да притом близ водяных мельниц. Водяному приписывают тоже значение, что и домовому, чему служит доказательством пословица: «дедушка водяной — начальник над водой». Ему также приписывают власть над русалками, которые поэтому не составляют самобытного божества. Народ олицетворяет водяного стариком, постоянно покрытого болотною травою. Водяной тоже требует к себе уважения. Месть его заключается в порче мельниц, в разгоне рыбы, а иногда, говорят, он посягает и на жизнь человека. Ему приписывают сома, как любимую рыбу, на которой он разъезжает и которая ему доставляет утопленников. Народ за это сома называет «чёртова лошадь».

В выборе места для жительства водяные неразборчивы, охотно селятся и в реках, особенно в тех, которые протекают в темных и сумрачных еловых чащах. Недоброжелательство к людям и злобный характер водяного выражаются в том, что он сторожит каждого человека, появляющегося в его владениях. С собой на дно он утаскивает тех, кто вздумает летней порой купаться в реках и озёрах после заката.

Еда его — раки, угри, сомы и налимы. Но водяной может обходиться и мукой или крошками хлеба. Рыбаки должны делиться с

водяным, отпуская первую пойманную рыбу. Особенно любит водяной тех рыбаков, которые строго хранят свои секреты.

**Нептун** — в древнеримской мифологии бог морей и потоков. Один из древнейших римских богов. Позднее был отождествлён с греческим богом Посейдоном. Женой Нептуна считалась богиня Салация (Фетида, Амфитрита).

С Нептуном связан праздник *нептуналий*, который отмечался 23 июля. Праздник справлялся с целью предотвращения засухи. Во время этого праздника строились хижины из листьев.

Морской Нептун почитался людьми, связанными с морем или отправлявшимися в морское путешествие.

**Леший** (хозяин леса, лесной дух, лешак, лесовик, дедушка-лесовой) — дух, хозяин леса в мифологических представлениях славянских народов.

Это главный хозяин леса, он следит, чтобы никто в его хозяйстве не навредил. К хорошим людям относится хорошо, помогает выйти из леса, к не слишком хорошим — плохо: путает, заставляет ходить кругами. Он поёт голосом без слов, бьет в ладоши, свищет, аукает, хохочет, плачет.

Леший может предстать в различных растительных, животных, человеческих и смешанных образах, может быть невидимым. Чаще всего предстаёт одиноким существом. На зиму покидает лес, проваливаясь под землю. Как хозяин заботится о лесе, охраняет его, является покровителем лесных животных. Лешему приписываются многие лесные звуки, особенно вызываемые ветром.

Отношение к лешему в народе было двойственным: он одновременно и нечистая сила и справедливый дух. Лешие не столько целенаправленно вредят людям, сколько проказят и шутят, но делают они это грубо и зло: пугают хохотом и хлопаньем в ладоши, сбивают с пути, прячут предметы и др. Леший может наказать человека за ненадлежащее поведение. От лешего зависит удача на охоте и благополучный выпас скота, для этого охотникам и пастухам было необходимо заключить с ним договор. Леший может похищать скот и людей.

**Лобасты** — в славянской мифологии род русалок. Они живут по берегам рек, в камышах. Еще их называют «албастами», они опаснее обычных русалок, ибо старше, опытнее и сильнее. В отличие от обычных русалок, лобасты предстают часто в виде нежити — ужасных полумёртвых старух, которые набрасываются на зазевавшихся людей у воды и утаскивают их под воду.

Лобаста, лобоста, лопаста — несколько видоизменённое название той же «страшной» русалки. Однако в некоторых районах средней и нижней Волги (например, в Саратовской, Астраханской губерниях) лобосту описывали как женщину огромного роста — «величиной от неба до земли».

Тело ее — серая масса, голова косматая, с оскалёнными клыками, руки очень длинные, пальцы скрючены. Лобоста появляется в бурю. Она возникает из тучи, оглушительно смеётся. Встреча с нею гибельна.

«Страшная» албаста-лобоста, скорее всего, отголосок распространённого у многих народов образа богини плодородия и неуправляемой стихии природы; от нее зависит и жизнь и смерть человека.

Так, у татар албасты (албасти) — огромное, опасное существо. Издали албасты не более собаки, но, приближаясь к человеку, становится величиной со стог.

## 4 нче дәрес

**Тема:** Мифлар бүген дә онытылмый

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — рус, грек һәм татар мифологиясен чагыштыра белү.

Предмет — мифик геройлар турында төшенчә формалаштыруны дәвам итү, миф белән әкиятнең аермасын аңлату. Язучылар иҗатына мифик геройлар керүе белән таныштыру.

Шәхескә кагылышлы — иптәшең белән сөйләшә, башкаларны тыңлый белү — аралашу культурасы тәрбияләү, экологик тәрбия бирү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 18—21 нче битләр), эш дәфтәрендә 4, 5 нче битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар: төрле мифик геройларның рәсемнәре, Батулла портреты, «Албасты» пьесасындагы җәнлекләр (аю, куян, бал корты, болан), урман аланы, чәчәкле урман аланы рәсемнәре.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Хәлләрегез ничек? Сезнеңчә, бүген көн матурмы? Һава торышы нинди?

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү. 1) Әңгәмә кору ярдәмендә өйдә укыган мифларны аңлау дәрәҗәсен тикшерү, славян мифлары белән чагыштыру.

2) Эш дәфтәрендәге җавапларны уку, тикшерү.

*3. Уку мәсьәләсен кую*

— Без берничә миф белән таныштык. Мифлар белән әкиятләрнең нинди аермалары бар? Бүгенге көндә мифик геройлар онытылганмы?

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Мифлар белән әкиятләрне чагыштыру.

— Мифлар чынга (элек булганга) охшаганмы? (Әйе.) Ә әкиятләр? (Охшамаган.)

— Мифта кайчан булган дип сөйләнелә? (Борынгы, хәзерге заманда.) Әкияттә? (Тылсымлы, әкияти.)

— Миф кызык өчен сөйләнеләме (юк), әллә берәр күренешне аңлатамы (әйе)? Әкият? (Кызык итеп яки өйрәтеп, әхлак төзәтеп.)

— Мифик геройлар мифларда гына очрыймы? (Г.Тукай әкият-поэмаларында да.)

2. Батулланың «Албасты» пьесасы белән танышу.

— Безнең көннәрдә дә язучылар мифларга еш мөрәҗәгать итәләр. Шуңа бер мисал — дәреслектә.

1) Албасты турында мифны уку, русчага тәрҗемә итү.

2) Пьесаны рольләргә бүлеп уку.

3) Дәреслекнең 21 нче битендәге 1—7 нче сорауларга җавап бирү (пьесаның эчтәлеге, анда күтәрелгән экологик проблема анализлана).

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәрсәләр белдегез?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларның үз эшчәнлегенә үзбәя.

3. Өй эше: а) мифлар турындагы теоретик төшенчәне кабатларга, эш дәфтәрендәге 7 нче биремне (кроссворд) үтәргә;

ә) 21 нче биттәге 8 нче бирем — урманнарны саклау өчен, тәкъдим-проектлар уйлап табарга;

б) «Табигатьне саклау өчен, без нишли алабыз?» проектын якларга, сөйләргә әзерләнергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую: мифлар турындагы белемнәрне гомумиләштерергә, фольклорның тагын бер жанры белән танышырга.

### Укытучы өчен өстәмә материал

1) Некоторые сказки рассматриваются иногда как «деградировавшие мифы». Некоторые исследователи считают мифы разновид-

ностью сказок. Другие, наоборот, склонны называть первобытные сказки мифами.

Мифы отличаются от сказок по функции: основные функции мифа — объяснительные, ритуальные и сакральные, а у сказки — развлекательные, морализаторские и поэтические. Миф воспринимается и рассказчиком, и слушателем как реальность, сказка — как выдумка. Время действия мифа доисторическое, сказка происходит во внеисторическом времени. (www.ruthenia.ru/folklore/meletinsky11.htm сайтыннан)

2) Эш дәфтәрендәге кроссворд.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *у* | *р* | *м* | *а* | *н* | | | | | |
| | | *и* | *к* | *а* | *р* | | | | |
| | | *ф* | *о* | *л* | *ь* | *к* | *л* | *о* | *р* |
| | | *о* | *з* | *ы* | *н* | | | | |
| | *а* | *л* | *б* | *а* | *с* | *т* | *ы* | | |
| | *б* | *о* | *л* | *а* | *н* | | | | |
| *е* | *л* | *г* | *а* | | | | | | |
| | *д* | *и* | *ң* | г | *е* | *з* | | | |
| | *и* | *я* | | | | | | | |

## 5 нче дәрес

**Тема:** Әйтем — сүзнең бизәге, мәкаль — сүзнең җиләге.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

М е т а п р е д м е т — татар һәм рус халык мәкальләрен чагыштыру.

П р е д м е т — мәкаль һәм әйтем турыда теорияне аңлап истә калдыру, аларның аермасын белү, мәкаль, әйтемнәр өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — балаларда халык авыз иҗаты белән кызыксыну уяту, әдәплелек тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 21—26 нчы битләр), эш дәфтәрендә 6, 7 нче битләр.

**Җиһазлау:** Н.Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» китабы, мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдта «Халык авыз иҗаты» схемасы.

**Д ә р е с б а р ы ш ы :**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

*1. Дәресне оештыру*

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

*2. Актуальләштерү*

Өй эшен тикшерү. Төркемнәрнең «Табигатьне саклау» темасына әзерләгән кайбер чыгышларын тыңлау (кайберләрен алдагы дәрескә калдырырга мөмкин).

*3. Уку мәсьәләсен кую*

«Халык авыз иҗаты» схемасы буенча эш (Халык авыз иҗатының нинди жанрлары бар? Кайсыларын 5 нче сыйныфта өйрәндегез? Бу уку елында тагын кайсыларын өйрәнергә тиешбез? Бүгенге дәрестә афористик жанрлардан мәкаль, әйтемнәрне өйрәнербез.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Теоретик материалны аңлату.

— Нәрсә ул мәкальләр? 21 нче биттән укыгыз, аңлатыгыз.

— Нәрсә ул әйтемнәр? 24 нче биттәге төшенчәне укыгыз, аңлатыгыз.

— Алар охшаганнармы? (Сөйләмне матурлыйлар, кыска, тотрыклы халык авыз иҗаты әсәрләре.)

— Аерма нәрсәдә? (Әйтемнәрдә өйрәтү, киңәш бирү юк, әйтем — конкретрак, мәкаль — күп охшаш күренешләр өчен уртак нәтиҗә чыгару.)

2. Дәреслектәге мәкальләрне уку, русчага тәрҗемә итү. 22 нче биттәге 1—4 нче биремнәрне үтәү.

3. Дәреслектәге әйтемнәрне уку, русчага тәрҗемә итү. 2, 3 нче биремнәрне телдән үтәү.

4. Эш дәфтәрендәге 3 нче бирем (мәкаль белән әйтемне аеруга басым ясала).

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрестә нинди яңа белем алдыгыз?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларның үз эшчәнлекләрен бәяләве.

3. Өй эше: а) 3 мәкаль, 3 әйтемне яттан өйрәнергә;

ә) эш дәфтәрендәге 1, 2 нче биремнәрне эшләргә;

б) дәреслектәге 5 нче бирем (әйтемнәр кертеп, кечкенә текст язарга).

4. Алдагы дәрескә проблема кую: мифлар, мәкаль-әйтемнәр турында белгәннәрне йомгаклау.

## 6 нчы дәрес

**Тема:** Нәтиҗә ясарга вакыт.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — татар халык авыз иҗаты әсәрләрен башка халыкларныкы белән чагыштыра, белгәннәрне кирәк ситуациядә искә төшереп куллана белү.

Предмет — миф, мәкаль, әйтем турында теорияне, аларга үрнәкләрне гомумиләштерү, аермаларын таба белү.

Шәхескә кагылышлы — балаларда халык авыз иҗаты белән кызыксыну уяту, аның кешеләрне тәрбияләүдә әһәмиятен аңлату.

**Материал:** методик әсбапның 1 нче кушымтасындагы тестлар.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), һәр укучыга тест, слайдлар: «Халык авыз иҗаты» схемасы, тестларның биремнәре (һәр биремне укучыларга аңлату өчен).

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: 1) укучы мәкаль-әйтемнәрне яттан сөйли, башкалар (яки икенче команда) русча эквивалентын әйтә;

2) төркемнәрнең «Табигатьне саклау» темасына әзерләгән чыгышларын тыңлап бетерү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Беренче бүлекне йомгаклау. Нәтиҗә ясау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Схема буенча теоретик материалны кабатлау, гомумиләштерү.
2. Төркемнәрдә сораулар, биремнәр әзерләү: теория буенча мифик геройлар турында, мәкаль-әйтемнәрне белү.
3. Төркемнәр арасында ярыш: бер-берсенең сорауларына җавап бирү.
4. Һәр укучының тест сорауларына мөстәкыйль рәвештә җавап бирүе.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларның мөстәкыйль эшләрен бәяләве.

3. Өй эше: музыка дәресләрендә җырлар турында өйрәнгәннәрне искә төшерергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую: халык авыз иҗатының тагын бер төре — җырлар турында өйрәнә башларбыз.

## 7 нче дәрес

**Тема**: Халык җырлары — иң кадерле мирас.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укучыларны халкыбызның онытылып бара торган бәйрәмнәре белән таныштыру.

Предмет — халык авыз иҗаты турында белемнәрне тирәнәйтү, халык җырлары жанрлары, йола җырлары турында белешмә бирү, Сөмбелә бәйрәме турында сөйләү.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда халкыбызның йолалары, гореф-гадәтләренә мәхәббәт, мәрхәмәтлелек, игътибарлылык тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 28—30 нчы битләр), эш дәфтәрендә 7 нче бит.

**Җиһазлау**: мультимедиа проекторы, экран, презентация, аудиоязмада халык җырлары, магнитофон.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

**1.** ***Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Хәлләрне сорашып, уңышлар теләп, дәресне башлау.

***2. Актуальләштерү***

«Халык авыз иҗаты» схемасы буенча теманы кабатлау. Үрнәк буенча җөмләләр төзү. (Халык авыз иҗатына ________________ __________ керә.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дәрестә халык авыз иҗатының бер тармагы — халык җырлары жанрлары, йола җырлары белән таныш ачыкларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Презентациядә халык авыз иҗатының тулы схемасы күрсәтелә; укучыларның мөстәкыйль эшләре тикшерелә. Тулы схемадагы халык җырларының жанрларга бүленешенә игътибар юнәлтелә. Укытучы җырларның 5 төргә бүленешен күрсәтә: йола җырлары, тарихи җырлар, лирик җырлар, уен җырлары, такмак-такмазалар.

2. «Бишек җыры» яңгырый. Укучылар тыңлагач, сораулар бирелә:

— Бу җыр ничек җырлана? (Тыныч, салмак кына.)

— Бу нинди җыр? (Бу — бишек җыры.)

— Нәрсә ул бишек? (Яшь баланы тирбәтеп йоклату өчен махсус җайланып эшләнгән асма ятак яки йоклау урыны.)

— Бишек җырларын кемнәр җырлый? (Әни, әби, әти.)

— Сез ничек уйлыйсыз, бишек җырлары нинди төргә керә? (Йола җырлары.)

3. Бер укучы дәреслектән йола җырлары турындагы белешмәне укый.

4. Укытучы укучыларның аңлавын сораулар ярдәмендә тикшерә.

5. Презентациядә ел фасылларына кагылышлы бәйрәмнәрдән күренешләр күрсәтелә. Ел фасылларына бәйле бәйрәмнәр: Сөмбелә, Нардуган, Нәүрүз, Карга боткасы, Сабантуй. Шулай ук аулак өй, каз өмәләрендә йола җырлары еш кулланылганы әйтелә. Сөмбелә бәйрәме турында укытучы мәгълүмат бирә.

— Елның сихри фасылында — көн белән төн тигезләшкән вакытта — Сөмбелә бәйрәме уздырылган. Ул — көзге бәйрәм, уңыш бәйрәме. «Сөмбелә» — башак дигән сүз.

Дәреслектә 29 нчы биттәге сүзлек өстендә эш: *яхшы, кәеф, Сөмбелә.*

6. Дәреслектән Сөмбелә турында белешмәне уку, фикер алышу.

7. Сүзлек өстендә эш.

30 нчы биттәге сүзлекчәнең татарча-русча тәрҗемә күнегүләре.

8. «Сөмбелә җыры»ның сүзләрен укып аңлау, тыңлау, бергәләп җырларга өйрәнү.

9. Дәреслектәге биремнәр, сораулар; эш дәфтәрендә эшләү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәрсәләр белдегез? Дәрестә алынган белемнәр тормышта кирәк булырмы?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга, дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

3. Өй эше: а) җыр турындагы теоретик төшенчәне кабатларга;

ә) эш дәфтәрендә 2 нче биремне эшләргә;

б) әби-бабайлардан алар яратып җырлаган халык җырларын язып алып килергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую (башка җыр жанрларын өйрәнербез).

## 8 нче дәрес

**Тема:** Халык җырларында —тарих чагылышы.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укучыларны тарихи вакыйгалар, тарихи шәхесләр белән таныштыру, халыкның үткәнен, тарихын, язмышын аңлату.

Предмет — тарихи җырлар турында белешмә бирү, «Көзге ачы җилләрдә» дигән татар халык җырын өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — үз халкыңның үткәнен белү, тарихи җырлар аша чорны, халыкның язмышын аңлау, халык җырларына ихтирам тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 32—33 нче битләр), эш дәфтәрендә 8 нче бит.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар, җыр язмалары, магнитофон.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Өй эшен тикшерү***

Үзе яраткан йола бәйрәме турында язылган эшләрне тыңлау.

***2. Актуальләштерү***

1. Җырларның жанрларын искә төшерү.
2. Сүзлек өстендә эшләү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дә халык җырлары турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен әйтә. Тарихи җырлар белән танышуны искәртә. Укучылар белән бергә дәрескә бурычлар куялар.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Тарихи даталарны искә төшерү.

I Бөтендөнья сугышы — *Первая мировая война.*

Бөек Ватан сугышы — *Великая Отечественная война.*

Гражданнар сугышы — *Гражданская война.*

Социализм чоры — *период социализма.*

1941 — 1945 еллар — Бөек Ватан сугышы еллары.

1917 ел, февраль — Патша бәреп төшерелә, Вакытлы хөкүмәт урнаша.

1917 ел, 7 ноябрь — Социалистик революцион система урнаша.

1918 — 1920 еллар — Гражданнар сугышы еллары.

2. Бу чорларга кагылышлы җырлар тыңлана. Аларны укытучы үзе сайлый (Тәкъдим ителә: «Комсомолка Гөлсара», «Герман көе» — Рөстәм Маликов башкаруында.)

3. Бу җырлар тарихи җырлар дип атала. Белешмәне дәреслектән уку. Укыганны аңлау өчен сораулар бирелә.

4. Дәреслектән «Күзге ачы җилләрдә» җырының тексты белән эш.

а) Фонетик күнегү.

ә) Сүзлек өстендә эш: укытучы сүзләрнең русчасын әйтә, укучылар тәрҗемә итә.

б) Җырның тексты белән танышу (тулы вариантны укырга. Тарихи вакыйгага анализ ясарга.)

в) Сәнгатьле уку.

г) Материалны аңлауны ныгыту өчен, эш дәфтәрендәге биремнәр үтәлә.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрестә нәрсәләргә өйрәндегез? Бу белемнәр кайда, кайчан кирәк булыр?

2. Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3. Өй эше: а) дәреслектән тарихи җырлар турындагы теоретик төшенчәне истә калдырырга;

ә) эш дәфтәрендәге 1—2 нче биремнәрне эшләргә;

б) Интернет челтәреннән тарихи җырлар табарга.

## 9 нчы дәрес

**Тема.** Уйныйбыз да, җырлыйбыз да.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — укучыларга сәнгать тәрбиясе бирү.

П р е д м е т — уен җырлары турында белешмә бирү, «Кәрия-Зәкәрия» уен җырын өйрәнү.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — коллектив белән башкарыла торган халык җыры культурасы белән танышу, аны өйрәнү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 33—35 нче битләр), эш дәфтәрендә 8—9 нчы битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, презентация, уен җырлары аудиоязмалары.

## Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Өй эшен тикшерү***

Интернет челтәреннән укучылар эзләп табып килгән тарихи җырларны тыңлау һәм нәтиҗә ясау.

***2. Актуальләштерү.***

Укытучы халык авыз иҗаты турында әңгәмә оештыра.

— Халык авыз иҗатының үзенчәлекләрен әйтегез *(особенности устного народного творчества).*

— Халык авыз иҗатына нәрсәләр керә?

— Халык җырлары нинди төрләргә бүленә?

— Нинди йола бәйрәмнәре беләсез?

— Нинди тарихи җырлар беләсез?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүгенге дәрестә халык җырларының жанр төрләре турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен әйтә. Уен җырлары белән танышуны искәртә. Темадан чыгып, уку мәсьәләсе куела.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Әңгәмә.

— Балалар, сез нинди уеннар беләсез?

— Сүзле уеннардан нинди уеннар беләсез? («Ал кирәк, гөл кирәк...», «Җиләк җыям, как коям...», һ.б.)

— Җырлы уеннар да була. Алардагы җырларны уен җырлары дип йөртәләр.

2. Дәреслектән уен җырлары турындагы белешмәне укып аңлау. Бер укучы кычкырып укый. Укытучы, аңлаганны тикшерү максатыннан, сораулар бирә.

— Яшьләр кайларда күңел ачканнар?

— «Кәрия-Зәкәрия» җырында, рифмага туры китерер өчен, нинди сүз кулланалар?

— Нинди уен җырлары искә алына?

— Әйдәгез, без өйрәнәсе уен җырының сүзләре белән танышыйк.

3. Сүзлек өстендә эш.

4. Чылбыр буенча уку, кушымтаны хор белән бергәләп уку.

5. Яңа куплет өстәп уку («биюче» сүзе белән).

6. Сыйныф бүлмәсендә түгәрәкләнеп басып, җырлы уенны өйрәнү. Берничә мәртәбә уйнау.

7. Әңгәмә.

— Җырлы уен сезгә ошадымы?

— Яңа җырлы-биюле уен өйрәнергә теләгегез бармы?

8. Татар биюе видеоязмасын карау.

— Биючеләр нәрсәләр кигән? (Итек, читек, калфак, түбәтәй, чалбар, күлмәк). — Аларның киемнәрендә нинди орнаментлар бар? Рус орнаментлары белән тәңгәл киләме?

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Уку мәсьәләсен чиштекме? Нинди яңа белем алдыгыз?

2. Дәрескә бәя. Укучыларның эшләренә үзбәя. Журналга билгеләр кую.

3. Өй эше: а) «Кәрия-Зәкәрия» яки «Әпипә» җырының сүзләрен өйрәнергә;

ә) эш дәфтәрендә читек, түбәтәй, калфак рәсемнәре өчен татар орнаментлары ясарга;

б) укучыларның үзләренә ошаган яки әти-әниләре яратып уйнап җырлаган, яки Интернет челтәреннән эзләп тапкан уен җырын иптәшләренә өйрәтергә әзерләнергә.

### Укытучы өчен өстәмә материал

Татар халык уен үрнәкләренең, бию хәрәкәтләренең тасвирламасын Гай Таһировның («100 татарских фольклорных танцев», Казань, 1988) хезмәтендә һәм «Татар халкының җырлы-биюле уеннары» җыентыгында табарга мөмкин. Аларның күпчелеге җыр барышында салмак кына түгәрәк әйләнүгә, уртага чыгучыларның кара-каршы һәм култыклашып биюенә яки ике рәткә тезелеп баскан уенчылар арасыннан үзең сайлаган пар белән җитәкләшеп үтүгә кайтып кала. Җырлы-биюле уеннар элек гадәттә күп кеше катнашында ачык һавада башкарыла торган булган. Шул ук вакытта алар юа, кузгалак, чәчәк бәйрәмнәрендә, Сабантуй, җыен вакытларында уйналган.

Музыкаль яктан уен җырларының төзелеше — композициясе ике өлештән — түгәрәк әйләнгән вакытта салмак итеп җырлана торган озын җырдан һәм уртадагылар биегәндә кызу итеп башкарыла торган кушымта — такмактан тора.

## 10 нчы дәрес

**Тема:** Шигъриятьтә халык көе.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — милли үзаңны үстерү, халыкның үткәненен, тарихын өйрәнү.

Предмет — Г.Тукайның халык җырларына карата булган хезмәтләре турында белешмә бирү, «Туган тел», «Туган авыл» җырларын өйрәнү; композитор А.Монасыйпов турында белешмә бирү.

Шәхескә кагылышлы — Тукайга хөрмәт, милләтеңә, туган җиреңә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү.

**Материал:** Г.Тукайның «Туган тел» шигыренең рус һәм инглиз телләренә тәрҗемәсе, «Туган авыл» шигыре, А.Монасыйпов турында белешмә, «Туган тел» җыры (Г.Тукай сүзләре, халык көе); «Туган авыл» җыры (Г.Тукай сүзләре, А.Монасыйпов көе).

**Җиһазлау:** Г.Тукай һәм А.Монасыйпов портретлары, мультимедиа проекторы, җыр язмалары.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру.***

Укучылар белән исәнләшү. Дежур укучыны тыңлау. Уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: а) әти-әниләре, әби-бабайлары уйнаган уен җырларын белешү;

ә) «Кәрия-Зәкәрия», «Әпипә» уен җырларының сүзләрен яттан сөйләү, бергәләп җырлау.

б) укучылар ясаган орнаментларны бәяләү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Г.Тукайның портретын карау.

— Бу кем? Аның турында нәрсәләр беләсез? (Балаларның Тукай турында белемнәрен ачыклау.)

Укытучы бүгенге дәрестә Г.Тукайның җырга булган мөнәсәбәте турында сөйләшү алып барылачагын хәбәр итә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Г.Тукай сүзләренә язылган, халык көе булган «Туган тел» яңгырый.

2. Укытучы мәгълүмат бирә: татар халкы өчен «Г.Тукай», «туган тел», «милләт» төшенчәләренең аваздаш булуы турында сөйли.

3. Укытучының шигырьне сәнгатьле укуы яки актёр укуында дисктан тыңлау, сораулар ярдәмендә укучыларның аңлавын тикшерү. (Шигырь нәрсә турында? Кемнәр телгә алына? Әни, әби турында нәрсә әйтелә?)

36 нчы биттәге 1—7 нче биремнәрне эшләү; шигырьнең рус һәм инглиз телләренә тәрҗемәләрен уку.

4. Дисктан «Туган тел» җырын тыңлау, көен бергәләп өйрәнү.

5. — Шагыйрьнең язган шигырьләренә җырлар бик күп. Аларны халык яратып башкара. Композитор Алмаз Монасыйпов «Тукай аһәңнәре» дигән вокаль-симфоник поэма яза. Шушы циклга кергән «Туган авыл» җырын да тыңлап карыйк. (Җырны тыңлау, эчтәлеге буенча әңгәмә.)

6. Эш дәфтәрендә Г.Тукай яшәгән авыллар турында биремне эшләү.

7. Дәреслектәге сүзлек белән эш.

8. Шигырьне сәнгатьле уку.

9. Композитор турында кыскача белешмә бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Г.Тукай сүзләренә язылган нинди җырлар белдегез? Аның җырларын тагын белергә телисезме?

2. — Дәрес сезгә ошадымы? (Смайликлар белән күрсәтү.)

3. Өй эше: а) «Туган тел» яки «Туган авыл» җырларының сүзләрен өйрәнергә (укучыларга сайлау мөмкинлеге бирергә була — «5» легә шигырьнең 3—4 строфасын өйрәнергә, «4» легә — 2 строфаны яхшы итеп сөйләргә, һ.б.);

ә) дәреслектән А.Монасыйпов турында укырга;

б) туган тел турында 5 җөмлә төзергә.

## Укытучы өчен өстәмә материал

Әдәбиятка иң якын торган сәнгать — музыка. Кеше җырны көе һәм сүзләре белән бергә ота, шулай кабул итә. Җырларда көй генә түгел, сүзләр дә бик әһәмиятле урын алып тора.

Халык җырларының тарихы бик еракларга китә. К.Насыйри, беренче буларак, халык җырларын җыйган, аларны өйрәнгән, рус теленә тәрҗемә иткән. Шуның белән бергә ул рус җәмәгатьчелеген дә татар халкының музыкаль фольклоры белән таныштыра башлаган. Г.Тукай да халык җырларын бик яраткан, аларның тарихи

әһәмиятен өрәнгән, үзе дә бик матур җырлый торган булган. 1910 елда, халык җырларын һәм бәетләрне туплап, «Халык моңнары» дигән җыентык төзеп чыгарган.

## ХӘТИМӘ
### (соңгы сүз)

Халык җырлары чын үземезнеке генә булганга, анда читләрдән гарәп, төрек, сарт кебиләрнең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм һәм мәхәббәт итәм. Шунлыктан, халык җырларына мәхәббәтемнең бер өлеше дип, шушы мөляхәзәләремне язарга җөрьәт иттем.

Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Мәдрәсәдә хәлфәләр кече атна кичләрдә бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде.Мин, самавыр артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул җырлавым бәрабәренә хәлфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия кыйлына иде. Мин, кулымдагы симәнкәне бетергәнче яргач, тагын җырлый идем.

Мәдрәсәдә үк мине «җырчы» диләр иде.

Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телемезне сөю тугъды. Әгәр миңа җырулар ярдәм итмәсә, мин соң сарт «Бәдәвам»нәре, сарт «Кисекбаш»лары, кызылбаш «Тасриф»ләре, гарәп «Нәхү»ләре (синтаксис) белән туган телемезне сөймәк кеби бер олуг нигъмәткә малик (байлыкка ия) була алыр идеммени?

Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!

*(Тукай Г.* Халык әдәбияты //*Г.Тукай.* Әсәрләр. Биш томда. Проза. Публицистика (1907 — 1913). — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. — 164—185 б.)

## 11 нче дәрес

**Тема:** Татарстан Республикасының Дәүләт гимны.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укучыларга патриотик тәрбия бирү.

Предмет — Татарстан Республикасы Дәүләт гимны турында теоретик төшенчә бирү һәм гимнның сүзләрен аңлап истә калдыру.

Шәхескә кагылышлы — Татарстан Республикасы, аның казанышлары белән горурлану хисләре тәрбияләү һәм, Дәүләт гимны яңгыраганда, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштерү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 40—41 нче битләр).

**Җиһазлау:** магнитофон, Россия һәм Татарстан гимннарының аудиоязмалары.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: укучыларның шигырьләрне яттан сөйләве (берничә кеше — укытучыга, берничә кеше — партадашына, күрше партада утыручы сыйныфташларына һ.б.)

2. А.Монасыйпов турында сорауларга җаваплар эзләү (нинди шигырьгә көй язган? Нинди зур әсәрләре бар? һ.б.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

1. Тактада (слайдта) А.Монасыйпов һәм Р.Яхин портретлары. (Болар кемнәр? Р.Яхинның иң танылган әсәрен беләсезме?) Укытучы Р.Яхинның Татарстан Республикасы Дәүләт гимны авторы икәнен, бүген гимн турында сөйләшү булачагын җиткерә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. «Гимн» төшенчәсен аңлату эше Россия гимнын тыңлау, аның кайларда яңгыравын, ничек тыңлануын искә төшерү аша бара.

2. Татарстан Республикасы гимнын тыңлау.

— Әлеге гимнда үткәнебез дә чагыла, киләчәгебезгә өметләр дә баглана. Республикабыздагы күпмилләтле халкыбызның тату, дус яшәве дә чагылыш тапкан. Дәүләт гимны текстының 8 юлы — татарча, 8 юлы рус телендә, һәм алар бергә башкарыла.

3. Дәреслектән (40 нчы бит) Дәүләт гимнының текстын укытучы укый. Авторларның портретын күрсәтеп, мәгълүмат бирә. Гимнны тыңлау тәртибен аңлата. (Татарстан Республикасының Дәүләт гимны турындагы Положениедә (Нигезләмәдә) әйтелгәнчә, Татарстан Республикасы Дәүләт гимны халык алдында башкарылганда, гимнны басып тыңлыйлар. Дәүләт гимнына ихтирам күрсәтү — дәүләтнең һәр гражданинының бурычы.)

4. Сүзлек белән эш: укытучы сүзләрне укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Аерым укучылардан авыр сүзләрне кабатлаттыра.

5. Татарстан Республикасының Дәүләт гимны текстын, аңлап, дөрес укуга ирешү. Гимн текстын ятлауга әзерлек эше

(укучыларның эчтән укулары, партадашларына укулары, чылбыр буенча сәнгатьле уку, экранда (тактада) гимн текстының төшеп калган сүзләрен искә төшереп куеп уку һ.б.)

**III . Рефлексив бәяләү**

1. Укучылар ТР Дәүләт гимнын тыңлыйлар. (Басып тыңларга икәнне алар дәрестә үзләштерергә тиеш.)

— Гимнны тыңлаганда, нәрсәләр күз алдына килә?

— Сез бүгенге дәрестә нәрсәләр белдегез? Ничек уйлыйсыз: бу дәресне без бушка уздырмадыкмы?

2. Дәрескә бәя. Үзбәя.

3. Өй эше: гимнның сүзләрен ятларга.

### Укытучы өчен өстәмә материал

«Гимн» — грек сүзе, «тантаналы җыр» дигән мәгънәне белдерә.

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны:

1) Татарстан Республикасында билгеләп үтелә торган бәйрәмнәргә багышланган тантаналы җыелышларны, утырышларны ачканда һәм япканда;

2) Дәүләт органнары тарафыннан уздырыла торган церемонияләр һәм башка тантаналы кичәләр вакытында Татарстан Республикасы Дәүләт флагын күтәргәндә;

3) Татарстан Республикасына рәсми визит белән килүче дәүләт һәм хөкүмәт башлыкларын, БДБ илләренең һәм чит илләрнең рәсми делегацияләрен каршылаганда һәм озатканда тиешле дәүләт гимны башкарылганнан соң;

4) Татарстан Республикасы тормышындагы мөһим тарихи вакыйгаларны билгеләп үтү йөзеннән, һәйкәлләр, монументлар, обелисклар һәм башка корылмалар ачканда;

5) һәр көнне «Татарстан» телерадиокомпанияләренең тапшыруларын башлаганда башкарыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 14 июлендәге карары нигезендә расланган Гимнның музыкаль редакциясенә төгәл туры китереп башкарылырга тиеш.

Гимнның авторы — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, СССР һәм Россиянең халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты композитор Рөстәм Яхин, сүзләрен Рамазан Байтимеров язган, Филипп Пираев рус теленә тәрҗемә иткән.

## 12 нче дәрес

**Тема:** Җырсыз кеше — канатсыз кош.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — халык иҗатының бай мирасын өйрәнү, әхлакый һәм эстетик тәрбия бирү.

Предмет — җыр жанрларын, җыр сәнгатен белүне ныгыту.

Шәхескә кагылышлы — укучыларда җырга, музыкага мәхәббәт тәрбияләү, коллектив башкару, җыр культурасын үстерү.

**Материал:** әти-әниләр, әби-бабайлар истәлекләреннән һәм Интернет челтәреннән алынган халык җырлары, Р.Ваһапов портреты һәм аның турында белешмә.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, магнитофон, халык җырлары язмалары, Р.Ваһапов портреты һ.б.

### Дәрес барышы:

**Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Исәнмесез, укучылар! Кәефләрегез ничек? Бүген сыйныфта кем дежур? Барлык укучылар да дәрестә катнашамы?

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: гимн сүзләрен яттан сөйләү. Татарстан Дәүләт Гимнын тыңлау. Гимнны тыңлаганда, хаталар җибәрелмиме? Гимн тыңлау кагыйдәләрен искә төшерү.

2. Сораулар ярдәмендә кабатлау:

— Халык җырлары башка җырлардан нәрсә белән аерыла? (Авторлары билгесез.)

— Халык җырлары нинди төрләргә бүленә?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Экраннан Г.Тукай сүзләре укытыла:

«Халык җырлары — халык күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер. Бу — бертөрле сихри көзгедер...».

— Бу сүзләр бүгенге дәресебезнең эпиграфы, ягъни төп мәгънәсен билгеләүче сүзләр булачак. Бүгенге дәрестә без төркемнәрдә эшләрбез, һәм сез халык җырлары буенча үзләштергән белемнәрегезне күрсәтерсез.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Төркемнәргә бүленү. Дәреслектән Р.Ваһапов турында укып, диалог төзү һәм һәр төркемнән 1 пар укучының диалогын тыңлау.

2. Укытучының Р.Ваһапов турында тулырак сөйләве, презентация күрсәтү. Аудиоязмада бер җырын тыңлау. Җырчы турындагы материал бу бүлекнең логик тәмамлануы икәнен аңлату: халык җыры — шигърияттә халык көе — шагыйрь белән композитор иҗат иткән җырлар — профессиональ башкаручы (җырчы).

3. Мөстәкыйль эш: тест сорауларына җавап бирү (кушымта).

4. Дәреслекнең 42 нче битендәге бирем: җырлар турында телдән журнал әзерләү. Төркемнәрдә бу проект эше өчен җыр төре сайлау, материал табу һәм аны тәкъдим итү формасын уйлашу, эш бүлешү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — «Халык җырлары» темасыннан кайсы дәрес ныграк ошады?

2. — Дәрестә биргән җавапларыгыздан сез канәгатьме? Ни өчен? Үзбәя.

3. Өй эше: төркемнәрдә җырлар турында проект әзерләргә.

## 13 нче дәрес

**Тема:** Кадерле син, Кеше туганым!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — автор әйтергә теләгән төп фикерне таба, аны тормыш белән бәйли белү.

Предмет — язучы Н.Исәнбәт иҗаты белән танышу, «Өч матур сүз» шигыренең эчтәлеген, «лирик герой» төшенчәсен аңлау.

Шәхескә кагылышлы — эти-әнинең, туган илнең кадерле икәнлеген аңлау, сөйләм телен үстерү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 44—45 нче битләр), эш дәфтәрендә 9, 10 нчы битләр.

**Җиһазлау:** Н.Исәнбәт китаплары, мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар: язучы портреты, туган ил — Россия, Татарстанны сурәтләгән рәсемнәр.

## Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: проект эшләрен яклау.

2. Яңа бүлек исеме, аның ни турында булачагы, кадерле әйберләр турында әңгәмә (Сиңа нәрсә кадерле? Кем кадерле? Һәрчак бер үк әйберләр кадерлеме? Ә нәрсәләр кешегә гомер буе кадерле булып кала?)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Н.Исәнбәтнең «Өч матур сүз» шигыре. Уку мәсьәләсе куегыз. (Н.Исәнбәтнең кем икәнен белү, шигырьне уку, аңлау.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Язучы Н.Исәнбәтнең кыскача биографиясе, иҗаты белән таныштыра — укытучы язучының портретын, китапларын күрсәтеп сөйли.

2. Дәреслектән язучы турындагы белешмәне чылбыр буенча уку, укытучы сораулары белән аңлауны тикшерү.

3. Шигырьне укуга, аңлауга әзерлек.

— Шигырь «Өч матур сүз» дип атала. Сезнеңчә, нинди матур сүзләр бар? (Әти, әни һ.б.) Эш дәфтәрендәге 1 нче бирем.

— Н.Исәнбәт нинди матур сүзләр турында әйтергә теләгән икән? Шигырьне укыгач, белербез. Шигырьне аңлау өчен, безгә тактадагы (экрандагы) сүзләр кирәк булыр *(әйт, уйлап, якын, якын сүз, калмый, һәрвакыт, бергә, ил, илкәем, җир, җиркәем, төп бабамнар)*.

Сүзләрне укытучы артыннан кабатлау, тәрҗемә итү. Укучыларның дөрес итеп укулары. Җөмләләр төзү.

4. Шигырь белән эш.

1) Укытучының сәнгатьле укуы. Эчтәлек буенча сораулар:

— Шигырь нәрсә турында?

— Нинди матур сүзләр турында әйтелә?

2) Шигырьне чылбыр буенча уку, русчага сүзгә-сүз тәрҗемә итү.

3) Шигырьне һәр укучының эчтән укуы, сәнгатьле укуга хәзерлек. Сәнгатьле уку.

5. Теоретик төшенчәне кертү.

— Шигырь диалог формасында. Бу — кемнәр сөйләшүе?

— Автор сүзләре кайсылар? Автор үзен генә күздә тотамы?

— Авторны чагылдыручы образ «лирик герой» дип атала. Дәреслектәге теоретик төшенчәне укыйк. Аңлашыламы?

6. Яңа материалны ныгыту — дәреслектәге сорауларга җавап бирү.

5 нче бирем — шигырьне ятларга. Өй эшенә әзерлек: шигырьне йөгерек уку, истә калдырырга тырышып уку («фотога төшерәбез»), эш дәфтәрендәге 2 нче биремне эшләү (китапка карамыйча, төшеп калган сүзләрне искә төшереп язу).

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәрсәләр белдегез?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларның үз эшчәнлекләрен бәяләве.

3. Өй эше: а) «Өч матур сүз» шигырен яттан өйрәнергә;

ә) лирик герой турындагы теоретик төшенчәне истә калдырырга;

б) башка бер шигырьдәге лирик геройны табып аңлатырга.

* Өстәмә уку өчен бирелгән «Туган ил» шигырен шушы ук дәрестә танышып, тыңлап китәргә яки каникулда укырга тәкъдим итәргә була.

## 14 нче дәрес

**Тема:** Ирек — кадерлеме?

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — татар мәсәлчеләрен рус әдәбиятындагы мәсәлчеләр белән чагыштыру, мөстәкыйль укып, нәтиҗә ясый белү.

Предмет — язучы М.Гафури иҗаты, «Әтәч белән Сандугач» мәсәле белән танышу, «сынландыру» теоретик төшенчәсен аңлау.

Шәхескә кагылышлы — тормышта ихтыяр көченең, белемнең кирәклеген аңлау.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 48—51 нче битләр), эш дәфтәрендә 10 нчы бит.

**Җиһазлау:** М.Гафури китаплары, мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар: язучы портреты, сүзлекчәдәге сүзләр, әтәч, сандугач рәсемнәре.

## Дәрес барышы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: «Өч матур сүз» шигырен яттан укуларын тыңлау.

2) — Кем ул Нәкый Исәнбәт? Нәрсә исегездә калды? Бу шигырьдә шагыйрь әйтергә теләгән төп фикер нәрсә?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Мәҗит Гафуриның «Әтәч белән Сандугач» мәсәле. Уку мәсьәләсе куябыз (М.Гафури турында мәгълүматлы булу, мәсәлне уку, аңлау).

— Бу мәсәлне узган дәрестә өйрәнгән «Өч матур сүз» шигыре белән нәрсә бәйли? (Әтәч туган җирендә, иректә. Сандугач рәхәт яши, ләкин читлектә.)

### II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Язучы М.Гафуриның кыскача биографиясе, иҗаты белән таныштыру (укытучы презентация күрсәтә яки портреты, китапларын күрсәтеп сөйли).

2. Дәреслектән язучы турындагы белешмәне мөстәкыйль уку, укытучы сорауларына җавап бирү: кайда, кайчан туган, кайда укыган һ.б.

3. Мәсәлне укуга, аңлауга әзерлек.

1) Дәреслекнең 50 нче битендәге, экрандагы сүзлекчә белән эш: дөрес итеп уку, сүзләрне кабатлау, тәрҗемәсен уку, сүзтезмәләр төзү.

2) Эш дәфтәрендәге 1 нче бирем: сүзтезмәләрне тәрҗемә итү.

4. Мәсәлне укытучының сәнгатьле укуы.

— Мәсәл нәрсә турында?

5. Мәсәлне чылбыр буенча уку — һәр строфаны сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү.

6. Белемнәрне ныгыту.

1) Дәреслектәге сорауларга җавап бирү.

2) Дәреслектәге рәсем буенча сөйләшү.

— Әтәч нинди? Ул кайда? Сандугач кайда? Рәсемдә ничә тавык бар? Бу рәсемгә кайсы юллар туры килә? Чынлыкта әтәч, сандугач нишли генә беләләр (сайрый, кычкыра)? Ни өчен бу мәсәлдә алар сөйләшәләр?

7. Сынландыру турында теоретик төшенчәне аңлату. Дәреслектән уку.

— Сынландыру бигрәк тә экиятләргә, мифларга, мәсәлләргә хас. Бу әсәр кайсы жанрга туры килә? (Мәсәл турында теоретик төшенчә белән танышу.)

Дәреслектәге 10 нчы бирем.

— Мәсәлнең морале була. Бу мәсәлнең моралең эзлик. Ә кешеләр өчен ирекле булу мөһимме? Нинди сыйфатлар кирәк? (Белем, көч, ихтыяр көче, һ.б.)

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? М.Гафури турында нәрсәләр исегездә калды? Мәсәл аңлашылдымы? Куелган сорауга җавап таптыгызмы? («Өч матур сүз» белән бәйләнеш — әтәч үз туган җирендә, иректә. Туган ил дә, ирек тә кадерле.)

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) «Әтәч белән Сандугач» мәсәлен рольләргә бүлеп укырга әзерләнергә;

ә) дәреслектән И.Крылов яки Г.Шамуков мәсәлен укырга;

б) өстәмә укылган мәсәл буенча эш дәфтәрендәге сорауларга җавап язарга.

## 15 нче дәрес

**Тема:** Анага бала кадерле, балага ана кадерле.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — музыка дәресендә өйрәнгән бишек җырлары яки әниләр турындагы җырларны искә төшереп, әдәбият белән бәйләнешне аңлау.

Предмет — язучы М.Гафури иҗаты белән танышуны дәвам итү, «Ана» шигырендә автор фикерен аңлау, сәнгатьле уку.

Шәхескә кагылышлы — әниләргә карата ихтирам тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 56—57 нче битләр), эш дәфтәрендә 11—12 нче битләр.

**Җиһазлау:** М.Гафурикитаплары, портреты, тактада яки экранда — дәрестә кирәк булачак таныш түгел сүзләр, магнитофон, шигырь язылган аудиодиск.

**Д ә р е с   б а р ы ш ы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Яхшы кәеф, сәламәтлек, укучыларның кадерле кешеләре — эти-әниләренә дә сәламәтлек теләп, дәресне башлау.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү — «Әтәч белән Сандугач» мәсәлен рольләргә бүлеп уку.

2) — Мәсәлнең авторы кем? Аның турында нәрсәләр исегездә калды? Бу шигырьдә шагыйрь әйтергә теләгән төп фикер нәрсә?

3) Тагын нинди мәсәлләр (мәсәлчеләр) беләсез? Өйдә өстәмә укыган мәсәлләр буенча кыскача фикер алышу.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Мәҗит Гафуриның «Ана» шигырендә ана һәм бала кадере.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую:

а) Шигырь белән танышырга, төп фикерне аңларга, матур итеп укырга өйрәнергә кирәк.

ә) Бу шигырь эчтәлеге буенча узган дәресләрдә өйрәнгән нинди шигырьләр белән аваздаш?

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Шигырьне аңлауга әзерлек.

— Шигырь «Ана» дип атала. Сезнеңчә, ул кем турында? Шагыйрь әниләр турында нәрсәләр язды икән? Үз фикерләрегезне әйтегез, шигырьне укыгач, чагыштырырбыз.

Дәреслектәге сүзлекчә белән эш.

2. Шигырь белән эшләү.

1) Дисктан яки укытучы укуында шигырьне тыңлау. Беренчел аңлауны тикшерү (шигырьдә әниләр турында нәрсә сөйләнә? Монда кем кадерле?)

2) Шигырьне русчага сүзгә-сүз тәрҗемә итеп уку, аңлау.

3) Укучыларның шигырьне ярымтавыш белән укуы.

4) Чылбыр буенча сәнгатьле уку.

5) Телдән шигырьне аңлауны ныгыту.

*В какой строчке говорится о том:*

*— что мама воспитывала ребёнка (тебя);*

*— что ты очень много плакал, спал, не смеялся;*

*— что улыбнулся первый раз;*

*— если ты начинаешь плакать;*

*— как радовалась мама, когда ты начал ходить;*
*— качая, напевая;*
*— увидев лицо своей матери и др.*

3. Дәреслектәге сораулар һәм биремнәрне башкару.
4. Эш дәфтәрендәге 1, 2 нче биремнәрне эшләү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? М.Гафуриның «Ана» шигыре нәрсә турында? Ул бу шигыре белән балаларга нәрсә әйтергә теләгән? «Ана теле», «родной язык» дигән төшенчәләрне ничек аңлыйсыз? Сез алда өйрәнгән кайсы әсәр белән бу шигырьнең кайсы строфасы арасында бәйләнеш таптыгыз? (Г.Тукайның «Туган тел» шигыре.) Бу төшенчә кадерлеме?
2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.
3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) Г.Моратның «Чит тел» шигырен укырга;

б) эш дәфтәренә бишек җыры язарга (рус телендә булса да ярый).

## 16 нчы дәрес

**Тема:** Габдулла Тукайны биргән, җырларда җырланган ямьле Казан арты...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т —географик картадан Тукай туган, яшәгән җирләрне, поэмадагы «Казан арты» дигән урынны таба белү, аңлау.

П р е д м е т — Г.Тукай турында 5 нче сыйныфта өйрәнгәннәрне искә төшерү, тулыландыру, «Шүрәле»поэмасының 1 нче өлеше белән танышу.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — поэмада сурәтләнгән урман матурлыгы, урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре аша экологик тәрбия бирү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 59—61 нче битләр), эш дәфтәрендә 14—17 нче битләр.

**Җиһазлау:** Г.Тукай портреты, китаплары, мультимедиа проекторы, экран (такта), шагыйрь турында фильм, Г.Тукай турында презентация, Татарстан картасы, слайдларда — поэмадагы җөмләләргә туры килә торган урман рәсемнәре.

## Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: 1) парларда бер-берсенә «Ана» шигырен сәнгатьле уку; 2) язып килгән бишек җырларын сыйныфташларына уку.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасы — Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасы.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую:

а) Г.Тукайның биографиясен искә төшерү, яңа белемнәр белән тулыландыру;

ә) «Шүрәле» поэмасының 1 нче өлешен уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Г.Тукайның биографиясен искә төшерү.

1) Г.Тукай турындагы интерактив китап яки презентация карау, укучыларның алда өйрәнгәннәрен хәтердә яңарту;

2) Тукай биографиясе турында сорауларга җавап бирү (эшне төркемнәрдә оештырырга мөмкин: һәр сорауга төркемнәр җавап бирә, кемнең дөрес җаваплары күбрәк?)

— Г.Тукай кайда туган? (Арча районы, Кушлавыч авылы.) Картадан табарга.

— Г.Тукай кайчан туган? (1886 ел, 26 апрель.)

— Әтисе-әнисе турында нәрсәләр беләсез?

— Г.Тукай кайларда яшәгән? Тактадагы (экрандагы) модель буенча кайда, ничек яшәгәненә тукталу. Татарстан картасыннан бу авылларны, шәһәрләрне табу.

Кушлавыч ⟶ Сасна Пүчинкәсе ⟶ Өчиле ⟶ Казан ↘

Өчиле

Казан ⟵ Җаек (Уральск) ⟵ Кырлай ↙

2. «Шүрәле» поэмасын укуга әзерлек.

1) — Шүрәле — Г.Тукай уйлап тапкан образмы? (Татар мифларында бар.)

2) Дәреслектәге сүзлекчә белән эш: укытучы артыннан һәр сүзне дөрес итеп кабатлау, тәрҗемә итү, сүзтезмәләр төзү.

3. «Шүрәле» поэмасы белән танышу.

1) Укытучы укыганны яки дисктан 1 нче өлешне тыңлау.

2) — Сүз нәрсә турында бара? Табигать турында нәрсәләр язган,ниләр аңлашылды? Шүрәле турында бу өлештә язылганмы?

3) Укучылар үзләре укып чыгалар.

— Тагын нәрсәләр аңладыгыз?

4) Әкият-поэманың һәр юлын уку, русчага сүзгә-сүз тәрҗемә итү.

5) Укучыларның ярымтавыш белән укуы, сәнгатьле укуга әзерлек.

6) Әсәрне укучыларның чылбыр буенча укуы.

7) Дәреслектәге сораулар һәм биремнәрне үтәү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Г.Тукай турында нәрсәләр белдегез? (Тактадагы үрнәккә карап, җавап бирәләр.)

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) поэмадан өзекне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) эш дәфтәрендәге биремнәрне эшләргә (16—17 нче битләр, 1, 2 нче биремнәр);

б) урманда нәрсәләр эшләргә ярый, ә нәрсә эшләргә ярамый икәнлеге турында язарга (эш дәфтәрендә).

## Укытучы өчен өстәмә материал

Габдулла Тукай Казан губернасы Кушлавыч авылында указлы мулла Мөхәммәтгариф белән мулла кызы Бибимәмдүдә гаиләсендә дөньяга килә.

Габдулла Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф 44 яшендә вафат була. Әтисе үлгәндә, Габдуллага дүрт ай ярым була.

Әнисе Бибимәмдүдә Габдулланны Шәрифә исемле фәкыйрь бер карчыкка вакытлыча асрамага биреп калдырып, Сасна Пүчинкәсе авылының мулласы Мөхәммәтшакирга икенче мәртәбә кияүгә чыга. Бу вакытта Габдуллага ике яшь тә сигез ай була.

1889 елның язында әнисе Бибимәмдүдә Габдулланы үз янына Сасна Пүчинкәсенә алдырта. Ул анда бер елга якын тора. 1890 елның кышында Бибимәмдүдә 26 яшендә вафат була.

Әнисе вафат булганнан соң, Габдулла яңадан **Өчилегә —** бабасы Зиннәтулла йортына кайтарыла. Бабасы белән үги әбисе Габдулланы, бер авыл ямщигына утыртып, **Казанга** озаталар. Казанга озатылу

моменты турында ул болай яза: «Ямщик Казанга килеп җиткәч, Печән базарында: «Асрамага бала бирәм, кем ала?» — дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктан алган... Миңа эти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Алар Яңа бистәдә торганнар».

1892 елның башында Мөхәммәтвәли белән Газизә, каты авырып киткәнлектән, үзебез үлсәк, бу бала кемгә калыр, дип куркып, Габдулланы бер ямщикка утыртып, яңадан **Өчилегә** — бабасы Зиннәтулла өенә кайтарып җибәрәләр.

Июнь урталарында бабасы Зиннәтулла Габдулланы **Кырлай** авылы кешесе Сәгъдигә асрамага биреп җибәрә.

Кырлай — Габдулла Тукай иҗатына билгеле бер эз салган авыл, үзе әйткәнчә, «минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным». «Шүрәле» поэмасында, «Туган җиремә», «Туган авыл» шигырьләрендә ул Казан артын аерым бер мәхәббәт белән сурәтли.

Тукай гыйлем дөньясына беренче адымны 1892 елның көзендә Кырлайда ясый. 1893 елның көзендә Габдулла, абыстайда укуын төгәлләп, мәдрәсәгә күчә. Мәдрәсәдә «Һәфтияк», «Бәдавам», «Кисекбаш» китапларын бик җиңел үзләштерә. Ул бу мәдрәсәдә Уральскига киткәнче укый.

Уральскидагы җизнәсе Галиәсгар Госмановның чакыртуы буенча, Кушлавыч крестьяны Бәдретдин абзый Габдулланы Кырлай авылыннан **Уральскига** алып китә.

Анда ул 1894 елның ахырында килеп җиткән. Тукай 27 еллык гомереннең зур өлешен шушы шәһәрдә үткәрә. Уральск — аның зур шагыйрь буларак формалашкан шәһәре.

1895 елны Габдулланы җизнәсе Галиәсгар Госманов «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә укырга бирә. Ә 1896 елның көзендә Тукай өч еллык рус классында укый башлый.

Габдулла Тукай «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыганда, шигырьләр чыгара башласа да, татар телендә газета-журналлар булмау сәбәпле, аларны яттан гына әйтеп йөргән.

1904 ел урталарында Камил Мотыгый Төхвәтуллин Уральскида атнага бер мәртәбә кулъязма «Әлгасрелҗәдит» журналы чыгара башлый. Тукай — бу журналга язучыларның берсе, журнал идарәсендә редколлегия әгъзасы. Шигырьләре һәм мәкальләре беренче тапкыр шушында дөнья күрә.

1907 елның көзендә Габдулла Тукай Уральскидан **Казанга** чыгып китә. Ул Казанга килеп җитә һәм «Болгар» номерының өченче катында 40 нчы бүлмәгә урнаша. Тукай Казанда Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев һәм башкалар белән таныша.

1907 елның ноябрь аенда Габдулла Тукайның беренче шигырь җыентыгы чыга. Бу җыентыкка «Шүрәле» поэмасы, «Пар ат», «Шагыйрьгә» һәм башка шигырьләре керә.

Габдулла Тукай Казанга Уральскидан үпкә авыруы алган килеш килә. Казанда табиб аңарда икенче стадия үпкә авыруы таба. Ләкин шагыйрь авыруына әллә ни игътибар итми, дәваланмый.

1908 елның башында «Габдулла Тукаев шигырьләре» дигән икенче җыентыгы басылып чыга. 1909 елда тагын бер җыентыгы дөнья күрә.

1913 ел башында, сәламәтлегенең көннән-көн начарлана баруына карамастан, Тукай күп эшли. «Ялт-йолт», «Аң» журналларында, «Кояш» газетасында әледән-әле аның әсәрләре чыгып тора. Иптәшләре аны Клячкин больницасына озаталар. Ләкин Тукай анда да үзенең әсәрләрен язуны дәвам итә.

2 апрельдә татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның йөрәге тибүдән туктый.

Г.Тукай турында мәгълүмат булган сайтлар:

http://igravsadu.blogspot.ru/p/application.html — Г.Тукай тормышы, иҗаты буенча интерактив кроссвордлар

http://gabdullatukay.ru/ — Г.Тукайга багышланган Интернет-портал

## 17, 18 нче дәресләр

**Тема:** Барыбызга да «таныш» Шүрәле.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — «аршын» (аршин) сүзенең мәгънәсен аңлау, кайда кулланылышы турында белү, рәссам Б.Әлменов картинасы белән танышу.

Предмет — шагыйрь Г.Тукай биографиясен истә калдыру, «Шүрәле»поэмасының 2, 3 нче өлешләре белән танышу.

Шәхескә кагылышлы — экологик тәрбия бирү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 61—66 нчы битләр), эш дәфтәрендә 14—18 нче битләр.

**Җиһазлау:** Г.Тукай портреты, мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар: Тукай тормышыннан фактлар (портрет, туганнарының рәсемнәре, яшәгән җирләре — схема, «Шүрәле» поэмасы тышлыклары, Б.Әлменовның «Шүрәле» картинасыннан репродукция).

### Дәрес барышы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: эш дәфтәрендәге биремнәргә аңлатма (укучыларда нинди сораулар туган, кем ничек башкарган).

2) Г.Тукай тормышын, иҗатын искә төшерү:

— Бала чагы нинди булган? Тормышы? Ни өчен экият-поэмалар язган дип уйлыйсыз? Ни өчен «Шүрәле» поэмасында Кырлай турында күп итеп, матур итеп язган?

3) Эш дәфтәрендәге 14—15 нче биттәге биремнәрне үтәү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасы.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую: «Шүрәле» поэмасыннан өзекләрне сәнгатьле уку, аңлау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Поэманың 2, 3 нче өлешләрен укырга әзерлек.

Дәреслектәге сүзлекчә белән танышу. Укытучы дөрес итеп укыганны тыңлау, кабатлау. Дөрес уку һәм тәрҗемә итү. Сүзләр белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзү.

2. Әсәр белән эш.

1) Шигъри әсәрне диктор яки укытучы сәнгатьле укыганны тыңлау.

2) Эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү:

— Бу өлештә нәрсә турында сүз бара?

— Вакыйга кайда бара?

— Кемнәр катнаша? Алар нишлиләр?

— Егет нинди? Шүрәле нинди?

3) Поэманы уку, һәр юлын сүзгә-сүз тәрҗемә итү.

4) Укучылар эчтән яки ярымтавыш белән укыйлар, кычкырып укырга әзерләнәләр.

5) Әсәрне чылбыр буенча сәнгатьле уку.

6) Сайлап уку:

— *найдите строчки, где говорится, что джигит пошёл в лес и т.д.*

— *найдите строчки, в которых описывается ночной лес, Шурале и т.д.*

— *найдите предложения, которые подходят к рисунку и т.д.*

7) Шүрәле белән егетнең сөйләшүен рольләргә бүлеп уку.

8) Дәреслектәге һәр өзектән соң бирелгән сорауларга җавап, биремнәрне үтәү.

9) Эш дәфтәрендәге биремнәрне үтәү (14—18 нче битләр).

10) «Шүрәле» мультфильмын карау (яки, өйдә карап килеп, фикер алышу):

— Мультфильм эчтәлеге әкият-поэма эчтәлеге белән туры киләме? Нинди аерма бар?

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Тукайның Шүрәлесе нинди  герой: уңаймы, тискәреме (бәлки, ул шулай урманны саклыйдыр)? Егет дөрес эшләдеме? Хәзер кешеләр Шүрәледән куркамы? Бу начармы, яхшымы? һ.б.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) поэмадан өзекне сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) эш дәфтәрендәге биремнәрне эшләргә;

б) «Шүрәле» поэмасының кыскача эчтәлеген сөйләргә (эш дәфтәрендәге җөмләләрне кулланып).

4. Алдагы дәрескә уку мәсьәләсе кую:

— Шүрәле белән бәйле нәрсәләр бар? (Парк, балет һ.б.)

**Укытучы өчен өстәмә материал**

Аршин — старорусская единица измерения длины.

1 аршин = 1/3 сажени = 4 четверти = 16 вершков = 28 дюймов = 0,7112 м; устаревшая мера длины.

«Самый прут, палочка, тесьма ровно в эту меру» — Толковый словарь живого великорусского языка Даля.

«Линейка длиною в один аршин с нанесёнными на ней делениями, служащая для измерения. Деревянный. Складной» — Толковый словарь русского языка Ушакова.

Пословицы и поговорки

* «Аршинными буквами» (писать) — крупно.

* Ходит (сидит, кланяется) «словно аршин проглотил» — не сгибаясь, навытяжку.

* «Аршин на кафтан, два на заплаты» (вычинка дороже вещи).

* «Аршин не солжёт» (мера — делу вера).

* «На свой аршин мерить».

## 19 нчы дәрес

**Тема:** Дөньяларны гизгән Шүрәле.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — «балет», «либретто», «балетмейстер» төшенчәләрен белү.

П р е д м е т — Г.Тукайның «Шүрәле»сенә балет язылуы, аның эчтәлеген белү, авторы композитор Ф.Яруллин турында мәгълүматлы булу.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — эстетик тәрбия бирү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 66—68 нче битләр), эш дәфтәрендә 19—20 нче битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар: Г.Тукай, Ф.Яруллин, З.Яруллин, Ә.Фәйзи, Л.Якобсон портретлары, балеттан күренешләр яки балеттан видео өзекләр (utube видеохостингтан алырга мөмкин).

## Д ә р е с б а р ы ш ы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: а) эш дәфтәрендәге биремнәрне күзәтү, фикер алышу; ә) «Шүрәле» поэмасының кыскача эчтәлеген сөйләү (эш дәфтәрендәге гади җөмләләр белән).

2) — Шүрәле белән бәйле нәрсәләр таптыгыз? («Шүрәле» балеты, Кырлай паркы, «Сөйкемле Шүрәле», «Шүрәле биштәре» конкурслары, скульптуралар, рәссамнарның картиналары һ.б.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасына нигезләнеп иҗат ителгән «Шүрәле» балеты.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую:

а) «Шүрәле» балетының авторлары белән танышу;

ә) «Шүрәле» балетының эчтәлеге белән танышу (Поэма белән тәңгәл киләме? Мультфильмда аермалыклар күргән идек һ.б);

б) «Нәрсә ул балет?» соравына җавап бирү.

### II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. «Балет» теоретик төшенчәсен аңлату.

1) — Нәрсә ул балет? Укучыларның фикере тыңлана.

2) Дәреслектән балет турында теоретик төшенчә укыла.

— Димәк, балет сәхнәгә куелсын өчен, кемнәр иҗат итәргә тиеш? (Композитор, драматург, балетмейстер.)

2. «Шүрәле» балеты, аның авторлары белән танышу.

1) Дәреслектәге биографияне уку: абзацны укучылар укый-

лар, үзләре аңлаганча сорауларга җавап бирәләр. (Кем турында язылган? Ул кайчан туган? һ.б.)

2) Һәр җөмләне чылбыр буенча уку, сүзгә-сүз тәрҗемә итү.

3) Эш дәфтәрендәге таблицаны тутыру (Ф.Яруллинның биографиясе буенча).

4) — Таблицаны тутыру өчен, нәрсәләр белмибез? (Дәреслектән балет турында уку, тәрҗемә итү, таблицаны тутыру.)

5) Видеода балеттан өзекләр карау.

3. Дәреслектәге сораулар һәм биремнәр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Балет турында аңлашылдымы? «Шүрәле» балетының авторлары кем? Эчтәлеге нәрсә белән аерыла?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) балетны театрда яки Интернет челтәреннән карарга;

ә) эш дәфтәрендәге биремнәрне эшләргә;

б) «Шүрәле» балетының кыскача эчтәлеген сөйләргә (эш дәфтәрендәге җөмләләрне кулланырга була).

## 20—21 нче дәресләр

**Тема:** Чәчәкләр — матурлык һәм үлемсезлек символы.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — тарихтан Бөек Ватан сугышы чоры турында белү.

Предмет — М.Җәлил биографиясен искә төшерү, сугыш чоры иҗаты белән таныштыру, «Чәчәкләр» шигырен аңлап уку, символ, «строфа» төшенчәләре белән танышу.

Шәхескә кагылышлы — туган илне ярату, туган илне саклау — мактаулы икәнен аңлау.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 69—76 нчы битләр), эш дәфтәрендә 20—22 нче битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), М.Җәлил тормышы турында презентация, М.Җәлилнең шигырь җыентыклары, слайдлар: чәчәкле болын күренешләре, һәйкәлләр рәсемнәре, нәркис, сөмбел, мәк рәсемнәре.

## Дәрес барышы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: «Шүрәле» балетының эчтәлеге буенча фикер алышу (өйдә сөйләргә өйрәнгән балалар татарча сөйли, кемдер сорауларга русча җавап бирә, кемдер татарча җөмләләр төзи һ.б.)

2) «Шүрәле» балеты буенча әңгәмә.

— Нәрсә ошады? Балет кайсы илләрдә һәм шәһәрләрдә куелган? (Опера һәм балет театрында, чит илләрдә, Россиянең күп шәһәрләрендә.) Бу театр кем исемен йөртә? М.Җәлил турында нәрсәләр беләсез?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы: «Чәчәкләр — матурлык һәм үлемсезлек символы». (М.Җәлил иҗаты белән танышу, 5 нче сыйныфта өйрәнгәннәрне тулыландыру, «Чәчәкләр» шигырен уку.)

— Темада язылган җөмлә белән килешәсезме? М.Җәлил белән бәйләнеш бармы? (Чәчәкләр матур, Җәлил матурлык яраткан, Җәлилне онытмыйлар, һәйкәленә чәчәкләр китерәләр, шул исемдә шигыре дә бар.)

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую:

а) М.Җәлилнең тормыш юлын, иҗатын өйрәнергә;

ә) «Чәчәкләр» шигырен укырга, аңларга;

б) «символ», «строфа» теоретик төшенчәләрен истә калдырырга.

### II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Шагыйрьнең иҗаты, тормыш юлы, музее турында мәгълүмат бирү.

1) М.Җәлилнең тормыш юлы турында презентация карау.

2) Укучылар, 5 нче сыйныфта өйрәнгәннәрне искә төшереп, пре-зентациядә күргәннәрне өстәп, шагыйрьнең тормыш юлы турында җөмләләр әйтәләр.

3) Укытучының М.Җәлил турында, бигрәк тә сугыш чоры, Моабит дәфтәрләре турында сөйләве (яңа мәгълүмат өстәп, тулыландырып).

4) Дәреслектән М.Җәлил турында уку.

5) — Шагыйрьнең тормышы турында тулырак кайдан белә алабыз? (Китаплары, музей.) Казанда М.Җәлилнең музей-квартирасы бар. Дәреслектән уку, тәрҗемә итү. Укытучы тулыландыра яки музей сайтындагы фотосурәтләргә күзәтү ясый.

2. «Чәчәкләр» шигыре белән эш.

1) — Ничек уйлыйсыз, шигырь нәрсә турында икән? (1943 елның ноябрендә языла.) (Укучыларның фикерләре.)

2) Сүзлекчә белән эш: дөрес әйтеп укуны тыңлау, кабатлау, сүзтезмәләр, җөмләләр төзеп, аңлауны ныгыту.

3) Шигырьне диктор башкаруында тыңлау яки укытучының сәнгатьле укуы.

4) — Шигырь нәрсә турында? Нәрсәләр аңладыгыз?

5) Шигырьне яңадан уку, һәр юлын русчага сүзгә-сүз тәрҗемә итү.

6) Укучыларның эчтән яки ярымтавыш белән укулары.

7) Чылбыр буенча сәнгатьле уку.

3. Теоретик төшенчәләр кертү.

— Шигырьне ничек бүлеп укыдыгыз? Ни өчен башкача бүлмәдек? Шигырь теземнәренең төркемләп бирелүе — «строфа» дип атала.

— Шигырь чәчәк турындамы? Нәрсә турында? Чәчәк — символ буларак бирелә.

«Символ» төшенчәсенең аңлатмасын укып, истә калдыру.

4. Шигырьдәге теоретик төшенчәләр белән эш.

Дәреслектәге сораулар һәм биремнәр.

Эш дәфтәрендәге сораулар, биремнәр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? М.Җәлил турында нәрсәләр белдегез? «Чәчәкләр» шигырен аңладыгызмы? Нәрсәләр исегездә калды?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) шигырьнең үзеңә иң ошаган 4 строфасын сәнгатьле укырга әзерләнергә;

ә) беренче 2—3 строфасын яттан өйрәнергә;

б) «Тик булса иде ирек» шигырен укырга.

### Укытучы өчен өстәмә материал

1. 1941 елның июлендә М.Җәлилне гаскәри хезмәткә алалар. Башта ул Казан гарнизонында хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге хәрби сәясәтчеләр әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә немецлар якынлашкач, курслар

Татарстанның Минзәлә шәһәренә күчерелә. 1941 елның декабрендә укуны тәмамлагач, өлкән политрук М.Җәлил Мәскәү аша фронтка озатыла (февраль, 1942). Ул Төньяк-көнбатыш фронтта чыга торган русча «Отвага» («Батырлык») исемле газетаның алгы сызыктагы хәрби редакторы итеп билгеләнә. 1942 елның июнендә, Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, хезмәттәшләре белән бергә чолганышта калып, М.Җәлил каты яраланган хәлендә фашистлар кулына эләгә. Шул көннән аның тоткынлыктагы газаплы һәм каһарманнарча кыюлык белән узган кыска гомер этабы башлана.

М.Җәлил һәм җәлилчеләрнең, яшерен оешма төзеп, фашизмга каршы алып барган каһарманлыклары турында дистәләрчә китаплар — романнар, кыйссалар, драма әсәрләре һәм поэмалар языла, кинофильмнар төшерелә. Иң мөһиме: Җәлил һәм аның көрәштәшләре ахыргы сулышларына кадәр туган халкына турылыклы калып, тиңдәшсез рухи ныклык, батырлык үрнәге күрсәтәләр.

1944 елның февраль аенда Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә (барысы да татарлар) Дрезден шәһәрендә хөкем оештырыла. Хәрби мәхкәмә аларны, «дәүләткә каршы җимерү эше алып бару»да гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләре Абдулла Алиш, Гайнан Курмаш, Фуад Сәйфелмөлеков, Фуад Булат, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Зиннәт Хәсәнов, Абдулла Баттал, Әхәт Атнашев һәм Галләнур Бохараевларның гомерләре өзелә.

Тоткынлык шартларында күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен, М.Җәлилгә, вафатыннан соң (1956 елда), «Советлар Союзы Герое» дигән исем бирелә, ә әсирлектә тудырган поэтик иҗаты — бөтен дөньяга мәгълүм «Моабит дәфтәрләре» өчен, СССРның ул вакыттагы иң зур бүләге — Ленин премиясенә лаек була.

«Моабит дәфтәрләре» — Җәлил шигъриятенең иң югары ноктасы. Моабит шигырьләрендә шагыйрьнең шәхси образы, кичерешләре, фәлсәфи уйланулары аша кеше рухының бөеклеге, гуманистик табигате, гаделлек һәм хаклык тантанасына тирән ышанычы, туган халкына чиксез мәхәббәте гаҗәеп тәэсирле, эмоциональ көч һәм сәнгатьчә камиллек белән гәүдәләнә. Моабит шигырьләре, Россиядәге барлык милли телләргә тәрҗемә ителүдән тыш, инглиз, француз, испан, немец, гарәп, төрек, кытай, япон, мадьяр (венгр), румын, чех һәм башка чит ил халыклары телләрендә дә кат-кат матбугатта басыла.

2. Символ (гр. *symbolon* — танытучы билге) — универсаль сәнгати һәм мәдәни категория. Бер яктан — әдәби образ, икенче яктан, билге сыйфатларын үзенә туплый. Һәр символ — ниндидер мәгънә белдерүче, шул мәгънә белән кушылган, ләкин аның белән чикләнми торган образ ул. Символ да эчтәлек — формага, форма эчтәлеккә күчә, икепланлы бөтенлек туа: аның форма тарафыннан белдерелүче катламы — морфема, формадан зуррак катламы метаморфема дип атала.

## 22 нче дәрес

**Тема:** Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — катлаулы текст белән эшли, иң әһәмиятлесен таба белергә өйрәнү.

Предмет — Ә.Еники иҗаты белән танышу, «Туган туфрак» әсәрен укый башлау.

Шәхескә кагылышлы — өлкән буынга ихтирам, туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 77—81 нче битләр), эш дәфтәрендә 23 нче бит.

**Җиһазлау:**мультимедиа проекторы, экран (такта), Ә.Еники тормышы, иҗаты турында презентация.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: «Чәчәкләр» шигырен (2—3 строфасын) яттан сөйләү яки сәнгатьле уку.

2) — «Тик булса иде ирек» шигыренең төп темасы, фикере нәрсә? (Туган җирне, якыннарын сагыну, аларны яклап сугышу.) Әдәбиятта туган җир темасы бик күп әсәрләрдә чагыла. Ни өчен кешегә Туган ягы кадерле икән? (Укучыларның фикерләре.)

— Туган җир турында күп иҗат иткән тагын бер бөек язучы — Әмирхан Еники.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең максаты — Ә.Еникинең «Туган туфрак» хикәясе белән таныша башлау.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую:

а) Ә.Еникинең тормыш юлы, иҗаты белән танышырга;

ә) «Туган туфрак» хикәясенең 1 нче өлешен укырга, аңларга.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Язучының иҗаты, тормыш юлы турында мәгълүмат.

1) — Ә.Еники турында ишеткәнегез бармы? (Аның исемендә урам да бар.)

2) Язучы турында презентация карау яки укытучының аның портретын, китапларын күрсәтеп сөйләве.

3) Дәреслекнең 77 нче битендәге биографик белешмәне уку.

2. «Туган туфрак» хикәясенең 1 нче өлешен уку.

1) Сүзлек эше: 80 нче биттәге сүзләр белән танышу. «Бу сүзләр ярдәмендә эчтәлек турында белеп буламы?» — дип, укучыларны кызыксындыру.

2) 1 нче абзацны укытучы сәнгатьле итеп укый, укучылар тыңлыйлар.

— Кем турында сүз бара? Вакыйга кайда бара?

3) 1 нче абзацның һәр җөмләсен уку, сүзлекчәне кулланып, сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү.

4) 1 нче абзацның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү: китаптан табып уку яки кыскача үз сүзләре белән сөйләү (Төп геройлар кемнәр? Клара кайда яши? Бабай кайда яшәгән? Клара авылда булганмы? Кайчан? Ул анда нишләгән? Кларага авыл ошаганмы? Бабасы Кларага нәрсә әйтә? Клараның авылга барасы киләме? «Безнең Каракош» — нәрсә дигән сүз?).

5) 2 нче абзац белән шул ук тәртиптә эшләү. Сорауларга җавап бирү (Бабасы Каракошта нәрсәне сагына? Клара бабасының сагынганын каян белә? Клара, бабасын тыңлагач, нәрсә уйлый? Бабасы ничек яшәгән, аның нәрсәләре булган?).

6) Һәр абзац белән танышып чыккач, дәреслектәге сораулар һәм биремнәр белән эшләү.

3. Эш дәфтәрендәге таблицаны тутыру (1 нче бирем).

**III. Рефлексив бәяләү.**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Ә.Еники турында нәрсәләр белдегез? «Туган туфрак» хикәясенең исеме ни өчен шулай, аңладыгызмы? Клара авыл турында дөрес уйлыймы? Ни өчен ул авылга кайтып китә? Анда нәрсәләр булыр, ничек уйлыйсыз?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) әсәрнең үзенә ошаган абзацын сәнгатьле укырга өйрә-нергә, шул өзек буенча 2 сорау төзергә;

ә) эш дәфтәрендәге 2 нче биремне үтәргә;

б) эш дәфтәренә үз бабалары турында сорауларга җавап язарга (3 нче бирем).

## 23—25 нче дәресләр

**Тема:** Әби-бабайларның туган җире оныкларга кадерлеме?

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — план төзи белү.

Предмет — «Туган туфрак» әсәрен уку, аңлау, автор Ә.Еники турында мәгълүматлы булу, әсәрдән өйрәнгән тропларны, символик образларны таба белү.

Шәхескә кагылышлы — өлкән буынга ихтирам, туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 81—88 нче битләр), эш дәфтәрендә 23—25 нче битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), Ә.Еникинең тормышы, иҗаты турында презентация, слайдларда авыл күренешләре.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Һәр дәрестә яңа бүлекне укый башлаганчы, хикәянең авторы Ә.Еники турында, алда укылган бүлекләр эчтәлеге буенча кыска әңгәмә.

3) Алга таба вакыйгалар ничек барыр дип уйлыйсыз? (Укучыларның үз фикерләрен тыңлау, яңа бүлекне укырга кызыксыну уяту.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәреснең темасын, дәрескә бурычларны бергәләп кую.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү этабы.**

Бу дәресләрнең һәркайсында хикәянең яңа бер бүлеге укыла.

1. Яңа текстны укырга әзерләү: сүзлекчә белән эшләү (дөрес әйтелешне тыңлау, кабатлау, тәрҗемә итү — башта үзләре уйлаганча, аннары дөреслеген тикшерәләр яки тәрҗемәсен китаптан карыйлар).

Яңа сүзләр белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзү.

2. Яңа текстны тыңлау (тәрҗемәсез, анализсыз гына). Укучылар башта әйткән фикерләр туры киләме?

— Нәрсә турында сүз бара?

3. Һәр абзацны уку, тәрҗемә итү яки эчтәлекне аңлаганны тикшерү өчен гади сораулар бирү.

4. Дәреслектәге сораулар һәм биремнәрне үтәү. Укучылар үз фикерләрен башта русча әйтергә мөмкин, аннары татарча әйтәләр.

5. Эш дәфтәрендә һәр бүлеккә биремнәр тәкъдим ителә. Биремнәр кыскача эчтәлекне бирә торган, укучыларга истә калдырырга җайлы җөмләләр белән бара. Бер үк сүзләрнең, җөмләләрнең берничә тапкыр кабатлануы эчтәлекне һәм сөйләм материалын истә калдырырга ярдәм итә. Көчлерәк төркемнәрдә укытучы үзе телдән тагын охшаш биремнәр әзерләсә, отышлы булыр.

Дәресләрдә телдән күп эшләнсә, укучылар, мәҗбүри бирем булмаса да, гади җөмләләр белән, укылган әсәрнең (бүлекнең) кыскача эчтәлеген сөйли алалар.

6. Әсәрдәге символик образларны табарга тырышу (укучылар өчен авыр, бергәләп эшләргә кирәк).

Туган туфрак (нигез) — үткән белән бүгенгене тоташтыра, дәвамчылык.

Бабасы сагынган каен — ялгызлык.

Авылда яшьлекнең аз булуы — чынбарлыкны яхшыга үзгәртергә кирәклеген тою.

Тауга менү теләге — көчле кичерешләр, Кларанның эчке дөньясындагы үзгәрешләр.

7. Ә.Еникинең бу әсәрендә сюжет сызыгы — анда бара торган вакыйгалар түгел, Кларанның кичерешләре. Аның эчке дөньясы каршылыклы: аңа яңа дөреслекләр ачыла. Башта «туган туфрак» төшенчәсен бөтенләй танымаган кыз тау башыннан Каракош авылын күрүгә сөенә, үзен бәхетле хис итә.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? (Һәр дәрес башында куелган уку мәсьәләсе үтәлдеме, максатка ирештекме — йомгак ясыйбыз).

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) әсәрнең үзеңә ошаган абзацын сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) эш дәфтәрендәге биремнәрне эшләргә;

б) бүлектә нинди вакыйгалар булды, нәрсә турында әйтелә — үз сүзләрегез белән сөйләргә.

## 26 нчы дәрес — йомгаклау, кабатлау дәресе

**Тема:** «Кадерле син, Кеше туганым!» бүлеген йомгаклау.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**: әлеге бүлектә укылган әсәрләрне истә калдыру, бу әсәрләрдә күтәрелә торган проблема — туган җирне ярату, туган як кадере, иң якын кешеләребезнең кадере турында аңлап калу.

### Дәресне оештыру вариантлары:

1. Һәр әсәрнең эчтәлеген бергәләп искә төшерү, язучының әйтергә теләгән фикерен ассызыклап үтү.

2. Төркемнәргә бүленеп, һәр төркемнең бер әсәрне «яклавы» — төп фикерне ачуы, алдан әзерләнеп чыгыш ясавы.

3. Бу бүлектә үткән әсәрләрнең бер-берсе белән бәйләнешен ачыклау. Һәркайсының бүлекнең төп темасын ничек ачуын күрсәтү.

4. Төркемнәргә бүленеп, викторина, ярыш, «Тапкырлар, зирәкләр клубы» (КВН) формасында бу әсәрләрне үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.

* Вакыт калса, И.Юзеевның «Бакчачы турында баллада»сы белән танышырга яки, өйдә мөстәкыйль укып, эш дәфтәрендәге биремнәрне үтәргә була.

## 27 нче дәрес

**Тема:** Энҗе карлар явып үткән...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — тексттан кирәкле мәгълүматны табарга өйрәнү.

Предмет — Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Кар ява» әсәрен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — табигатькә карата күзәтүчәнлек тәрбияләү, һава торышының үзгәрешен аңлау, татарча дөрес репликалар белән аңлата белү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 94, 95 нче битләр), эш дәфтәрендә 27, 28 нче битләр.

**Җиһазлау:** Г.Ибраһимовның портреты, китаплары, альбомы, тормышын һәм иҗатын чагылдырган презентация.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Язучыларны портретлары буенча тану, татар язучыларының исем-фамилияләрен хәтердә калдыру өчен, портретлар белән эшләү шактый отышлы. Гадәттә, татар теле кабинетларында язучыларның портретлары була.

— Бу кемнең портреты?

— Бу — Габдулла Тукай.

— Аның турында нәрсәләр беләсез? һ.б.

— Бу кемнең портреты?

— Бу — Илдар Юзеев.

— Без аның нинди әсәрен укыдык?

— «Бакчачы турында баллада» әсәрен.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Ә бу кем? (Укытучы портрет күрсәтә, укучылар әйтә алмыйлар.)

— Бу — язучы Галимҗан Ибраһимов. Бүгенге дәрестә без Г.Ибраһимовның иҗаты белән танышырбыз һәм аның «Кар ява» дигән әсәрен укырбыз.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу. Укытучы, Интернет челтәре материалларын файдаланып,презентация аша һәм язучының китапларын күрсәтеп, аның тормышы, иҗаты белән таныштыра.

2. Сүзлек белән эш.

3. Даталарны дөрес әйтергә өйрәтү:

— туган елы — 1887 ел;

— беренче хикәясе — 1907 елда языла;

— «Яшь йөрәкләр» романы — 1912 елда языла;

— «Көтүчеләр», «Табигать балалары» әсәрләре — 1912 — 1914 елларда дөнья күрә.

4. Автор турында дәреслектәге белешмәне эчтән укырга тәкъдим ителә; аңлаганны тикшерү өчен, сорауларга җавап алына. (Г.Ибраһимов кайчан һәм кайда туган? Кайда укыган? Аның язган әсәрләрен әйтегез.)

96 нчы биттәге 1, 2 нче биремнәр эшләнелә.

5. Г.Ибраһимовның «Кар ява» текстын өйрәнү.

1) Экранда кар яву күренешен тасвирлаган рәсем күрсәтелә.

— Бу кайсы вакыт? (Кыш.)

Укучылар рәсем буенча җөмләләр төзеп әйтәләр. (Кар ява. Агачларда кар; кар көртләре өелгән һ.б.)

2) — Бу күренешне Г.Ибрагимов ничек тасвирлаган? (Укытучы «Кар ява» текстын укый. Аңлашылмаган сүзләр тикшерелә, искә төшерелә.)

3) Сорауларга тексттан табып җавап бирү.

— Кар кайчан ява башлаган?

— Җир йөзе — *всё в округе* дип тәрҗемә ителә. Бу сүз белән текстта нинди җөмлә бар? Үзегезнең җөмләне төзеп әйтегез.

— Болытлар нигә түбәнгә салына башладылар?

4) 95 нче биттә бирелгән сүзләрнең тәрҗемәсен әйтү һәм тексттан эзләп табу, үз җөмләләрен төзү.

5) Тексттан сыйфатларны табып, тәрҗемәсен әйтү.

6) — Кар нинди? Яланнар нинди? Сүзтезмәләр төзеп әйтү. *(Ап-ак кар, киң яланнар, биек таулар, яңа матурлык, яңа йомшак кар, ак мамыктай, калын-калын болытлар, зур елгалар.)*

6. Биремнәр һәм сораулар, эш дәфтәрендә эшләү.

7. Текстны сәнгатьле итеп уку.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау.

— «Кар ява» хикәясе нәрсә турында? Ул сезгә ошадымы?

— Кышкы табигать турында диалог төзеп, партадашыгыз белән сөйләшегез, бер-берегезнең сөйләменә бәя бирегез.

2. Бәяләү. Укытучы укучыларның дәрестә катнашулары буенча белемнәренә билгеләр куя.

3. Өй эше: а) «Кыш көне кошлар» темасына җөмләләр төзергә;

ә) өстәмә уку өчен булган «Иң кыен вакыт — шул...» текстын укырга;

б) «Син кошларга ничек ярдәм итәсең?» соравына язма рәвештә җавап бирергә.

## 28 нче дәрес

**Тема**: Мәрхәмәтле булыйк!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — спорт белән бәйләнеш.

П р е д м е т — язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Кызыклы хәл» шигырен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — кыш көне кошлар, хайваннарның көнкүреше, яшәү рәвеше турында белемнәрне ныгыту, аларга игътибарны үстерү, балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләү, экологик тәрбия бирү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 101—103 нче битләр), эш дәфтәрендә 30 нчы бит.

**Җиһазлау:** К.Нәҗминең тормышын һәм иҗатын чагылдырган презентация, дәреслек, эш дәфтәре, әдипләрнең портретлары, кошлар рәсемнәре.

## Д ә р е с  б а р ы ш ы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, һава торышы турында сөйләшү, дәрескә килмәгән укучылар турында белешү, дәресне башлау.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү.

«Кыш көне — кошлар» темасына төзелгән җөмләләрне тыңлау. (Кошлар өчен елның кайсы вакыты иң кыен вакыт? Ни өчен?)

— Кошларга син ничек ярдәм итәсең? (Өй эшенә бирелгән сорауга җавапларны тыңлау.)

Бездә кышлаучы кошларны искә төшерү, русча-татарча атамаларын белүне ныгыту.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы язучылар, шагыйрьләр, гомумән, кешеләрнең табигатьтә яшәүче кошларга, хайваннарга карата битараф булмавын аңлата. Бүгенге дәрестә дә язучы К.Нәҗминең бу темага язылган шигырен өйрәнәсе һәм аның иҗаты белән танышасы барлыгын искәртә.

### II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Автор белән танышу.

1) Интернет челтәреннән файдаланып яки укытучы үзе төзегән презентациясе ярдәмендә К.Нәҗми иҗаты белән таныштыра, китапларын күрсәтә.

2) Бер укучы дәреслектән К.Нәҗми иҗаты турында белешмәне укый.

3) Дәфтәрдә хронологик таблица төзү.

2. Сүзлек белән эш.

1) 102 нче биттәге сүзләрне укытучы укый, укучылар аның артыннан кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучыларга кабатлата.

2) Әйтелеше белән язылышында аерма булган сүзләр тагын бер кат укыла.

3) Яңа сүзләрне тексттан табып, сүзтезмәләрнең мәгънәләрен аңлаганнан соң, җөмләләр төзеп әйтәләр.

3. К.Нәҗминең «Кызыклы хәл» шигырен уку.

1) Беренче кат укытучы укый.

— Шигырь нәрсә турында? — дигән сорауга җавап эзләү (Вилдан һәм аю турында, Вилдан чаңгы ярышында.)

2) Аннары мөстәкыйль рәвештә эчтән уку һәм шигырьне ике өлешкә бүлү.

— Беренче өлеш нәрсә турында?

— Икенче өлеш нәрсә турында?

3) Берничә укучы шигырьне кычкырып укыйлар.

4. Биремнәр һәм сораулар, эш дәфтәрендә эшләү.

1) 102—103 нче биттәге сорауларга җаваплар эзләү.

2) Эш дәфтәрендәге биремнәр эшләнелә.

3) Текст эчтәлеге буенча диалог төзү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау.

— Сез чаңгы шуарга яратасызмы?

— Финишка беренче булып килеп җиткән аю баласы турында сез нәрсә әйтер идегез? (Аю баласы чаңгы шумый.)

2. Бәяләү. Укучыларга билгеләр кую.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга;

ә) укылган шигырьгә иллюстрация ясарга;

б) «Кышын җәнлекләр» темасына иҗади эш.

4. Алдагы дәрескә уку мәсьәләсе кую: ылыслы агачлар турында мәгълүмат табарга.

## 29 нчы дәрес

**Тема:** Чыршыларны саклыйк!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — биология фәне белән бәйләнеш: ылыслы агачлар турында мәгълүмат бирү; проект эшен әзерләргә өйрәнү.

П р е д м е т — М.Фәйзуллинаның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Чыршы күлмәкләре» әсәрен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы — балаларда табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 104—106 нчы битләр), эш дәфтәрендә 31 нче бит.

**Җиһазлау:** М.Фәйзуллинаның тормышын һәм иҗатын чагылдырган презентация, «Кышкы урман» картинасы.

## Д ә р е с б а р ы ш ы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: а) ясалган рәсемнәрдән күргәзмә оештыру, бу рәсемнәр буенча җөмләләр төзү;

ә) «Кызыклы хәл» шигырен сәнгатьле уку.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, кыш көне кошлар, хайваннар һәм үсемлекләрнең яшәеше турында әңгәмә оештыра.

— Сез ясаган рәсемнәрдә чыршыларның ылыслары нинди? (Энә кебек, яшел.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүген дә дәрестә табигать турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен җиткерә. Шагыйрә М.Фәйзуллина иҗаты белән танышачакларын әйтә.

### II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы язучының шигырьләрен, китапларын, портретын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра (презентация).

2) Дәреслектән М.Фәйзуллина турында биографик белешмәне уку, аңлашылмаган сүзләр белән эш.

3) Сорау-җавап рәвешендә укыганны тикшерү, 106 нчы биттәге 1, 2 нче биремнәрне эшләү.

4) Эш дәфтәрендә шагыйрәнең тормыш юлы һәм иҗаты турында хронологик таблица тутыру.

3. М.Фәйзуллинаның «Чыршының күлмәкләре» шигырен уку.

1) Шигырьнең исеме, сүзлекчәдәге сүзләр буенча эчтәлек нинди булырга мөмкинлеге турында фикер алышу — укучыларны кызыксындыру.

1) Укытучының шигырьне сәнгатьле итеп укуы. Тыңлап аңлауны тикшерү. (Шигырьдә төп геройлар кемнәр? Вакыйга кайда бара? һ.б.)

2) Шигырьне чылбыр буенча уку, русчага сүзгә-сүз тәрҗемә итү. Шигырьне башта эчтән укыганнан соң, чылбыр буенча сәнгатьле итеп уку. Дәреслектәге сорауларга җавап бирү.

3) — Шагыйрә нинди проблема күтәрә, бу проблема кайсы юлларда чагылган? (Чыршыларны саклау проблемасын күтәрә.) Чынлыкта мондый проблема бармы? Аны ничек чишеп була? Ылыслы агачлар турында нәрсәләр беләсез? Ни өчен алар кыйммәтрәк саналалар?

3) Табигатьне һәм чыршыларны саклау турында диалог төзү. (Тактада ситуацияләр бирелә: а) дустыгыз Яңа елга чыршы алып кайтулары турында әйтә, сез аңа чыршының файдасы турында әйтегез; ә) диалогта катнашучыларның берсе чыршыны кайдан алу турында киңәш сорый, икенчесе, аңлатып, җавап бирә; б) ике дус чын чыршы һәм ясалма чыршыны чагыштыра, «Бәйрәмгә кайсы яхшырак?» дигән сорауга җавап эзлиләр.)

4. «Чыршыларны саклыйк!» исемле проектка әзерлек эше: төркемнәргә бүленү, һәр төркемнең проект формасын, эчтәлеген сайлавы, өйдә кем нәрсә эшләячәген билгеләү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау.
2. Дәрестәге эшчәнлекне бәяләү. Укучыларга билгеләр кую.
3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга;
ә) эш дәфтәрендә 32 нче биттәге 2 нче биремне эшләргә;
б) һәр төркемгә «Чыршыларны саклыйк!» проекты әзерләргә.
4. Алдагы дәрескә уку мәсьәләсен кую: чыршыларны саклау буенча фикер алышырбыз.

### Укытучылар өчен өстәмә мәгълүмат

Ель европейская (обыкновенная) — самое распространённое в Европе хвойное дерево. При благоприятных условиях дерево может дожить до 400 лет.

Высота дерева составляет 50 м при ширине ствола в 1 м. Это стройное дерево, крона — густая, пирамидальная. Ветки — горизонтальные или поникающие, низко опускающиеся по стволу.

Длина хвои — 1—3 см. На дереве хвоя держится порядка 7 лет. Зрелые шишки ели европейской имеют продолговато-цилиндрическую форму. Их длина 10—15 см, ширина — 3—4 см. Шишки созревают в октябре, но семена, как правило, выпадают в январе-апреле.

Длина семян — 3—5 мм. Семя имеет желтоватое крыло, которое легко от него отделяется. Зацветает дерево в возрасте 25—30 лет.

Листья игловидные (хвоя), зелёные, короткие, четырёхгранные, реже плоские, жёсткие и острые, иногда обращённыеабаксиальной стороной вверх, с 2 килями на верхней и нижней стороне. Расположены спирально поодиночке, сидят на листовых подушечках. Сохраняются на побегах в течение нескольких (6 и более) лет. Ежегодно опадает до одной седьмой части хвои.

## 30 нчы дәрес

**Тема:** Табигать — безнең байлыгыбыз.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — әзерләгән проектны презентацияли, сөйли белү.

Предмет — Резеда Вәлиеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Нәни чыршы» шигырен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — балаларда табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү, Яңа ел бәйрәме вакытында чыршыларны әрәм итмәү чараларын өйрәтү.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 104—106 нчы битләр), эш дәфтәрендә 31 нче бит.

**Җиһазлау:** Р.Вәлиеваның тормышын һәм иҗатын чагылдырган презентация, кышкы урман, чыршы рәсемнәре.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Хәлләрегез ничек? Бүген һава торышы нинди? Сезнеңчә, көн матурмы?

***2. Уку мәсьәләсен кую***

Укучылар белән бергәләп, дәреснең максатын билгеләү. (Әзерләгән проектларны яклау, башкаларны игътибар белән тыңлау һәм сораулар бирү, яңа мәгълүматны истә калдыру.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Проектларны яклау. Төркемнәргә бүленеп бирелгән «Чыршыларны саклыйк» проекты тыңлана: чыгыш ясаган төркемнәргә сораулар бирү, җавапларның дөреслеген, сөйләү осталыгын бал-

лар куеп бәяләү. Йомгаклап, төркемнәрнең эшенә билгеләр кую.

2. Р.Вәлиеваның «Нәни чыршы» шигыре белән танышу. (Бу дәреснең төп өлешен проектларны яклау алып тора, шуңа күрә шигырь теманың дәвамы, йомгаклау формасында бирелә.)

1) Шигырьне укытучының сәнгатьле укуы. Беренчел аңлауны тикшерү, әңгәмә. (Шигырьдә нәрсә турында сүз бара? Аны кем язган?)

2) Аңлашылмаган сүзләрне тәрҗемә итү. Эчтәлек буенча әңгәмә. (Ни өчен чыршы күңелсез?)

3) Дәреслектәге сорауларга җавап бирү.

4) Табышмакларга җавап эзләү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау.

— Сез Яңа ел бәйрәменә чыршы куясызмы? Ул чын чыршымы, әллә ясалма *(искусственная)* чыршымы?

— Бүгенге дәрестән соң, сез дусларыгызга, эти-әниегезгә нинди киңәш бирер идегез?

2. Бәяләү. Укучыларның иптәшләрен һәм үз эшләрен бәяләве.

3. Өй эше: а) эш дәфтәрендә 2 нче биремне (32 нче бит) үтәргә;

ә) «Нәни чыршы» шигырен ятларга;

б) «Шигырьдә чыршы күңелсез, чөнки...» җөмләсе белән башлап, чыршылар турында сөйләргә әзерләнергә.

## 31 нче дәрес

**Тема:** Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә, кирәк һәммәбезгә дә!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — якыннарыңны бәйрәм белән котлый белү.

Предмет — Туфан Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Акбай һәм Кыш бабай» әсәрен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — сәхнәдә кешеләр янында рольгә кереп уйнау сәләтен үстерү, җыр, бию сәнгатенә кызыксыну уяту.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 109—114 нче битләр), эш дәфтәрендә 31 нче бит.

**Җиһазлау:** Т.Миңнуллинның тормышы һәм иҗаты турында слайдлар, әдипнең портреты, китаплары һ.б.

## Дәрес барышы:

**1.Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Хәлләрне сорашып, һава торышы турында сөйләшеп, дәресне башлау. Уңай психологик халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: шигырьне иң матур сөйләүчегә конкурс.

2) — Яңа ел бәйрәмендә Чыршы янында һәр елны нинди дә булса әкият куялар. Сезнең нинди әкиятләр тыңлаганыгыз бар? Анда кемнәр катнашты?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәрестә шундый әкиятләр язучы, талантлы драматург Туфан Миңнуллин иҗаты белән танышачаклары искәртелә һәм аның «Акбай һәм Кыш бабай» дигән әкиятен рольләргә бүлеп укыячаклары, өйрәнәчәкләре турында әйтелә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы Т.Миңнуллин турында презентация эшләп, китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2) Укучылар дәреслектән Т.Миңнуллин турындагы белешмәне укыйлар.

3) Укыганны аңлау дәрәҗәсен тикшерү. Укытучы сораулар ярдәмендә укучыларның аңлавын тикшерә. 116 нчы биттәге 1, 2 нче биремнәр эшләнелә.

2. Сүзлек белән эш.

1) Укытучы сүзләрне укый, русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтә.

2) Укучылар сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр, сүзләрне хәтердә калдыралар.

3. Т.Миңнуллинның «Акбай һәм Кыш бабай» әкиятен рольләргә бүлеп уку.

— Бозау, Бәти һәм Бәрән кайсы бәйрәмгә әзерләнә?

— Акбай һәм Дүрткүз аларга ничек ярдәм итә?

— Кар кызы, бәйрәм белән котлап, нинди теләкләр тели? Тагын нинди җөмләләр белән котларга, нинди теләкләр теләргә була?

Укыганнан соң, бу сорауларга җавап бирәләр. «Иң оста укучы» билгеләнә.

4. Биремнәр һәм сораулар, эш дәфтәрендә эшләү.

Дәреслектән 4—8 нче биремнәр эшләнә. Укучылар биремнәрне үзләре укыйлар, җавапларны партадашларына әйтәләр. Иптәшләренең җавапларына бәя бирәләр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау:

— Сезгә әсәр ошадымы?

— Ни өчен?

— Кар кызының теләкләрен исегездә калдырдыгызмы? Үзегез Кар кызы булсагыз, нинди теләкләр әйтер идегез?

2. Журналга билгеләр кую.

3 Өй эше: а) дәреслектәге сорауларга җавап бирергә;

ә) әти-әниләрен Яңа ел белән котлап, эш дәфтәренә котлау тексты язарга.

## 32 нче дәрес

**Тема:** Кабатлау, йомгаклау.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — өйрәнгән материалны искә төшереп, гомумиләштереп куллана белү.

Предмет — «Энҗе карлар явып үткән...» бүлегендә өйрәнелгән материалны кабатлау, үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү.

Шәхескә кагылышлы — бәйрәм белән котлау, үзең ясаган бүләкнең игътибарлылык, әдәплелек билгесе икәнлеген аңлату.

**Материал:** дәреслек (1 нче кисәк, 93—115 нче битләр).

**Җиһазлау:** Г.Ибраһимов, Т.Миңнуллин, М.Фәйзуллина, Р.Вәлива, К.Нәҗми портретлары, төрле әсәрләргә туры килә торган рәсемнәр, аерым битләрдә тестлар.

### Дәрес барышы:

**1. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Хәлләрне сорашу. Уңай психологик халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: а) сорауларга телдән җавап бирү;

ә) эш дәфтәренә язган котлау текстларын уку (берничә укучы), дәфтәрдә язганны тикшерү (берничә кешенекен).

2) Чылбыр буенча бер-берсен бәйрәм белән котлау.

3) Яңа елга нинди бүләк көтүләре, кемгә нинди бүләк әзерләүләре турында әңгәмә. Бүләк бирешү — әдәплелек, игътибарлылык билгесе, үз кулың белән ясаган кечкенә бүләкнең яки открытканың кыйммәтле икәнен аңлату.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәреснең максаты — бүлекне йомгаклау, мөстәкыйль рәвештә тест сорауларына җавап бирү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Портретлар ярдәмендә бу бүлектә өйрәнелгән язучыларның исемнәрен хәтердә яңарту.
2. Төрле рәсемнәр ярдәмендә, укылган әсәрләрнең эчтәлеген кабатлау.
3. Тест сорауларына җавап бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау: тест сорауларына җавапларны телдән тикшерү.
2. Укучыларның үзләренә билге куюы. Журналга билге тест җавапларын тикшергәч куела.
3. Өй эше: каникулда татарча спектакль карарга, дәреслектән өстәмә уку өчен бирелгән берәр әсәрне укырга.

## 33 нче дәрес

**Тема:** Күп укыган — күп белер.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — фантастик элементлар турында мәгълүмат бирү.

Предмет — К.Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Әбүгалисина» әсәрен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — үзеңә кирәкле белемне дөрес итеп таба белергә, китапларны теләп укырга күнектерү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 8—10 нчы битләр), эш дәфтәрендә 34 нче бит.

**Җиһазлау:** К.Насыйриның портреты, китаплары, тормышы һәм иҗаты буенча төзелгән презентация.

## Д ә р е с   б а р ы ш ы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Укучыларның каникулны ничек үткәрүләре, кәефләре турында сөйләшү. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: каникулда нәрсә укулары, татарча нинди телетапшыру, спектакль караулары турында әңгәмә.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, әдәбияттан үзләштерелгән белемнәрне ныгыта:

— Сез кайсы татар шагыйрьләрен беләсез?

— Нинди татар язучыларын беләсез?

— Татар рәссамнарыннан кемнәрне беләсез?

— Җырчылардан кемнәрне беләсез?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүгенге дәрестә «Акыл — тузмас кием, белем — кипмәс кое» бүлеген өйрәнә башлауны җиткерә, Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышачакларын искәртә.

### II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Автор белән танышу.

Укытучы, К.Насыйриның портретын, китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗат юлы белән таныштыра (презентация күрсәтә).

Дәреслектән К.Насыйри турындагы биографик белешмәне чылбыр буенча уку.

Укылган өлешне аңлау дәрәҗәсе тикшерелә (бер укучы аңлаганын рус телендә сөйләргә, ә калганнар өстәргә мөмкин, яисә укытучы сорау бирә, балаларның җаваплары тыңлана).

1) К.Насыйри кайчан туган?

2) К.Насыйри кайда туган?

3) Аның әтисе һәм бабасы нинди кешеләр булган?

4) Ул кайларда укый (белем ала)?

5) К.Насыйри нинди телләр белгән?

6) К.Насыйри кем ул?

2. Сүзлек белән эш. Яңа сүзләр белән танышу, текстны укырга әзерлек.

3. К.Насыйриның «Әбүгалисина» әсәрен уку:

1) Укытучы беренче абзацны укый, сораулар ярдәмендә укылган өлешне аңлау дәрәҗәсе тикшерелә.

2) Шулай ук башка өлешләрне дә балалар белән бергәләп

аңлап укуга ирешү. (Аңлашылмаган сүзләр генә тәрҗемә ителә, әсәр үзе тәрҗемә ителми.)

3) Эчтәлек буенча фикер алышу.

4. Әсәрнең укылган өлешен ныгыту.

1) 10 нчы биттәге сорауларга җавап бирү. (Сорауларны балалар үзләре укыйлар, җавап бирәләр. Авыр булса, тәрҗемә итәргә мөмкин.)

2) Эш дәфтәрендә биремнәрне үтәү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау.

— Сиңа бу дәрес тормыш өчен нәрсә бирде?

2. Бәяләү. Укучыларга билгеләр кую.

3. Өй эше: а) әсәрнең укылган өлешен кабатларга;

ә) К.Насыйри тормышы, «Әбүгалисина» әсәре турында сораулар төзергә;

б) Әбүгалисина белән Әбелхарисны чагыштырып сөйләргә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую.

— Белем тормышта ни өчен кирәк? Нигә күп укырга кирәк? Әбүгалисина белән Әбелхарис алга таба нишләрләр?

## 34 нче дәрес

**Тема:** Күп укыган — күп белер.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**.

Метапредмет — әдәби күренешләрне география, биология, тарих фәннәре белән бәйләп аңлату.

Предмет — К.Насыйриның тормышы һәм иҗаты турында белешмә бирү, К.Насыйриның «Әбүгалисина» әсәрен өйрәнүне дәвам итү.

Шәхескә кагылышлы — белемнең, акылның тормышта төп рольне уйнавына төшендерү.

**Материал:** К.Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре, дәреслек (2 нче кисәк, 10—13 нче битләр).

**Җиһазлау:** К.Насыйриның тормышын һәм иҗатын чагылдырган презентация, «Әбүгалисина» китабы, К.Насыйриның портреты.

**Д ә р е с   б а р ы ш ы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Укучылар белән исәнләшү

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: өйдә әзерләгән сорауларны чылбыр буенча сыйныфташларына бирү, җавап бирүче икенче кешегә үз соравын бирү һәм шулай һәр укучы җавап әйткәнче дәвам итә.

2. Әбүгалисина белән Әбелхарисны чагыштыру:

— Әбүгалисина — нинди бала? Ни өчен шулай уйлыйсыз?

— Әбелхарис нинди бала була? Фикерегезне китаптан җөмләләр укып дәлилләгез.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүгенге дәрестә дә «Әбүгалисина» әсәрен укуны дәвам итәчәкләрен әйтә. «Кыйсса» жанры турында аңлатып үтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Сүзлекчә белән эш. 11, 12 нче биттәге яңа сүзләрне дөрес итеп укып, истә калдыру.

2. 13 нче биттәге рәсемнәрне карап, бу бүлекнең эчтәлеге нинди булачагы турында фикер алышу, укучыларны кызыксындыру.

3. «Әбүгалисина» әсәренең II бүлеген уку. Өлешләп уку, сорауларга җавап биреп, аңлау дәрәҗәсен тикшерү.

4. Дәреслекнең 12 нче битендәге сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Каюм Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре сезгә ошыймы? Ни өчен? Кайсы герой күбрәк ошый? Алар татумы?

2. Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашуларын бәяләп, билгеләр кую.

3. Өй эше: а) К.Насыйриның тормышы, иҗаты турында кабатларга;

ә) 13 нче биттәге рәсемнәргә карап, бу бүлектәге вакыйгалар турында сөйләргә;

б) белем турында мәкальләр һәм әйтемнәр язып килергә.

4. Алдагы дәрескә проблема кую: әсәрне укып бетерергә, К.Насыйри турында истә калдырырга.

## 35 нче дәрес

**Тема:** Ни чәчсәң — шуны урырсың.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укучыларны музейлар белән таныштыру, кызыксындыру.

Предмет — «Әбүгалисина» әсәрен укып бетерү, К.Насыйриның Казандагы һәм Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылындагы музейлары турында мәгълүмат бирү.

Шәхескә кагылышлы — белем алырга, белем белән кешеләргә файда китерергә, игелекле булырга омтылыш тәрбияләү.

**Материал:**дәреслек (2 нче кисәк, 14—18 нче битләр).

**Җиһазлау:** К.Насыйриның портреты, музейлары буенча төзелгән презентация.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Укучыларга яхшы кәеф теләү.

***2. Актуальләштерү***

Өй эше тикшерү: төрле вариант өй эшләрен тыңлап, алдагы дәрес материалы кабатлана.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәреслектәге материалны карап, укучылар белән бергә дәрескә максат кую:

1) «Әбүгалисина» әсәрен укып бетерергә;

2) К.Насыйриның музейлары турында истә калдырырга.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. 15 нче биттәге сүзлекчә белән эш: дөрес итеп кабатлау, дөрес итеп уку, тәрҗемәсен истә калдыру, җөмләләр төзү.

2. Укучыларның «Әбүгалисина» әсәрен (соңгы бүлек) укып чыгулары. Сорауларга җавап бирү — аңлауны ныгыту. Дөрес аңламаган яки авырсынган өлешләрне тәрҗемә итү.

3. Эчтәлек буенча әңгәмә. (Ни өчен икесенең язмышы ике төрле тәмамлана? Дәреснең темасы эчтәлеккә туры киләме? Игелекле булу авырмы? һ.б.)

4. Теоретик төшенчәне аңлату.

— Бу әсәрдәге вакыйгалар тормышта була аламы (булганмы)?

Әкият белән охшаш яклары? (Фантастик моментлар.) Чынлыкка охшаш яклары? (Мәгарәдә китапханә булуы; белемне тылсым өреп кенә түгел, ә күп укып алулары; Ибн Сина исемле галим яшәгән.) Мондый әсәрләрне кыйсса дип атыйлар.

5. К.Насыйриның музейлары белән танышу.

1) — Дәресебезнең темасы К.Насыйри тормышына да туры киләме икән? (Күп укыган, күп эшләгән, хезмәтләрен шул вакыттагы галимнәр дә, бүген дә югары бәялиләр. Халык өчен тырышкан, аны халык онытмый. Музейлары бар.)

2. — «Музей» сүзе нәрсәне аңлата?

3. Казанда К.Насыйри музее турындагы текстны уку. Әңгәмә үткәрү.

Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылында К.Насыйри музее турындагы текстны уку. Әңгәмә.

4. Музейлар турында презентация яки китаплардагы рәсемнәрне карап, укылганны ныгыту.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау.

— Дәрестә сез нинди яңалыклар белдегез? Дәрестә нәрсә ошады? Нәрсә ошамады? Ни өчен?

2. Бәяләү.

3. Өй эше: а) «Әбүгалисина» әсәренең 3 нче өлеше буенча план төзергә;

ә) Әбүгалисина (Ибн Сина) турында өстәмә мәгълүмат табарга;

б) «Китапханәдәге бәхәс» шигырен укырга, китапханә белән мәгарәне чагыштырырга.

## 36 нчы дәрес

**Тема:** Тырышкан табар — ташка кадак кагар.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — хикәядә очрый торган яңа сүзләрне (эш кораллары атамаларын) тормыш белән бәйләп, истә калдыру.

Предмет — Г.Сабитовның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Чүкеч» хикәясен өйрәнү, «хикәяләү» теоретик төшенчәсе белән танышу.

Шәхескә кагылышлы — җаваплылык хисләре, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү, укучыларга хезмәт тәрбиясе бирү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 21—24 нче битләр), эш дәфтәрендә 34 нче бит.

**Җиһазлау:** Г.Сабитов портреты, китаплары, тормышы һәм иҗаты турында слайдлар, эш кораллары рәсемнәре.

## Дәрес барышы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

Укучыларга хәерле көн теләү, уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: укучыларның төзегән планнарын укулары, тапкан өстәмә мәгълүмат белән таныштырулары.

2. Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп хезмәт, эш турында әңгәмә кора:

— Әбүгалисина, Әбелхарис китап белеме белән генә кызыксынганнармы? (Төрле эш эшли белгәннәр.) К.Насыйри китап язу, фәнни эш арасында тагын нинди эшләр эшли белгән? (Үзе җиһазлар, уен кораллары ясаган.)

— Буш вакытта нинди эшләр эшләргә яратасыз? Кызлар, малайлар, технология (хезмәт) дәресендә нәрсәләргә өйрәнәсез?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүген танышачак герой да эшләргә ярата. Г.Сабитовның «Чүкеч» хикәясе белән танышырбыз.

### II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы Г.Сабитовның китапларын күрсәтә, тормышы һәм иҗат юлы белән таныштыра. Презентация күрсәтә.

2) Укучылар дәреслектәге белешмәне укыйлар.

— Дәреслектә укытучы сөйләгән нинди фактлар турында язылган? Нәрсәләр турында әйтелми?

2. «Чүкеч» текстын укуга әзерлек.

1) Сүзлек белән эш: 23 нче биттәге яңа сүзләрне дөрес итеп укыганны тыңлау, кабатлау, ассоциация алымы белән истә калдыру (рус телендә әйтелеше охшаган сүз табу, бәйләп, җөмлә төзү. Мәсәлән: *эш коралы* (татарча) — *коралл* (русча)).

2) Фразеологик сүзтезмәләр белән җөмләләр төзү.

3) Рәсем буенча фикер алышу. (Хикәя нәрсә турында булырга мөмкин? Малай нинди? Ул әтисе белән нәрсә турында сөйләшә икән?)

3. Г.Сабитовның «Чүкеч» хикәясен уку.

1) Укучылар укытучы укыганны тыңлыйлар, ишетеп аңларга тырышалар. Эчтәлек буенча әңгәмә.

2) Укучыларның мөстәкыйль укулары. Һәр укучы 3 җөмләнең генә тәрҗемәсен сорый ала, калган өлешен үзләре аңларга тырышалар.

3) Текст ахырындагы сорауларга җавап бирү. Эчтәлек буенча әңгәмә (хәзер тулаем аңлап).

4) — Бакый — нинди малай? Тактадагы бирелгән сүзләр рәтеннән аңа караган сүзләрне сайлап әйтү: *ялкау, тырыш, максатчан, хезмәт ярата, эшләргә яратмый, кызыксына торган, кадак җене кагылган, гел уйнарга ярата.*

5) Табышмакларга җавап табу.

4. Теоретик материал белән эш.

1) — Бу әсәр нинди жанрга карый? (Хикәя.)

2) Сюжет элементларын искә төшерү (эш дәфтәрендә 34 нче бит). Бу хикәядә сюжет элементларын табу.

3) «Хикәяләү» теоретик төшенчәсен аңлату. Дәреслектән билгеләмәне рус һәм татар телләрендә уку.

— Рус әдәбиятыннан хикәяләүгә нинди мисаллар китерә аласыз?

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау

— Г.Сабитовның «Чүкеч» хикәясе ошадымы? Бу дәрестә үзегезгә файдалы киңәш алдыгызмы? Бүгенге дәрестә нәрсәне яттан белергә кирәк дип саныйсыз?

2. Бәяләү. Билгеләр кую.

3. Өй эше: а) хикәяләү турындагы теоретик төшенчәне истә калдырырга;

ә) хикәяне рольләргә бүлеп укырга әзерләнергә;

б) «Сиңа «Чүкеч» әсәрендәге төп герой — Бакый ошадымы?» — дип башлап, диалог әзерләргә. (Бер кешегә Бакый ошаган, ә икенчесе аның кимчелекләрен тапкан.)

## 37 нче дәрес

**Тема:** Эшләгәнең — кешегә, өйрәнгәнең — үзеңә.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — тексттан төп мәгълүматны таба һәм кирәкле башка формага куеп куллана белү.

Предмет — А.Алишның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Әни ялга киткәч» хикәясен өйрәнү, «хикәяләүче» теоретик төшенчәсен истә калдыру, сөйләм телен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — төрле ситуацияләрдә үз-үзеңне дөрес тота, буш вакытны файдалы эшләр белән үткәрә белергә өйрәтү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 25—27 нче битләр), эш дәфтәрендә 35 нче бит.

**Җиһазлау***:* А.Алишның тормышы һәм иҗаты турында презентация, альбомнар, китаплары.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Хәлләрне сорашып, укучылар бер-берсенә комплиментлар әйтеп, уңышлар теләп, дәресне башлау — психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: (вариатив) «Чүкеч» хикәясен рольләргә бүлеп уку, әзерләгән диалогларын тыңлау.

2. Укытучының юнәлдерүче сораулары белән хезмәт,эш турында әңгәмә.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүгенге дәрестә хезмәт турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен әйтә. Балалар язучысы А.Алиш белән танышачакларын искәртә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы А.Алишның китапларын күрсәтә, тормышы һәм иҗат юлы белән таныштыра. Презентация күрсәтә.

2) Дәреслектән А.Алиш турында белешмә укыла. Аңлауны тикшерү, ныгыту төрле биремнәр белән башкарыла:

а) бер укучы датаны әйтә, икенчесе туры килә торган вакыйганы таба;

ә) укучы сорау бирә һәм тест формасында 3 җавап тәкъдим итә;

б) укучы җөмлә төзеп әйтә, башкалар текст эчтәлегенә туры килүе белән килешәләр. (Мин синең белән килешәм. Мин килешмим, чөнки...)

2. Хикәяне укырга әзерлек.

1) Сүзлекчә белән эш.

2) Тактадагы (экрандагы) сорауларны уку, аңлау. (Әни кая киткән? Ул ни өчен киткән? Өйдә кемнәр калган? Кем ул Фәүзия? Аны иртән кем киендерә? Чәйне кем кайната? Кем аш пешерә? Идәнне кем юа? Малай эшләрен сөйләгәч, энисе нишли?)

3. А.Алишның «Әни ялга киткәч» хикәясе белән танышу.

1) Укытучы укыганны тыңлау. Сорауларга җавап бирү (аңлаган кадәр).

2) Укучыларның хикәяне эчтән укулары, сорауларга җавап эзләү дәвам итә.

3) Хикәяне абзацлап аңлап укуга ирешү.

4) Хикәядән соң бирелгән сораулар, биремнәрне үтәү.

4. Теоретик төшенчә белән таныштыру.

— Хикәяләү — нәрсә ул? Хикәяләүне кем башкара? Бу хикәядә кем хикәяләүче?

Укытучы «хикәяләүче» теоретик төшенчәсе белән таныштыра, дәреслектән билгеләмә рус һәм татар телләрендә укыла.

5. Эш дәфтәрендәге биремнәрне телдән эшләү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау: укучылар 5 нче биремне эшлиләр. Бу биремне эшләгәндә, хикәянең эчтәлеге тулысынча кабатлана.

2. Бәяләү. Билгеләр куела.

3. Өй эше: а) эш дәфтәрендәге биремнәрне (35 нче бит) язмача эшләргә;

ә) дәреслектәге 5 нче бирем җөмләләрен кулланып, малай турында сөйләргә;

## Укытучы өчен өстәмә материал

Хикәяләүче — укучыга вакыйгалар һәмперсонаҗларның гамәлләре турында хәбәр итүче, вакыт күчешен билгеләүче, катнашучыларның тышкы рәвешен, вакыйгалар барган урынны тасвирлаучы, геройның эчке хәлен анализлаучы, аның рухи дөньясын, темпераментын, әхлак кагыйдәләренә мөнәсәбәтен билгеләүче. Хикәяүченең дөньяга карашы киң, аның сөйләмә, беренче чиратта, укучыга юнәлтелгән. Хикәяләүче — зат түгел, ә функция. Әлеге функция персонажга беркетелгән булырга мөмкин.

## 38 нче дәрес

**Тема:** Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — план төзи, план буенча сөйли белү.

Предмет — А.Алишның «Әни ялга киткәч» хикәясен өйрәнү, сөйләм телен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — төрле ситуацияләрдә үз-үзеңне дөрес тота, буш вакытны файдалы эшләр белән үткәрә белергә өйрәтү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 25—27 нче битләр), эш дәфтәрендә 35 нче бит.

**Җиһазлау:** А.Алишның тормышы һәм иҗаты турында презентация, альбомнар, китаплары.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: эш дәфтәрендәге биремнәрнең дөреслеген тикшерү, хаталарны төзәтү. Малай турында сөйләү.

2. Өйдә әниләргә булышу турында әңгәмә.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Сез дә, малай шикелле, әниегезгә булышасызмы? Ул кайтуга эшләрне бетереп куясызмы? Шул турыда сөйләргә өйрәнербез.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. А.Алишның тормышы, иҗаты турында искә төшерү.

1) Дәреслектән А.Алиш турында биографик белешмәне уку.

2) Тест сорауларына җавап бирү:

1. А.Алиш туган җир:

а) Арча районы Кушлавыч авылы;
ә) Оренбург өлкәсе Мостафа авылы;
б) Спас авылы Көек авылы.

2. А.Алиш туган көн:

а) 15 нче февраль;
ә) 15 нче сентябрь;
б) 26 нчы апрель.

3. Абдулланы кем укырга өйрәтә?

а) Әтисе;
ә) энисе;
б) укытучы.

4. А.Алиш кайчан яза башлый?

а) 1930 елда;
ә) рус мәктәбендә укыганда;
б) алты-җиде яшьләрдә.

5. Казанга килгәч, ул нинди журналда эшли башлый?

а) «Пионер каләме»;
ә) «Техника»;
б) «Ялкын».

6. Сугыш башлангач, ул фронтта кем була?

а) Журналист;
ә) хәрби хәбәрче;
б) солдат-радист.

7. А.Алиш ничәнче елда әсирлеккә төшә?

а) 1941 елда;
ә) 1943 елда;
б) 1944 елда.

8. Әсирлектә кайсы шагыйрь белән яшерен оешма эшендә катнаша?

а) Г.Тукай;
ә) М.Җәлил;
б) Ф.Кәрим.

3) Сорауларга җавапның дөреслеген тикшерү (телдән).

2. Сөйләм телен үстерү.

1) «Әни ялга киткәч» хикәясендәге хикәяләүче эшләгән эшләрне санау, рус һәм татар телләрендә әйтү.

2) Эш дәфтәрендәге фигыльләр белән җөмләләр төзү.

3) Парлап сөйләшү:

— Син әниеңә булышасыңмы?

— Әйе. Ә син?

— Мин дә булышам: идән юам, сеңлемне киендерәм, кер үтүклим.

— Ә мин идән себерәм, савыт-саба юам, төймәмне үзем тагам һ.б.

### III. Рефлексив бәяләү

1. Рефлексив кабатлау.

— Бүгенге дәрес сине нинди булырга өйрәтте?

— Автор безгә нәрсә әйтергә теләгән?

2. Бәяләү. Укучыларның үз эшчәнлекләрен бәяләве.

3. Өй эше: а) өйдә ничек булышулары турында җөмләләр язарга;

ә) өйдә ничек булышулары турында сөйләргә;

б) Җ.Дәрзаманның «Бүләк» шигырен укып, эш дәфтәрендәге биремнәрне үтәргә.

## 39 нчы дәрес

**Тема:** Эш кешене тәрбияли, ялкаулык боза.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — җаваплылык хисләре, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү.

Предмет — Ф.Яруллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Кояштагы тап» хикәясен өйрәнү, «притча» теоретик төшенчәсен истә калдыру.

Шәхескә кагылышлы — әниләргә карата шәфкатьлелек, хөрмәт хисләрен үстерү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 30—34 нче битләр), эш дәфтәрендә 38—39 нчы битләр.

**Җиһазлау:** Ф.Яруллинның портреты китаплар күргәзмәсе.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Кәефләрен сорашып, уңышлар теләп, психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

Әңгәмә. Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән әңгәмә кора.

— «Чүкеч» хикәясен кем язган, ул хикәя кем турында? «Әни ялга киткәч» хикәясен кем язган, ул хикәя кем турында? Бу хикәядәге малайлар нинди? Аларның уртак яклары бармы?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең лирик герое — шундый ук малай. Аны алда укылган әсәрләрнең геройлары белән чагыштырырсыз.

Укытучы бүгенге дәрестә хезмәт, эш һәм тәрбиялелек турында сөйләшәчәкләрен әйтә. Халык язучысы Ф.Яруллин иҗаты белән танышачакларын искәртә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы Ф.Яруллин китапларын күрсәтә, аның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыра. Презентация күрсәтә.

2) Укучылар дәреслектәге биографик белешмәне укыйлар.

3) Укытучы, сораулар ярдәмендә, укучыларның аңлау дәрәҗәсен тикшерә.

— Ф.Яруллин кем ул?

— Ул кайчан туган?

— Ул кайда туган?

— Ул кайларда укыган (белем алган)?

— Беренче шигырьләре кайда басыла?

2. «Кояштагы тап» әсәрен укуга әзерлек.

1) Сүзлекчә белән эш. Укытучы яңа сүзләрне укый, укучылар кабатлыйлар. Укучылар яңа сүзләр белән чылбыр буенча сүзтезмәләр төзиләр.

2) Әсәрнең исемен русчага тәрҗемә итү. Дәреслектәге рәсем белән эш. (Бу малай нишли? Бакыйга охшаганмы? Ни өчен әсәр шулай атала?)

3. Ф.Яруллинның «Кояштагы тап» хикәясен уку.

Әсәрне өлешләп аңлап укырга ирешергә. Укылган өлешнең аңлау дәрәҗәсен тикшереп барырга кирәк. (Хикәя тулысынча тәрҗемә ителми, аңлашылмаган өлешләрне генә тәрҗемә итәбез.) Һәр абзацның эчтәлеге буенча әңгәмә.

4. Дәреслектәге 1—5 нче сорауларга телдән җавап бирү.

5. Теоретик материал белән эш. Укытучы «притча» теоретик төшенчәсе турында аңлата, укучылар дәреслектәге белешмәне рус һәм татар телендә укыйлар.

— «Кояштагы тап» хикәясе притча дип аталамы? Ни өчен?

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау.

2. Бәяләү. Билгеләр кую.

3. Өй эше: а) притча турындагы теоретик төшенчәне ятларга;

ә) «Кояштагы тап» хикәясеннән ошаган өзекне сәнгатьле итеп укырга;

б) эш дәфтәрендәге биремнәрне үтәргә.

## 40 нчы дәрес

**Тема:** Ялгап әйткән тотылыр...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — җаваплылык хисләре, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү.

Предмет — Ф.Яруллинның «Кояштагы тап» хикәясен өйрәнү, «притча» теоретик төшенчәсен ныгыту, сөйләм телен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — әниләргә карата шәфкатьлелек, хөрмәт хисләрен үстерү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 30—34 нче битләр), эш дәфтәрендә 38—39 нчы битләр.

**Җиһазлау:** Ф.Яруллинның портреты китаплар күргәзмәсе.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Укучыларның кәефләрен белү. Һава торышы турында фикер алышу.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: эш дәфтәрендәге биремнәрнең дөреслеген тикшерү, өзекне сәнгатьле уку.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— «Кояштагы тап» әсәренең эчтәлеген сөйләргә әзерләнербез.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Текстны чылбыр буенча уку, аңлашылмаган җөмләләрне тәрҗемә итү.
2. Әсәрне өлешләргә бүлү, һәр өлешкә исем кушу.
3. Әсәрне сюжет элементлары ягыннан тикшерү.
4. Әсәргә бергәләп план төзү. План белән чылбыр буенча сөйләү. (Бер укучы башлый, калганнар дәвам итә.)
5. Бергәләп эчтәлек сөйләү: бер укучы бер җөмлә әйтә, икенче укучы аның җөмләсен кабатлый һәм үзе яңа җөмлә өсти, өченче укучы 1, 2 нче җөмләләрне кабатлый, яңа җөмлә өсти.
6. Парлап яки төркемнәрдә, планга карап, эчтәлек сөйләп карау.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Рефлексив кабатлау.
2. Бәяләү. Билгеләр кую.

3. Өй эше: а) «Кояштагы тап» әсәренең эчтәлеген сөйләргә;

ә) «Кояштагы тап» хикәясендәге малай ошадымы? Ни өчен?» — сорауларына җавап әзерләргә;

б) «Чүкеч», «Әни ялга киткәч», «Кояштагы тап» хикәяләрендәге төп геройларны чагыштырып, характеристика бирергә.

## 41 нче дәрес

**Тема:** Иң элек син Кеше бул, балам!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — һөнәр сайларга әзерләү.

Предмет — Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү, «Кем булырга?» шигырен өйрәнү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәтү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 36—38 нче битләр), эш дәфтәрендә 39, 40 нчы битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, Г.Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты турында слайдлар, китаплар күргәзмәсе, Г.Зәйнашева сүзләренә җырлар язмасы.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Кәефләрне белешү. Һава торышы турында сөйләшү. Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: алдагы дәрестә бирелгән өй эшенең кайсы сайланган булса да, укучы сөйләргә әзерләнгән булырга тиеш. Һәр укучы сөйли алсын өчен, «түгәрәк буенча» сөйләргә мөмкин: парларда бер-берсенә сөйлиләр, парларны берничә тапкыр алмашып, тагын башкаларга сөйлиләр, аннары, бергәләп, һәр укучыга билге куялар.

2. Әңгәмә.

— Бу өч хикәядәге малайлар, үскәч, нинди кеше булырлар икән? Нинди һөнәр иясе булырлар дип уйлыйсыз?

— Ә сез кем булырга телисез? Бу турыда уйлаганыгыз бармы?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүгенге дәрестә һөнәр ияләре, үскәч кем булырга теләүләре темасына сөйләшәчәкләрен әйтә. Шагыйрә Г.Зәйнашева иҗаты кызыклы булуын искәртә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

— Укытучы Г.Зәйнашеваның китапларын күрсәтә, тормышы һәм иҗат юлы белән таныштыра.

— Дәреслектәге белешмә укыла. Китапларны ябып, кечкенә тест белән аңлау дәрәҗәсе тикшерелә.

1) Гөлшат Зәйнашева кем ул?
а) Язучы;
ә) шагыйрә;
б) җырчы.

2) Училищеда, институтта ул нинди һөнәр ала?
а) Укытучы;
ә) табибә;
б) җырчы.

3) Г.Зәйнашева шигырьләренә кемнәр көй яза?
а) Шагыйрә;
ә) композитор;
б) биюче.

4) Г.Зәйнашеваның туган ягы кайсы?
а) Тукай районы;
ә) Арча районы;
б) Спас районы.

2. «Кем булырга?» шигырен укуга әзерлек, сүзлек өстендә эш.

3. Г.Зәйнашеваның «Кем булырга?» шигырен уку.

1) Укытучы шигырьне сәнгатьле итеп үзе укый. Эчтәлек буенча әңгәмә.

2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар. Сәнгатьле укуга әзерлек.

3) Парларда, төркемнәрдә иптәшләренә шигырьне кычкырып, сәнгатьле итеп укыйлар.

4. Дәреслектәге 1—6 нчы сорауларга җавап бирү. Җөмләләр төзиләр.

5. 6 нчы биремдәге үрнәк буенча парлап сөйләшү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәреснең уку мәсьәләсен чишә алдыкмы? Яңа мәгълүмат алдыгызмы?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларның эшчәнлекләрен бәяләү.

— Үзегезнең дәрестәге эшчәнлегегезне бәяләгез. (Укытучы билгеләр куя).

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга;

ә) эш дәфтәрендәге биремнәрне эшләргә (39—40 нчы битләр);

б) үзегезгә ошаган һөнәргә реклама ясарга (презентация, рәсемнәр, фото, сөйләү).

## 42 нче дәрес

**Тема:** Онытылмас моңнар. Сәйдәшнең юл башы.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укучыларга төрле һөнәр сайлау юлларын аңлату.

Предмет — М.Латыйфуллин әсәреннән алынган «Сәйдәшнең юл башы» өзеген өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — яңалыкка омтылу, һәрнәрсәне белергә теләү хисе тәрбияләү, милли горурлык хисләре формалаштыру.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 38—42 нче битләр), эш дәфтәрендә 40—41 нче битләр.

**Җиһазлау:** С.Сәйдәшевнең балачагы турында слайдлар, җыр язмалары.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Укучыларның хәлләрен сорашып, уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эше тикшерү: һөнәрләр турында презентация карау, тыңлау, бәяләү.

2. Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, әңгәмә кора.

— Сез сәнгать өлкәсендә нинди һөнәр ияләрен беләсез?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүген танылган композиторның ничек һөнәр сайлавы турында әсәрдән өзек укырбыз.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

Укытучы М.Латыйфуллинның тормышы һәм иҗаты белән таныштыра.

2. «Сәйдәшнең юл башы» әсәрен укырга әзерлек.

Сүзлек эше. 41 нче биттәге яңа сүзләрне укытучы укый, укучылар кабатлыйлар. Бер укучы сүзләрне рус телендә укый, икенчесе тәрҗемә итә, өченчесе кабатлый, дүртенче укучы — җөмлә төзи һ.б.

3. М.Латыйфуллинның «Сәйдәшнең юл башы» әсәрен уку.

1) Өзекне укытучы укый, сораулар биреп, укылган өлешнең аңлау дәрәҗәсен тикшерә.

2) Эчтәлек буенча әңгәмә.

4. Биремнәр һәм сораулар.

1) Дәреслектә 41—42 нче биттәге 1—5 нче биремнәр эшләнелә.

2) Эш дәфтәрендәге биремнәр үтәлә.

5. Укытучы биографик әсәр турында аңлата. Бер укучы дәреслектән рус һәм татар телендә биографик әсәр турында теоретик төшенчәне укый. Биографик һәм автобиографик әсәрләр арасындагы аерманы әйтәләр. Дәреслектән 7 нче сорауга җавап бирәләр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Салихны музыкага өйрәтеп дөрес эшләгәннәрме?

— Сезгә дәрестә кайсы бирем (эш төре) ошады?

2. Укучыларга, дәрестә катнашуларына карап, журналга билгеләр кую.

3. Өй эше: а) биографик әсәр турындагы теоретик төшенчәне истә калдырырга;

ә) эш дәфтәрендә 41 нче биттәге 2 нче бирем: сүзләрдән җөмләләр төзергә;

б) С.Сәйдәшев турында мәгълүмат табарга.

## 43 нче дәрес

**Тема:** Моңнар чишмәсе Салих Сәйдәшев.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — җыр, музыка сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү.

Предмет — С.Сәйдәшевнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирүне дәвам итү.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — Татарстанның күренекле шәхесләре белән горурлану хисләре уяту.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 43—45 нче битләр), эш дәфтәрендә 41, 42 нче битләр.

**Җиһазлау:** С.Сәйдәшевнең тормышы һәм иҗаты турында слайдлар, җыр язмалары.

**Д ә р е с  б а р ы ш ы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның күңел халәтен аңлау.

***2. Актуальләштерү***

1. Өй эшен тикшерү: эш дәфтәрендәге биремнәрнең дөреслеген тикшерү.

2. Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән яраткан композиторлары турында әңгәмә кора.

— Сез рус композиторларыннан кемнәрне беләсез?

— Татар композиторларыннан кемнәрне беләсез?

— Чит ил композиторларыннан кемнәрне беләсез?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүгенге дәрестә күренекле татар композиторы, татар профессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе Салих Сәйдәшев турында сөйләшүне дәвам итәчәкләрен әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. С.Сәйдәшев турында укучылар әзерләп килгән мәгълүматны тыңлау.

2. Сүзлек белән эш. Укытучы сүзләрне укый, укучылар кабатлыйлар. Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен әйтә. Сүзләр белән җөмләләр төзиләр.

3. Салих Сәйдәшев турындагы текст белән танышу.

1) С.Сәйдәшев турында сорауларны уку, тәрҗемә итү.

— С.Сәйдәшев кем ул?

— Ул кем гаиләсендә тәрбияләнә?

— Ш.Әхмәров кем ул?

— Салихта музыкага сәләт кайчан ачыла?

— Аның беренче уен коралы нәрсә була?

— Беренче укытучысы кем?

— Ул кайларда укый?

— С.Сәйдәшевның нинди җырларын беләсез?

2) Укытучының укуы. Укучылар тыңлыйлар, ишетеп аңларга, сорауларга җавап табарга тырышалар.

3) Аңлау дәрәҗәсен тикшерү: сорауларга җавап бирү (күпме аңлаганнар).

4) Текстны укучыларның мөстәкыйль укулары, сорауларга җавап эзләү.

4. С.Сәйдәшев турында альбом һәм презентация карау. Бу презентациядә Казанда С.Сәйдәшев исемен йөрткән истәлекле урыннар турында да мәгълүмат бирелә.

5. С.Сәйдәшевнең җырларыннан өзекләр тыңлау.

6. Эш дәфтәрендәге 3 нче биремне аңлату: хатны уку, сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү, барлык хатларга хас җөмләләрне билгеләү (астына сызу).

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Сезгә бу дәрес ошадымы?

— Татар композиторларыннан тагын кемнәр турында өйрәнәсегез килә?

2. Бәяләү. Билгеләр кую.

3. Өй эше: а) С.Сәйдәшев турында дәреслектән укырга;

ә) эш дәфтәрендә 1, 2 нче биремнәр (41, 42 нче битләр);

б) эш дәфтәрендә 3 нче бирем — хат язарга.

## 44 нче дәрес

**Тема:** Син башкаларга үрнәкме?

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — төрле яклап үз сәләтләрен үстерүгә омтылыш тәрбияләү.

Предмет — Равил Фәйзуллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү, «Бердәнбер» шигырен өйрәнү.

Шәхескә кагылышлы — әти-әни, туган ил, туган телнең иң кадерле икәнен аңлату.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 47, 48 нче битләр), эш дәфтәрендә 42, 43 нче битләр.

**Җиһазлау:** Р.Фәйзуллинның тормышы һәм иҗаты турында презентация, китаплар күргәзмәсе, аудиоязмада шигырьләре.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Укучылар белән исәнләшү, аларның кәефен сорау.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: эш дәфтәрендәге биремнәрне, язган хатны тикшерү, хаталарын төзәтү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, әңгәмә кора.

— Ни өчен С.Сәйдәшевне онытмыйлар? Аның кебек кешеләр күпме?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Укытучы бүгенге дәрестә Р.Фәйзуллин иҗаты белән танышачакларын әйтә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Автор белән танышу.

1) Укытучы Р.Фәйзуллинның портретын, китапларын күрсәтә, тормышы һәм иҗат юлы белән таныштыра.

2) Дәреслектән Р.Фәйзуллин турында биографик белешмә укыла.

3) Укытучы сораулар ярдәмендә укучыларның укыганны аңлауларын тикшерә.

2. Сүзлек белән эш.

3. Р.Фәйзуллинның «Бердәнбер» шигырен уку.

1) Укытучы шигырьне сәнгатьле итеп үзе укый яки аудиоязмада тыңлата.

2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.

3) Шигырьне сүзгә-сүз тәрҗемә итәләр.

4 )Берничә укучы шигырьне кычкырып укый. Сәнгатьле укуга әзерлек.

5) Эчтәлек буенча әңгәмә.

4. Биремнәр һәм сораулар, эш дәфтәрендә эшләү.

1) Дәреслектән 48 нче биттәге 1, 2, 4, 5, 6 нчы биремнәр телдән эшләнелә.

2) Эш дәфтәрендә 2 нче бирем язмача эшләнелә.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләштек?

— «Илдә бер» дип әйтсеннәр өчен, үзеңдә нинди сыйфатлар булдырырга кирәк?

2. Бәяләү.

— Үзеңә һәм иптәшләреңә нинди билгеләр куяр идең?

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга;

ә) эш дәфтәрендә 1 нче биремне эшләргә (42 нче бит);

б) бу бүлектә иң ошаган әсәр турында сөйләргә.

## 45 нче дәрес

**Тема:** Кабатлау, йомгаклау.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — белемнәрне гомумиләштерә, кирәк ситуациядә куллана белү.

Предмет — К.Насыйри, Г.Сабитов, А.Алиш, Ф.Яруллин, Г.Зәйнашева, М.Латыйфуллин, Р.Фәйзуллиннарның тормышлары, иҗатлары турында белү, әсәрләрен хәтердә ныгыту.

Шәхескә кагылышлы — тормышта үз урыныңны табу өчен һөнәрле, белемле, кешелекле булырга кирәклеген аңлату.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 8—48 нче битләр).

**Җиһазлау:** язучыларның портретлары, төрле әсәрләргә туры килә торган рәсемнәр.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларга хәерле көн теләп, уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: «Бердәнбер» шигырен сәнгатьле уку.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәреснең максаты «Акыл — тузмас кием, белем — кипмәс кое» бүлеген кабатлау, үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Портретлар, рәсемнәр ярдәмендә язучылар, аларның әсәрләре турында белемнәрне кабатлау.
2. Бу бүлекнең исеме, эчтәлеге, иң ошаган әсәр турында әңгәмә.
3. Мөстәкыйль эш — тест сорауларына җавап бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Эшләрне укытучыга тапшыргач, җавапларны телдән, тикшерү.
2. Бәяләү. Үзбәя.
3. Өй эше: бу бүлектәге өстәмә уку өчен бирелгән шигырьләрне укырга, эш дәфтәрендәге биремнәрне үтәргә (сайлап).

## 46 нчы дәрес

**Тема:** Туган туганга кирәк.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — тормышта авыр хәлләргә төшмәс өчен, элементар кагыйдәләрне белергә кирәклеген аңлату.

Предмет — Дәрдемәнднең тормыш юлы белән танышу, хикәяне уку.

Шәхескә кагылышлы — әхлак тәрбиясе бирү, сәламәт яшәү рәвеше турында мәгълүмат бирү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 50—53 нче битләр), эш дәфтәрендә 43, 44 нче битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта),слайдлар: Дәрдемәнд портреты, аның белән бәйле рәсемнәр, хикәя эчтәлегенә туры килә торган рәсемнәр (яшел карлыган, инеш, дарулар, яшел болын, күбәләкләр оча, абыстай, хәлфә, көз җитә, боз белән капланган күл).

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Яңа башланган бүлекнең темасы буенча әңгәмә.

— «Илдә илле дустың булсын» дигәнне ничек аңлыйсыз?

— Сезнеңчә, бу бүлектә әсәрләр нинди темага булыр?

— Нәрсә ул дуслык?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Дәрдемәнднең «Ике туган» хикәясе. Уку мәсьәләсе куегыз. (Дәрдемәнднең кем икәнен белү, әсәрне уку, аңлау.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Шагыйрь Дәрдемәнднең кыскача биографиясе, иҗаты белән таныштыру.

1) Презентация, видеофильм карау яки укытучының тәрҗемәсез генә шагыйрь турында сөйләве.

2) Сөйләгәннең төп моментлары буенча сорауларга җавап бирү:

— Дәрдемәнд — чын исемме? Чын исеме ничек? Кайда туган? (Картадан карау.)

— Ни өчен Орск өлкәсенә күчәләр? Кайда белем ала? Нәрсәләр белән шөгыльләнә?

3) Аңлашылмаган сорауларга җавапны дәреслектәге биографик белешмәне укып эзлиләр. Җавап табуга ирешү.

2. «Ике туган» хикәясе белән танышуга әзерлек.

1) — Рәсемдә нәрсә сурәтләнгән? Ул нинди? Ул нишли? Хикәя нәрсә турында икән?

2) Сүзлек эше. Дөрес укыганны тыңлау, кабатлау, тәрҗемә итү, сүзтезмәләр төзү.

— Сүзлек белән танышкач, сезнең фикерегез: хикәя нәрсә турында булырга мөмкин?

3. Хикәяне укытучының сәнгатьле укуы, китапны ябып тыңлау. Максат — эчтәлекне кем күбрәк, төгәлрәк аңлар.

Эчтәлек буенча фикер алышу.

4. Хикәяне укучыларның укып чыгуы. Эчтәлек буенча фикер алышу. (Яңа детальләр ачыла.)

5. Абзацлап уку, тәрҗемә итү. Эчтәлек буенча әңгәмә.

— Хикәя дуслык турындамы? Нинди дуслык турында?

6. Сораулар, биремнәрне үтәү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Дәрдемәнд турында нәрсәләр белдегез? Хикәяне аңладыгызмы?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) хикәяне рольләргә бүлеп сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) эш дәфтәрендәге 1, 2 нче биремнәрне үтәргә;

б) әтәч һәм тавыкны сурәтләүче сыйфатлар язарга, җөмләләр төзергә.

## 47 нче дәрес

**Тема:** Туганнар белән яшәү күңелле.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — бирелгән текст буенча план төзи белү.

Предмет — Дәрдемәнднең тормыш юлы турында белү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — әхлак тәрбиясе бирү, сәламәт яшәү рәвеше турында мәгълүмат бирү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 50—53 нче битләр), эш дәфтәрендә 43, 44 нче битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар: Дәрдемәнд портреты, аның белән бәйле рәсемнәр, хикәя эчтәлегенә туры килә торган рәсемнәр.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшеп, укучыларның хәлләрен сорашып, дәресне башлау — психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү. Эш дәфтәрендәге 1 нче биремне тикшергәндә, Дәрдемәнднең тормыш юлы искә төшерелә, истә калмаган мәгълүмат кабатлана.

2) Хикәяне рольләргә бүлеп уку — сәнгатьле, дөрес укуга игътибар ителә.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Дәрдемәнднең «Ике туган» хикәясен кыскача сөйләргә әзерләнү. Уку мәсьәләсе куегыз. (Эчтәлек сөйләргә өйрәнү.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү этабы.**

1. Хикәяне яхшырак аңлау, җөмләләрне истә калдыру максаты белән, сайлап уку күнегүләре.

Рәсемгә туры килә торган җөмләләрне табып уку. (Дәреслектә бер генә рәсем, укытучы башка рәсемнәр дә күрсәтә ала. Мәсәлән: яшел карлыган, инеш, дарулар, яшел болын, күбәләкләр оча, абыстай, хәлфә, көз җитә, боз белән капланган күл һ.б.)

— *В каком предложении говорится о том, что бегать очень полезно?* — (Җөмләләрне табып уку күнегүе.)

— Әтәч турындагы җөмләләрне генә укыгыз. Тавык турындагыларын гына һ.б.

— Икесе бергә нишлиләр?

2. Эш дәфтәрендәге бирем — план төзеп язу.

3. Планга карап, чылбыр буенча сөйләү.

1) Бер укучы башлый, икенчесе дәвам итә — берәр җөмлә төзеп әйтәләр.

2) План буенча 6 кеше такта янында сөйли. 1 нче укучы — бер җөмлә, 2 нчесе — беренче кешенең җөмләсен + үз җөмләсен, 3 нче укучы — алдагы җөмләләрне кабатлый + үз җөмләсен әйтә һ.б.

3) Көчлерәк укучыларның тулысынча сөйләп караулары.

4. Дәреслектәге 3—6, 8 нче биремнәрне үтәү.

5. Туганнар арасындагы дуслык, сәламәтлеккә зыян китерүче элементар нәрсәләр (әтәч аларны белмәгән) турында сөйләшү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) хикәянең эчтәлеген сөйләргә;

ә) теләк буенча, Дәрдемәнд турында да җөмләләр өстәп сөйләргә;

б) эчтәлек буенча рәсем яки сөйләү өчен терәк схема рәвешендә рәсем ясарга.

## 48 нче дәрес

**Тема:** Шагыйрь үткән юл.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — тарихтан Такташ яшәгән чор турында мәгълүмат бирү.

Предмет — Һ.Такташ турында мәгълүмат бирү, «Мокамай» поэмасы белән таныша башлау.

Шәхескә кагылышлы — туган якның онытылмас, кадерле икәнен аңлау.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 54—55 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар: Һ.Такташ портреты, урман рәсеме.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Исәнмесез! Кәефләрегез ничек? Барыбызга да хәерле көннәр, уңышлар теләп, дәресне башлыйк.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: укучыларның монологларын тыңлау (парларда, төркемнәрдә).

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасы — Һади Такташның «Мокамай» әсәре.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен укучылар белән бергәләп кую:

а) Һ.Такташның тормышы, иҗаты белән танышырга.

ә) «Мокамай» әсәренең 1 нче өлешен укып аңларга.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. 1) Һ.Такташның тормыш юлы, иҗаты турында укытучы сөйләве. Презентация, китаплар күргәзмәсе.

2) Дәреслектәге биографик белешмәне уку.

3) Парларда эшләү: шагыйрьнең тормышы турында сораулар төзү, җавап бирү.

2. Поэманың беренче өзеге белән танышу.

1) Беренче өлешнең сүзлекчәсе белән эш.

2) Беренче өлешне диктор (А.Арсланов башкаруында аудиоязмалар бар) укуында тыңлау яки укытучының сәнгатьле укуы.

3) Эчтәлек буенча сорау — җавап.

4) Чылбыр буенча уку, сүзгә-сүз русчага тәрҗемә итү. Эчтәлек буенча әңгәмә.

5) Беренче өлешне сәнгатьле уку.

6) Укыган өлешне анализлау.

— Ни өчен Тамбов урманнарын оныта алмый? (Картадан карау.) Шагыйрь нәрсәне оныта алмый? (Яфраклар шаулавын. Шаулау — борчылу, тынычсызлык.)

— Ни өчен бер җирдә юк андый каеннар, ди? (Туган якта.) Ни өчен юллар кабатлана? (Хисне көчәйтү өчен.)

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Һ.Такташның балачагы ничек үткән? Нинди шигырьләр язган?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) беренче өлешне сәнгатьле укырга;

ә) ошаса, яттан өйрәнергә;

б) әсәрдә сурәтләнгән табигать рәсемен ясарга.

## Укытучы өчен өстәмә материал

1) 1901 елның 1 нче гыйнварында Мордва Республикасы Тарбеево районы Сыркыды авылында урта тормышлы крестьян гаиләсендә бер ир бала дөньяга килә. Баланың атасы Хәйрулла исемле, ә анасы Шәмсениса исемле була. Дини гореф-гадәт буенча, мулла чакыртып, балага Мөхәммәтҗан дип исем кушалар. Ләкин Шәмсениса апага бу исем ошамый. Гадәттә мишәрләр Мөхәммәтҗан дигән исемне Мокамай дип бозып әйтәләр. Бәлки шул сәбәпледер, Шәмсениса апа, ире белән сөйләшеп, баланың исемен Мөхәммәтһади дип алмаштыра.

Шәмсениса апа Һадиның балачагы, шаянлыклары турында сөйләргә яраткан. Менә Һадинең 5—6 яшьлек чагы. Башка малайлар белән бергә Хәсәннәр бакчасына кереп, кыярларын урлап чыкканнар. Зуррак балалар йөгереп качканнар, ә Һадины Хәсән абый эләктереп алган. Бер кулы белән колагыннан тотып, икенчесе белән балага суккалый, кычкырып тирги икән. Тавышны ишетеп, Шәмсениса апа урамга йөгереп чыга: «Хәсән абзый, ни өчен кыйныйсың?» — ди. «Әнә үзе әйтсен», — дип, Хәсән абзый китеп бара. «Улым, ник еламыйсың, ичмасам, еласаң, кыйнаудан туктар иде», — ди әнисе. «Еласам, малайлар ишетерләр дә аннары мине беркайчан да разбуйникка алмаслар», — дип җавап бирә Һади. Әнисе «разбуйникның» корсагына кысып тоткан күлмәк итәген ачып карый. «И балам, бу нәни генә кыярларны ничек жәлләми өздең соң, борыннарыннан чәчәкләре дә төшмәгән бит әле!» — ди. Шул чагында Һади, малайлар ишетү ихтималын да онытып, кычкырып елап җибәрә. «Хәзер нәрсәгә елыйсың инде?» — дип сорый әнисе. «Бик нәниләр бит әле-е-е, хәзер үсәлмиләр бит инде», — дип такмаклый Һади.

Шулай бервакытны Шәмсениса апа Һадины арыш көлтәсе өешергә алып бара. Көн бик эссе. Эш тә җиңел түгел. Менә чүмәлә өстенә менеп баскан Һади: «Әни, безнең өй турысында төтен күренә, пожар түгел микән?» — ди. Әнисе хәйләне сизә. Ләкин: «Улым, бар, өйгә кайт, пожар булса килеп әйтерсең, булмаса, килеп тормассың», — ди. Һади, чүмәләдән төшеп, авылга таба йөгерә. Ләкин түзеп күп бара алмый, юлдан борылып, Парча елгасына су керергә чаба. Әнисе улының йомгак шикелле генә гәүдәсенә кызганып карап: «Көнозын су буенда уйнап кына йөрергә иде дә бит, балам», — дип уйлый.

Һади Такташ әнисен бик хөрмәт иткән. «Минем шагыйрь булып китүемә әниемнең тәэсире зур», — дип яза Такташ бер истәлегендә. Алар хатларны да бер-берсенә шигырь белән язганнар. Әнисе Шәмсениса апа гади вакыйгаларны да күңелгә үтемле итеп сөйләүче, җыр, бәетләр чыгаручы сүз остасы булган.

Һади укырга да бик сәләтле бала була. Башта әнисе укыта, мәктәп яшенә җиткәч, мәдрәсәгә бирәләр. Үзенең тырышлыгы, зирәклеге белән бик тиз танылa. Алдынгы укучыларның берсе була.

Такташевлар гаиләсе бик ишле булган, 9 баланың 6 сы исән-имин үскән. Һади гаиләдә өченче бала була. Һади Такташның сеңлесе Хәнифә апа үзенең бер истәлегендә болай дип язган:

«Китап сатып алыр өчен, әни Һади абыйга үзенең чәченә үреп йөри торган тәңкәләрен (чулпы) берәм-берәм бирә торган иде».

2) Шәүкәт Галиев Һади Такташ турында «Чулпы чыңы» дигән шигырь язган.

Чылтыр-чылтыр чулпы чыңлавы...
Елтыр күзле малай бишектә.

Биләүләрдә яткан чактан ук
Шушы җырны Һади ишеткән.

Сөйләшәләр нидер тәңкәләр,
Серләшәләр нидер тәңкәләр.
Тәңкәләрнең телен кем белгән,
Бала күңелен белә әнкәләр.

...Уеннарын ташлап, бер көнне
Чабып керә Һади ишектән:
— Бик кызыклы китап саталар,
Алыйк әле, әнкәй, ничек тә!

Шәмсениса апа ни дисен,
Юк акчаны каян аласы?
Зәңгәр күзен төбәп, ялварып,
Өметләнеп тора баласы.

Чылтыр-чылтыр чулпы чыңлавы
Тынып кала ана кулында.
Ана кулы — калын толымда,
Толымдагы тәңкә — улында.

Ничәнче кат Һади шатлана,
Ничәнче кат Һади очына —
Ничәнче кат инде әнкәсе
Көмеш тәңкә сала учына.

3) Фәүзия Бәйрәмованың Һади Такташ турында «Мишәр улы» исемле китабы бар.

## 49—50 нче дәресләр

**Тема:** Әкияттәге ике бала кебек...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — һәр кеше тормышында хатирәләр булуы, аларның яхшы яки начар булуының кешенең үзеннән күп торуы турында аңлау.

Предмет — поэма турында теоретик төшенчә белән танышу, «Мокамай» поэмасын уку, аңлау.

Шәхескә кагылышлы — чын дуслык кадере, ялгыш адым ясамаска кирәклек турында аңлау.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 55—59 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар: Һ.Такташ портреты.

## Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

1) Һ.Такташның тормышы, балачагы турында алдагы дәрестә үткәннәрне искә төшерү.

2) Өй эшен тикшерү: поэмадан өзекне сәнгатьле уку яки яттан сөйләү (теләк буенча), рәсемнәргә күзәтү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бу ике дәреснең темасы — Һади Такташның «Мокамай» әсәре. Димәк, әлеге дәресләрдә «Мокамай» әсәрен укырга, аңларга тиешбез.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

<u>I дәрес.</u>

1. Сүзлекчә белән эш, сүзлектән чыгып, эчтәлек турында фикер йөртү — нәрсәләр аңларга була?

2. 55 нче биттәге өзекне тыңлау (аудиоязма яки укытучының сәнгатьле укуы). Китаптан карап бару кирәкми, шигырьнең ритмын, матурлыгын тоемларга өйрәнсеннәр. Шул ук вакытта ишетеп аңлау күнегүе — тыңлап аңларга тырышалар.

— Сүз нәрсә турында бара?

3. Мокамайның кем икәнлеген аңлату.

* Мокамай — кушамат. Дөресе — Мөхәммәтҗан. Ул Сыркыды авылының Бәкер исемле иң ярлы бер кешенең баласы иде. Соңгы елларда авылда арба тәгәрмәче урлауда гаепләнеп, җыенда кыйналган һәм идән астына ябылып, шунда үзен үзе үтергән. *(Һ.Такташ искәрмәсе.)*

4. Поэманың тыңланган өлешен укып, тәрҗемә итү.

5. Бөтен әсәр белән өлешләп танышып чыгу.

6. 59 нчы биттәге сораулар һәм биремнәрне телдән эшләү.

<u>II дәрес.</u>

Поэма белән эшләү. Укучылар әле әдәби әсәргә анализ ясарга авырсыналар, әсәр белән анализ элементлары кертеп эшләү (төркемнең эшли алу дәрәҗәсенә карап).

1) Бу поэмада нинди алымнар бар. (Чагыштыру.)

— Кем белән кем чагыштырыла?

— Мокамайның нинди уңай яклары бар?

— Нинди начар яклары бар?

— Мокамайның үлеме лирик геройда нинди хис тудыра? (Үкенү хисе.)

— Дустының хатасын ул ничек атый? (Адашу, ялгыш адым ясау.)

— Тагын кабатлау алымы бар. «Әкияттәге ике бала кебек» — бу сүзләрне автор дүрт мәртәбә кабатлый. Шушы сүзләрне кат-кат кабатлап, шагыйрь нәрсә әйтергә тели? (Дус булулары турында.)

Шушы кабатлау аша әсәрнең мөһим эчтәлеген табабыз. 1) Лирик геройның дустына булган чиксез мәхәббәте ачыла. 2) Лирик геройны дусты турында начар сөйләүләре борчый. Борчылу беренче өлештә дә бар иде — лирик герой агачлар шаулавын оныта алмый — дустының начар исеме өчен борчыла.

— Димәк, бу поэмасын шагыйрь ни өчен яза? (Аның «карак» дигән исемен бетерү өчен.)

— Дустының үлеме ничек кенә авыр булмасын, шагыйрьне дусты турында начар сүз яшәве борчый. Шуңа күрә ул кат-кат кабатлый, сине карак итеп сөйләмәм, ди. Лирик герой дустына тугрылыклы булып кала: ул балачакта Мокамайны үзеннән өстен итеп тасвирлый.

2) Эш дәфтәрендәге биремнәр — дәрестә бергәләп эшләү өчен.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Һ.Такташның балачагы ничек үткән? Бу турыда белү поэманы аңларга ярдәм итәме? Поэма нәрсә ул? «Мокамай» поэмасы турында нәрсәләр исегездә калды?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) поэманың ошаган өлешен сәнгатьле укырга өйрәнергә;

ә) ошаган өзекне яттан өйрәнергә була;

б) эш дәфтәрендәге 3 нче бирем — дустыңа хат язарга.

## 51—52 нче дәресләр

**Тема:** Бәхетне, шатлыкны сакларга кирәк.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү.

Предмет — Ренат Харис иҗаты белән танышу, пьесаны укып, нәтиҗә ясау, «диалог» һәм «монолог» теоретик төшенчәләрен әдәби термин буларак истә калдыру.

Шәхескә кагылышлы — ваемсызлыкның нинди куркыныч нәтиҗәләргә китергәнен аңлату, үзләре өчен дә, әйләнә-тирә өчен дә җаваплылык хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 60—68 нче битләр, эш дәфтәрендә 45, 46 нчы битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), парлап эшләү өчен карточкаларда сораулар, Р.Харис китаплары, слайдлар: Р.Харис портреты, аның рәсемнәре, пьесадагыча урман аланы күренеше, ябалак рәсеме.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, дәресне башлау. Хәлләрен, нинди кәеф белән килүләрен сорашу. Психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: поэмадан өзекне сәнгатьле уку яки яттан сөйләү (теләк буенча), язган хатларны тикшереп, билгеләр кую, хаталарын аңлату.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Чираттагы 2 дәреснең темасы — Ренат Харисның «Серле алан» пьесасын уку.

Темадан чыгып, дәрескә уку мәсьәләсен кую (Р.Харис турында белү, пьесаны уку, аңлау, төп геройлар турында сөйли белү).

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Шагыйрь Ренат Харисның тормыш юлы, иҗаты белән танышу. Бу — укытучы сөйләве, презентация карау, алдан әзерләнгән укучыларның чыгышлары да булырга мөмкин.

2. Дәреслектәге биографик белешмә белән укучыларның танышуы. Сорауларга җавап бирү — алдан әзерләнгән карточкаларда сораулар, парларда яки төркемнәрдә сорау — җавап.

Ренат Харис — күпкырлы талант иясе. Аның рәсемнәре белән дә танышу. (Дәреслектә, Интернет челтәрендә, китапларында.)

3. Сүзлек эше.

4. Пьеса белән танышу: рольләргә бүлеп уку, тәрҗемә итү, эчтәлек буенча әңгәмә.

5. Дәреслектәге сораулар һәм биремнәр.

6. Теоретик төшенчәләр (символик образ, диалог, монолог) белән эш.

— Карт Ябалакны нәрсә дип атый? (Уяулык.) Шулай була аламы? Бу — символик образ.

7. — Әсәрдә нинди символик образлар бар? (Пьесадан эзләп җавап бирү.)

8. Эш дәфтәрендәге биремнәрне эшләү. Телдән эшләнгән эш ныгытыла.

9. Эш дәфтәрендәге бирем — җөмләләргә карап, бергәләп эчтәлек сөйләү (чылбыр буенча).

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәтиҗә чыгару.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) картның соңгы сүзләрен яттан өйрәнү;

ә) пьесаның эчтәлеген сөйләү;

б) символик образларның рәсемнәрен ясау.

* Н.Сладковның «Дуслар-ахирәтләр» экияте — өстәмә уку өчен.

## 53 нче дәрес

**Тема:** Дуслык, чын дуслык.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — шигъри әсәрне җиңел истә калдыру ысуллары белән танышу.

Предмет — Э.Шәрифуллина турында мәгълүмат бирү, дуслык турында шигырьне уку, дуслык турында мәкальләр истә калдыру, сөйләм телен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — дуслыкның кеше өчен мөһимлеген аңлату.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 72—73 нче битләр, эш дәфтәрендә 46, 47 нче битләр).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), Э.Шәрифуллина портреты, китаплары.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Исәнмесез, укучылар. Әйдәгез, бер-беребезгә уңышлар, яхшы кәеф теләп, дәресебезне башлап җибәрик.

***2. Актуальләштерү***

1) Өй эшен тикшерү: «Серле алан» пьесасының эчтәлеген яки картның сүзләрен яттан сөйләгәнне тыңлау.

2) Өйдә «Дуслар-ахирәтләр» укылса, эчтәлек турында фикер алышу.

— Аю ни өчен елый, кайгыра? Дусларсыз калу яки дусларың булмау авырмы?

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Дуслык турында язылган әсәрләрне укуны дәвам итәбез. Дәреслектән карап әйтегез: бүген безгә дәрестә нишләргә кирәк? («Дуслык, чын дуслык!» шигырен укырга, аңларга, ятларга, авторы турында белергә.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Э.Шәрифуллина иҗаты белән танышу.

— Без укыячак шигырьне кем язган? Сезнең аның турында ишеткәнегез бармы? Дәреслектәге биографик белешмәне үзегез укып, сорауларга җавап эзләгез:

— Кайда туган? Кайчан туган? Кайда укыган? Кем булып эшләгән? Нәрсәләр яза? (Бу текст җиңел тел белән язылган, сорауларга тәрҗемәсез генә җавап бирсеннәр.)

2. Сүзлек эше. Дәреслектә бирелгән сүзләргә өстәп, *көч, иптәш, бергә бул — булыйк* кебек таныш булырга тиеш сүзләрнең тәрҗемәсен белү-белмәүләренә дә игътибар итү, искә төшерү. Сүзләр белән җөмләләр төзү.

3. Шигырь белән танышу.

1) Шигырьне тыңлау, ишетеп аңлауны тикшерү, фикер алышу.

2) Укучыларның үзләренең укуы.

3) Эчтәлек буенча әңгәмә:

— Ничек юл кыскара ала? «Куллар кулга көч бирү» дигәнне ничек аңлыйсыз? «Яшик кояшлы елда» — ел буе кояш була аламы? Дуслыкның көче нәрсәдә?

4. Дәреслектәге сораулар һәм биремнәр.

5. Эш дәфтәрендәге дуслык турында мәкальләрне русчага тәрҗемә итү, мәкаль эчтәлеге турында сөйләшү.

6. Укучыларның үз дуслары турында сөйләшү. Тактада сораулар:

— Синең дусларың күпме? Алар кемнәр? Сез бергә нишлисез? Әгәр бер дустыгыз авырса, аның хәлен беләсезме? Бер-берегезгә булышасызмы?

— Иң якын дустың бармы? Ни өчен ул иң якын дус? Сезне нәрсә берләштерә? Ул нинди?

7. Эш дәфтәренә дуслары турында язу.

8. Эш дәфтәрендәге 1 нче биремне эшләгәнче, укучылар шигырьне кат-кат укыйлар (эчтән уку, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча уку, сәнгатьле уку, йөгерек уку, әкрен уку, «көләкөлә» уку, «елый-елый» уку, башкаларны көлдерерлек итеп уку һ.б.) Соңгы бирем — күбрәк истә калдырырга тырышып уку. Аннары эш дәфтәрендә төшеп калган сүзләрне истә калганча язып карау, тикшерү, төзәтү. Бу — шигырьне яттан өйрәнүгә әзерлек.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәтиҗә чыгару.

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларның үз-үзләрен бәяләве.

3. Өй эше: а) шигырьне яттан өйрәнү;

ә) якын дусларына бүләк-открытка ясау (шигырь юлларын кертеп);

б) татарча нинди газета-журналлар бар? Белеп килергә.

## 54 нче дәрес

**Тема:** Дуслык булса, яшәр тынычлык.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — шигърияtне әдәбият теориясе, җыр, рәсем белән бәйләнештә карау.

Предмет — шигырьгә анализ ясый белү, Ш.Галиевнең иҗатын, тормыш юлын белү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — поликультуралылык, толерантлык хисләре тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 74—76 нчы битләр), эш дәфтәрендә 47, 48 нче битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), Ш.Галиев китаплары, слайдлар: Ш.Галиев портреты, умарта, бал кортлары

рәсемнәре, Россия картасы (Татарстан белән Башкортстанның чиктәш икәнлеген карау өчен), төрле милләт вәкилләренең милли киемнәренең рәсемнәрен.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау. Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: шигырьне яттан сөйләү, Э.Шәрифуллина эшләгән һәм тагын башка татарча газета-журналларга кыскача күзәтү ясау (укучыларның өй эше буенча).

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Бүгенге дәреснең темасы — Шәүкәт Галиевнең «Дуслык балы» шигыре. Уку мәсьәләсе куябыз. (Шагыйрь турында искә төшерергә (5 нче сыйныфта үткәнне), шигырьне укырга, аңларга.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Шагыйрьнең тормыш юлы турында сөйләшү.

— Бу шагыйрь безгә таныш. Аның турында нәрсәләр әйтә аласыз?

Дәреслектән биографик белешмәне уку. Ш.Галиев иҗаты турында сораулар төзиләр, җавап бирәләр.

2. Сүзлек эше.

3. Шигырьне укуга әзерлек.

— Ничек уйлыйсыз: шигырь нәрсә турында икән? Сезнең бал ашаганыгыз бармы? Ә дуслык балы ашаганыгыз?

4. Шигырьне сәнгатьле уку, тыңлау, ишетеп аңлау аша эчтәлек буенча әңгәмә.

5. Шигырьне чылбыр буенча уку, сүзгә-сүз тәрҗемә итү. 1—3 нче сорауларга җавап бирү.

6. Эш дәфтәрендәге 1, 2 нче биремнәр.

7. 3 нче биремнән төрле милләт вәкилләренең рәсемнәре куелган презентациягә яки рәсемнәр күргәзмәсенә күчәбез. Һәр милләтнең теле, милли киемнәре турында сөйләшәбез. (Үрнәк слайдта (тактада): Чувашлар — чувашча, чуваш телендә сөйләшә. Аларның милли киемнәре кызыл, зәңгәр, ак, кара төстә. Хатын-кызлар күлмәк, яулык (калфак, кокошник һ.б), читек яки туфли кияләр. Ир-егетләр түбәтәй, бүрек, чалбар, күлмәк кияләр.)

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Ш.Галиев турында нәрсәләр әйтә аласыз? Шигырь аңлашылдымы, ошадымы? Нәрсә ошады яки ошамады?

2. Дәрескә гомуми бәя. Үзбәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга;

ә) шагыйрь турында белешмәне тагын укырга, кабатларга;

б) милли костюмнар яки бер милләтнең милли киеме турында рәсемнәр (презентация) әзерләргә, сөйләргә.

**Укытучы өчен өстәмә материал.**

http://www.lib05.ru, http://ppt4web.ru сайтларыннан милли киемнәр турында мәгълүмат, презентация алырга мөмкин.

## 55 нче дәрес

**Тема:** Кабатлау, йомгаклау.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укыганны искә төшереп, гомумиләштерә, командада эшли белү.

Предмет — Дәрдемәнд, Һ. Такташ, Р.Харис, Ш.Галиев, Э.Шәрифуллиналар турында төп мәгълүматны, укыган әсәрләрен истә калдыру.

Шәхескә кагылышлы — туганнар, яшьтәшләр, төрле милләтләр, илләр арасында дуслыкны аңлау, дус яшәүгә омтылыш тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 50—76 нчы битләр).

**Җиһазлау:** язучыларның портретлары, төрле әсәрләргә туры килә торган рәсемнәр.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Хәерле көн, укучылар! Кәефләрегез ничек? Дәресне башлыйбыз.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: «Дуслык балы» шигырен сәнгатьле уку.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәреснең максаты — «Илдә илле дустың булсын» бүлеген кабатлау, үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Портретлар, рәсемнәр ярдәмендә язучылар, аларның әсәрләре турында белемнәрне кабатлау. Төркемнәргә бүленеп эшләү.
2. Бу бүлекнең исеме, эчтәлеге, иң ошаган әсәр турында әңгәмә.
3. Мөстәкыйль эш — тест сорауларына җавап бирү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. Эшләрне укытучыга биргәч, телдән җавапларны тикшерү.
2. Бәяләү. Үзбәя.
3. Өй эше: бу бүлектәге өстәмә уку өчен бирелгән шигырьләрне укырга, эш дәфтәрендәге биремнәрне үтәргә (сайлап).

## 56 нчы дәрес

**Тема:** Шәүкәт Галиев — юмор остасы.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — елга башланган җир турында белү.

Предмет — Ш.Галиевнең иҗаты, юмористик шигырьләре белән танышу, шигырьгә анализ ясый белү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — экологик тәрбия бирү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 78—79 нчы битләр), эш дәфтәрендә 48, 49 нчы битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), Ш.Галиев китаплары, слайдлар: Ш.Галиев портреты, урман, авыл, елга, чишмә рәсеме, терәк сүзләр*: кошларга җимлекләр куялар, ашаталар, кышын пошиларга ашарга куялар, сыерчык оялары ясыйлар, авыру, корган агачларны кисәләр.*

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

— Яңа бүлекнең темасы андагы әсәрләрнең нәрсә турында буласын хәбәр итәме? 5 нче сыйныфта шундый әсәрләр белән таныштыкмы? Әдәбиятта аларны ничек атыйлар? (Юмор *(инглизчә:*

*холык, кәеф)* — көлкеле сурәтләү, көлүнең бер формасы. Көлү объектын яратып, якын итеп көлүгә нигезләнә.)

— Нинди шагыйрьләр, язучыларның юмористик әсәрләрен укыган идек, хәтерлисезме? (Л.Лерон, А.Гыймадиев, Ш.Галиев.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Ш.Галиевнең тагын юмористик шигырьләрен укырбыз (шигырьне укып аңларга, сәнгатьле укырга, анализ ясарга тиешбез).

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Сүзлек эше.

2. «Курыкма, тимим!» шигырен тыңлау. Сорауларга җавап бирү:

— Малай кая килгән? Малайдан кем (нәрсә) курыккан? Малай аларга нәрсә дигән? Авылга нәрсә (кем) килгән? Кем кемнән курыккан? Ни өчен Тиен, Куян — малайдан, малай Аюдан курыккан? (Көчлерәк, тияргә мөмкин, малайлар рәнҗетәләр.)

— Ни өчен җәнлекләр кешеләрдән куркалар? Кешеләр нишли? (Җәнлекләргә, кошларга тияләр, агачларны сындыралар, кош ояларын туздыралар, кырмыска ояларын җимерәләр, җәнлекләрне куркыталар, учак ягалар.) Кешеләр барысы да зыян китерәме? Кешеләр нинди яхшы эшләр эшлиләр? (Кошларга җимлекләр куялар, ашаталар, кышын пошиларга ашарга куялар, сыерчык оялары ясыйлар, авыру, корган агачларны кисәләр.) Бу сүзтезмәләрне тактага язып, җөмләләр төзибез. (Кешеләр урманда нишлиләр? Сез җәнлекләргә тиясезме? Сез шәфкатьлеме, ярдәмчелме?)

3. Тактадагы сүзләр белән җөмләләр төзеп әйтү. (Урманда кошларга тияргә ярамый. Кошларга җимлекләр ясарга кирәк.)

4. Эш дәфтәрендәге таблицаны тутыру (2 нче бирем).

5. «Атлап чыктым Иделне» шигыре белән танышу. Сораулар һәм биремнәр. Картадан Идел елгасын табу.

6. — Бу шигырьләрдә юмор бармы? Нинди алымнар кулланылган? (Кабатлаулар, каршы кую.)

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле укырга;

ә) эш дәфтәрендәге 3 нче биремне үтәргә;

б) урманда нишләргә ярый, нишләргә ярамый — шул турыда сөйләргә.

### Укытучы өчен өстәмә материал

Исток Волги — ключ у деревни Волговерховье в Тверской области на Валдайской возвышенности (на высоте 228 м). В верхнем течении, в пределах Валдайской возвышенности Волга проходит через небольшие озёра — Малое и Большое Верхиты, затем уже через систему крупных озёр, известных как Верхневолжские озёра: Стерж, Вселуг, Пено и Волго, объединённые в такназываемое Верхневолжское водохранилище.

Первый крупный населённый пункт на Волге от истока — город Ржев.

Между городами Тверь и Рыбинск на Волге созданы Иваньковское водохранилище (так называемое Московское море) с плотиной и ГЭС у г.Дубна, Угличское водохранилище (ГЭС у Углича) — Рыбинское водохранилище (ГЭС у Рыбинска). В районе Рыбинск — Ярославль и ниже Костромы река протекает в узкой долине среди высоких берегов, пересекая Угличско-Даниловскую и Галичско-Чухломскую возвышенности. Далее Волга течёт вдоль Унженской и Балахнинской низменностей. У Городца (выше Нижнего Новгорода) Волга, перегороженная плотиной Нижегородской ГЭС, образует Горьковское водохранилище.

Крупнейшие притоки верхней Волги — Селижаровка, Тьма, Тверца, Молога, Шексна, Которосль и Унжа.

В среднем течении, ниже впадения Оки, Волга становится ещё более полноводной. Она течёт вдоль северного края Приволжской возвышенности. Правый берег реки высокий, левый — низменный. У Чебоксар построена Чебоксарская ГЭС, выше плотины которой расположено Чебоксарское водохранилище. Наиболее крупные притоки Волги в её среднем течении — Ока, Сура, Ветлуга и Свияга.

В нижнем течении, после впадения Камы, Волга становится могучей рекой. Она протекает здесь вдоль Приволжской возвышенности. Около Тольятти, выше Самарской Луки, которую образует Волга, огибая Жигулёвские горы, сооружена плотина Жигулёвской ГЭС; выше плотины простирается Куйбышевское водохранилище. Нижняя Волга принимает сравнительно небольшие притоки — Сок, Самару, Большой Иргиз, Еруслан. ***(https://ru.wikipedia.org/wiki)***

## 57 нче дәрес

**Тема:** Ике тиен — зур акчамы?

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — укыган әсәрне бүгенге көн, көндәлек тормыш белән бәйләнештә күзаллый белү.

П р е д м е т — Ф.Шәфигуллин тормышы, иҗаты белән танышу, «Ике тиен акча» хикәясен аңлап уку, юмор аша язучы әйтергә теләгән фикерне эзләргә өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы —әхлак тәрбиясе бирү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 80—82 нче битләр), эш дәфтәрендә 49, 50 нче битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), Ф.Шәфигуллин китаплары, слайдлар: Ф.Шәфигуллин портреты, музейдан фотосурәтләр.

## Д ә р е с б а р ы ш ы:

### I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Кәефләрне сорашу. Бер-берләренә комплиментлар әйтеп, яхшы теләкләр теләп, дәресне башлау.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: шигырьне сәнгатьле уку.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Дәрес темасы — Фаил Шәфигуллин иҗаты, «Ике тиен акча» хикәясе. Дәрескә уку мәсьәләсен куйыйк. (Язучы турында белергә, хикәяне укырга, аңларга.)

### II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Фаил Шәфигуллин турында презентация карау, китапларын күрсәтеп, укытучы сөйләве яки алдан әзерләнгән укучыларның чыгышы.
2. Дәреслектән биографик белешмәне укып, сорауларга җавап бирү.
3. Ф.Шәфигуллинның музее турында уку.
4. Дәреслекне кулланып, эш дәфтәрендәге таблицаны тутыру.
5. Сүзлекчә белән эш.

— Сүзлек белән танышкач, исеменә карап, хикәя нәрсә турында дип уйлыйсыз?

6. Хикәяне тыңлау. Сүзгә-сүз тәрҗемә итмичә, дәреслектәге сораулар һәм биремнәрне эшләү.
7. Эчтәлек буенча фикер алышу. Язучының соравына җавап бирү (хикәя сорау белән тәмамлана).
8. Хикәяне анализлау. Сюжет элементларын табу.

— Юмор кайда? Язучы нәрсә әйтергә теләгән?

9. Эш дәфтәрендәге биремнәр (телдән эшләгән материал тагын кабатлана).

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) эш дәфтәрендәге биремнәрне эшләп бетерергә;

ә) «Акбай белән Карабай» хикәясен укырга (кем күпме укый, аңлый ала);

б) Ф.Шәфигуллин турында сөйләргә.

**Укытучы өчен өстәмә материал**

http://www.sptatar.ru/index.php/2012-08-06-14-40-58/343-elmajta-da-ujlata-da

## 58 нче дәрес

**Тема:** Акбай белән Карабай.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр***:*

Метапредмет — көндәлек тормышка юмор белән карый белергә өйрәнү.

Предмет — Ф.Шәфигуллинның тормышы, иҗаты турында мәгълүматлы булу, «Акбай белән Карабай» хикәясен уку, юмор аша язучы әйтергә теләгән фикерне табу.

Шәхескә кагылышлы — әхлак тәрбиясе бирү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 83—86 нчы битләр), эш дәфтәрендә 50, 51 нче битләр.

**Җиһазлау:** Ф.Шәфигуллин китаплары, слайдлар: Ф.Шәфигуллин портреты, музейдан фотосурәтләр, ак һәм кара көчек рәсемнәре.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Укучыларда уңай психологик халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Эш дәфтәрендәге биремнәрне тикшерү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

— Дәрес темасы — Фаил Шәфигуллин иҗаты, «Акбай белән Карабай» хикәясе. Дәрескә уку мәсьәләсен куйыйк. (Язучы турында белергә, хикәяне укырга, аңларга.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Язучы тормышы, иҗаты, музее турында белемнәрне ны-

гыту. Төркемнәргә бирем: язучы турында сораулар әзерләргә. Кайсы төркемнең сораулары күбрәк һәм дөрес җаваплары күбрәк — шулар җиңүче.

2. «Акбай белән Карабай» хикәясе белән эш.

— Өйдә укыдыгызмы? Хикәя нәрсә турында?

3. Хикәяне чылбыр буенча уку, тәрҗемә итү. Эчтәлек буенча фикер алышу.

— Язучы нәрсә әйтергә теләгән?

4. Дәреслектәге сораулар һәм биремнәр.

5. Эш дәфтәрендәге биремнәр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Үзбәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) эш дәфтәрендәге биремнәрне эшләп бетерергә;

ә) эш дәфтәрендәге план буенча Акбай белән Карабай турында сөйләргә;

б) үзләренең (күршенең, туганнарының) эте (песи, әрлән) турында сөйләргә.

## 59 нчы дәрес

**Тема:** Шаянлык файдасы.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет —сөйләм телен үстерү.

Предмет — галим В.Радлов турында мәгълүмат бирү, хикәяне уку.

Шәхескә кагылышлы — күп телләр белүгә теләк булдыру, телләргә ихтирам тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 88 нче бит), эш дәфтәрендә 51 нче бит.

**Җиһазлау:** В.Радлов портреты.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

— Хәерле көн, укучылар! Хәлләрегез ничек? Бүгенге дәресебезне башлыйбыз.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: укучыларның Акбай белән Карабай турында сөйләүләрен тыңлау.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәрес темасы — Василий Радловның «Шаян кеше» хикәясен уку.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Укытучының галим Василий Радлов тормышы белән таныштыруы.

2. «Шаян кеше» хикәясе белән танышу.

1) Сүзлек эше.

2) Сәнгатьле укыганны тыңлау, эчтәлек буенча фикер алышу.

— Тапкырлык, юмор хисе тормышта ярдәм итәме?

3) Дәреслектәге сораулар һәм биремнәр.

4) Хикәяне чылбыр буенча уку, русчага сүзгә-сүз тәрҗемә итү.

5) Эш дәфтәрендәге биремнәр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) «Шаян кеше» хикәясе буенча сораулар язарга;

ә) хикәянең эчтәлеген сөйләргә;

б) «Сезнең танышларыгыз арасында тапкыр, юмор хисле кешеләр бармы? Кызыклы вакыйгалар булганы бармы? Сыйныфташларыгызга сөйләргә әзерләнегез.»

## Укытучы өчен өстәмә материал

Шәрык телләре белгече, этнограф, фольклорчы, академик Василий Васильевич Радлов (Фридрих Вильгельм) 1837 елда Германиянең Берлин шәһәрендә полиция чиновнигы гаиләсендә туа. 1854 — 1858 елларда Берлин университетының тарих-филология бүлеген тәмамлый. Аның кызыксыну өлкәсе Көнчыгыш төркиләрнең теле һәм этнографиясе була. Шушы теләк Радловны 1858 елда Россиягә, Петербург шәһәренә алып килә. Ул татар, фарсы, гарәп, кытай телләрен өйрәнә.

1859 елның 11 маенда ул Россиягә тугрылыкка ант итә һәм ватандашлыкны кабул итә. Шул көннән Вильгельм Фридрих Василий Васильевич Радлов булып китә.

Радлов Барнаулга укытучылык эшенә җибәрелә. Яшь белгеч кышын укыта, ә җәй айларында Алтай төбәге буйлап экспедицияләргә чыга: бай лингвистик материал җыя, төрки телнең җирле сөйләмен өйрәнә, археологик казу эшләре алып бара. «Образцы народной литературы тюркских племён» монографиясенең беренче өч томын

яза. Шушы төпле, тирән нигезле хезмәт нәтиҗәсендә, В.Радловның исеме фән дөньясында зур танылу ала.

1858 — 1870 елларда Себердә төрле юнәлештә зур фәнни-тикшеренү эшләре алып бара. Себер татарларының фольклорын җыя. «Көньяк Себердә һәм Жунгар далаларында яшәүче төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» (1872), «Төрки халыкларның рәвешләре сүзлеге тәҗрибәсеннән» (1888 — 1896), «Төрки халыкларның әдәбияты үрнәкләре» (1907) һәм башка хезмәтләр бастыра.

Василий Радлов 1871 — 1884 елларда Казанда яши һәм педагогик эш белән шөгыльләнә. Галим тормышының Казан чоры педагогик һәм административ эшчәнлек белән бәйле. Казан чорын, беренче чиратта, Казан округына кергән татар, башкорт, кыргыз мәктәпләренең инспекторы вазифасында башкарылган хезмәтләр билгели. Ул татар мәктәпләрен ачуда, укыту эшләрен уңай хәл итүдә күп эшләр башкара. Татар укытучылар мәктәпләре Уфада, Симферопольдә, ә 1876 елда Казанда ачыла. В.Радлов инициативасы белән, татар мәктәп-мәдрәсәләрендә рус сыйныфлары булдырыла, дөньяви фәннәр укытылган яңа татар мәктәпләре ачыла, татар хатын-кызлары өчен беренче мәктәп оештырыла.

Инспектор буларак, В.Радлов татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү мәсьәләсенә зур игътибар биргән. Казан Татар укытучылар мәктәбен оештыруга үзеннән зур өлеш керткән. В.Радлов мәктәпнең уку-укыту бүлеген җитәкләгән, педагогика, дидактика, тарих фәннәрен укыткан. 1876 — 1917 елларда бу уку йорты барлыгы 389 укытучы әзерләп чыгарган. Алар арасында Г.Исхакый, Г.Коләхмәтов, М.Корбангалиев, Х.Ямашев һ.б. бик күп күренекле шәхесләр бар. В.Радлов Казан университеты каршында оештырылган Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте эшендә актив катнашкан. Галим бу җәмгыятьнең күренекле вәкиле Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтен татар теленнән рус теленә тәрҗемә иткән һәм әлеге тәрҗемәне 1877 елда Казанда уздырылган IV Бөтенроссия археологик корылтаенда укыган.

Мәктәп балалары өчен «Белек» (1872), «Беренче уку китабы» (1874) исемле уку әсбаплары төзи. Ул 1884 елда яңадан Петербургка китә.

## 60 нчы дәрес

**Тема:** Кабатлау, йомгаклау.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

М е т а п р е д м е т — татар әдәбиятын рус әдәбияты белән чагыштыра, белгәннәрне кирәк ситуациядә искә төшереп куллана белү.

П р е д м е т — Ш.Галиев, Ф.Шәфигуллин, В.Радлов иҗатлары турында мәгълүматлы булу, берничә әсәрләрен белү.

Ш ә х е с к ә  к а г ы л ы ш л ы — әхлак тәрбиясе бирү, юморның кешеләрне тәрбияләүдә әһәмиятен аңлату.

**Материал:** методик әсбап, кушымтадагы тестлар.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), һәр укучыга тест, слайдларда тестларның биремнәре (һәр биремне укучыларга аңлату өчен).

**Д ә р е с  б а р ы ш ы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү***

Өй эшен тикшерү: «Шаян кеше» хикәясе буенча сораулар төзү, җавап бирү, кыскача эчтәлеген сөйләү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүлекне йомгаклау. Нәтиҗә ясау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Портретлар, төрле иллюстрацияләр ярдәмендә укылган әсәрләрне кабатлау, гомумиләштерү.

2. Мөстәкыйль эш: тест сорауларына җавап язу.

3. Телдән җавапларның дөреслеген тикшерү.

* 4. Өстәмә уку өчен бирелгән Г.Остерның «Серне ачты» хикәясен яки Н.Мадьяровның «Урман аланына баргач» шигырен укырга, биремнәрне эшләргә мөмкин.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларның мөстәкыйль эшләрен бәяләве.

3. Өй эше: өстәмә уку өчен бирелгән бер әсәр буенча эш дәфтәрендәге биремнәр.

4. Алдагы дәрескә проблема кую: яз, җәй турында шигырьләр белән танышырга.

## 61 нче дәрес

**Тема:** Җәйге иртә.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — рәсем сәнгатендә пейзаж белән әдәбияттагы пейзаж төшенчәсен бәйләнештә күзаллау.

Предмет — Р.Әхмәтҗанов турында мәгълүмат алу, «Иртә әле...» шигырен укып аңлау, «пейзаж» төшенчәсен белү, шигырьгә анализ ясау, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — табигать матурлыгын күрергә өйрәтү, экологик тәрбия бирү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 94—96 нчы битләр, эш дәфтәрендә 54 нче бит).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Р.Әхмәтҗанов портреты, шигырь җыентыклары, җәйге иртә күренешләре.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау. Психологик уңай халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасыннан чыгып, укучылар белән бергә уку мәсьәләсе кую. (Р.Әхмәтҗанов турында белергә, шигырьне укырга.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты белән танышу.

1) Презентация, укытучының сөйләве, китапларын күрсәтү.

2) Дәреслектәге биографик белешмәне уку. Укытучы сорауларына җавап бирү.

3) Дәреслектәге 1, 2 нче сорауларга телдән җавап бирү.

2. Шигырь белән эшләү.

1) Сүзлекчә белән эш. Сүзләрне тыңлау, кабатлау, дөрес итеп укып, тәрҗемә итү, сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү.

2) Шигырьне сәнгатьле укыганны тыңлау. Эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү.

3) Шигырьне чылбыр буенча уку, тәрҗемә итү.

4) Эчтән яки ярымтавыш белән уку. Кычкырып, сәнгатьле уку.

3. Дәреслектәге 3—10 нчы сорауларга җавап бирү.

4. Теоретик белешмәне уку. Шигырьдәге пейзажны исбатлау.

— Шигырьдә төп тема нәрсә? Рәссам булсагыз, шигырьнең эчтәлеген ничек ясар идегез? Мондый картиналарны сәнгатьтә нәрсә диләр? (Пейзаж.)

— Әдәбиятта да шулай ук пейзаж дип атала.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Үзбәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле итеп укырга;

ә) русча шигырьләрдән пейзажны тасвирлаган бер шигырь табарга, сәнгатьле укырга;

б) шигырьгә рәсем ясарга.

## 62 нче дәрес

**Тема:** Иң кадерлем — әнием.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — рәсем сәнгатендәге портрет белән әдәбияттагы портретны чагыштыру.

Предмет — Г.Рәхим турында белү, «Апрель» хикәсен укып аңлау, «портрет» төшенчәсе белән танышу, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — әниләргә карата ихтирам тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 97—99 нчы битләр), эш дәфтәрендә 54, 55 нче битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Г.Рәхим портреты, шигырь җыентыклары, апрель, яз күренешләре.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Исәнләшү. Дежур укучыны тыңлау. Һава торышы турында сөйләшү. Яхшы кәеф, уңышлы көн теләп, дәресне башлау.

***2. Актуальләштерү***

1) Табигать сурәтләнгән шигырьләрне уку, пейзаж икәнлеген табу, һәр шигырь аша табигать матурлыгына игътибар итү.

2) — Пейзаж кебек, сәнгатьтә тагын нинди картиналар була? (Кешене сурәтләү «портрет» дип атала.)

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасыннан чыгып, укучылар белән бергә уку мәсьәләсе кую.

— Укыганда, сорауга җавап эзләгез: портрет күз алдына киләме? Язучы  хикәясендә портретны ничек бирә, ни өчен бирә Иң матур кешене башкалар да белсен өченме? (Ул әнисен чибәр итеп түгел, ничек бар шундый итеп сурәтли.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Гәрәй Рәхимнең тормышы, иҗат юлы белән таныштыру — укытучы сөйләве яки презентация.
2. Дәреслектәге 1, 2 нче сораулар.
3. Сүзлек эше. Дәреслектәге сүзлекчәне тәрҗемә итү, дөрес итеп уку, кабатлау, җөмләләр төзү. Хикәядән бу сүзләрне эзләп табу, җөмләләрен тәрҗемә итү.
4. Хикәяне тыңлау. Сорауларга җавап.

— Хикәя нәрсә турында? Вакыйгалар бармы? Апрель турында нәрсә яза?

5. Хикәяне чылбыр буенча уку, сүзгә-сүз тәрҗемә итү.
6. 3, 4, 5 нче сорауларга җавап бирү яңа әдәби терминны аңларга ярдәм итә. Теоретик төшенчә укыла.
7. Яңадан хикәяне уку, язучы нәрсәне нәрсә белән чагыштыра — укыганда ук әйтеп бару.

— Язучының әнисен күз алдына китердегезме? Ул нинди? (Фикерләрен русча әйтәләр.) Хикәя белән автор нәрсә әйтергә тели? (Әнисенә мәхәббәт, ихтирам, аның авыр тормышы, яратып үстергәне өчен рәхмәт, киләчәккә ышаныч та әнисе күзләре аша бирелә.)

— Лирик герой әнисен яратамы? Ул аның белән ничек сөйләшә икән? Ямьсез сүзләр әйтеп кычкырамы икән? Ә тормышта шундый кешеләр еш очрый бит. Аларның әниләре начармы? Аларның әниләре балаларына  начарлык теләгәннәрме? Сез әниегез белән ничек сөйләшәсез? Аңа ярдәм итәсезме?

8. Дәреслектәге 6 нчы сорау. (Без әниләргә бурычлы.)
9. Эш дәфтәрендәге биремнәр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсен чишә алдыкмы? Нинди яңа мәгълүмат алдыгыз?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) хикәяне сәнгатьле итеп укырга;

ә) русча шигырьләрдән портрет эзләргә;

б) әниегезнең портретын сүзләр белән язарга.

## 63—65 нче дәресләр

**Тема:** Көтеп алган Сабантуй.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — төрле бәйрәмнәрнең (бу очракта Сабантуй мисалында) тарихы белән кызыксыну.

Предмет — Г.Бәширов турында белү, «Язгы сабан туйлары» өзеген укып аңлау.

Шәхескә кагылышлы — халыкның гореф-гадәтләренә, йолаларына ихтирам тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 103—108 нче битләр), эш дәфтәрендә 55, 56 нчы битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: Г.Бәширов портреты, «Туган ягым — яшел бишек» һәм башка китаплары, Сабантуй күренешләре.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Укучыларның хәлләрен сорап, яхшы кәеф, уңышлар теләп, дәресне башлау.

***2. Актуальләштерү***

1) Укучылар алып килгән шигырьләрдән әдәби портретны табып уку.

2) Алдагы дәреснең өй эшен тикшерү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Дәреснең темасыннан чыгып, укучылар белән бергә уку мәсьәләсе кую.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

I дәрес

1. Гомәр Бәшировның тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру (укытучы яки алдан әзерләнгән укучылар сөйләве, презентация, фильм).

2. Дәреслектән язучы турында биографик белешмәне уку.

3. Парларда (төркемнәрдә) сораулар төзиләр, сорауларга җавап бирәләр. Язучыны башка әдипләр белән чагыштыралар:

— Тагын кем шул елны туган? (Һ.Такташ — 1901, 1 гыйнвар.)

— Кемнәр бу язучы белән бер яктан? (Г.Тукай.)

— Тагын кайсы язучылар укытучы булып эшләгән? (К.Насыйри, Р.Вәлиева, Э.Шәрифуллина)

— Тагын кайсы язучыларның автобиографик әсәрләре белән таныштык? (Г.Тукайның «Исемдә калганнар» әсәре.)

— Тагын кем фольклор өлкәсендә күп эшләгән? (К.Насыйри, Н.Исәнбәт.)

4. 104—105 нче битләрдәге өзекләр белән танышу. Эчтәлек буенча әңгәмә.

5. Сорауларга җавап. Сайлап уку күнегүләре. Укытучы әзерләгән Сабантуй рәсемнәренә туры килә торган җөмләләрне табу.

Өй эше: эш дәфтәрендәге биремнәр.

<u>II дәрес</u>

1. Г.Бәширов тормышын, иҗатын кабатлау. Сорауларга җавап (викторина формасында).

2. Әсәрнең 106—107 нче битләрдәге өзеген уку. Сүзлек эше, тыңлау, уку, тәрҗемә итү, сорауларга җавап бирү, сайлап уку.

3. Эш дәфтәрендәге биремнәр.

4. Сабантуй турындагы белешмәне уку. Әңгәмә, фикер алышу.

5. Өзекнең гади җөмләләр белән планын төзү. Истә калдырырга тырышу.

Өй эше: План буенча, 6—7 гади җөмлә белән, әсәрнең эчтәлеген яки Сабантуй турында сөйләргә.

<u>III дәрес</u>

1. Г.Бәшировның тормыш юлын, иҗатын кабатлау, истә калдыру.

2. Өй эшен — укучыларның монологларын тыңлау.

3. Б.Рәхмәтнең «Сабан туенда» дигән шигырен уку.

4. Сабан туенда нинди ярышлар була? Ярыш исемнәрен истә калдыру: тактага язу, тәрҗемә итү, җөмләләр төзү, рәсемнәр табу.

5. 5 нче бирем. Ярыш исемнәрен, биремдәге сүзләрне кулланып, Сабантуй турында кечкенә хикәя язу. (Авырсынган укучыларга өстәмә аңлатыла, тактада эшләнә.)

Өй эше: Язган хикәядән файдаланып, Сабантуй турында сөйләргә, рәсем ясарга.

## 66 нчы дәрес

**Тема:** Сабантуй — картиналарда.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — әдәбиятның рәсем сәнгате белән бәйләнешен күрсәтү.

Предмет — рәссам Л. Фәттахов, аның картинасы турында белү, сөйләм телен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — халыкның гореф-гадәтләренә, йолаларына ихтирам тәрбияләү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 112—113 нче битләр), эш дәфтәрендә 57, 58 нче битләр.

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, слайдлар: рәссам Л.Фәттахов портреты, аның картиналары, «Сабантуй» картинасыннан репродукция, Сабантуй күренешләре.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Укучыларның хәлләрен сорап, яхшы кәеф, уңышлар теләп, дәресне башлау.

***2. Актуальләштерү***

Алдагы дәреснең өй эшен тикшерү.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасыннан чыгып, укучылар белән бергә уку мәсьәләсе кую: Лотфулла Фәттаховның тормышы белән танышу, картиналарын белү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Лотфулла Фәттаховның тормыш юлы белән танышу. Тактада сораулар:

— Л.Фәттахов кем ул? Кайчан туган? Кайда туган? Гаиләләре зур булганмы? Балачагы нинди була? Нишләргә ярата? Кайчан Казанга килә? Казанда нишли? Кайда яши? Мәктәпне тәмамлагач нишли? Сугыш вакытында нишли? Картиналарында күбрәк нәрсәләр ясый?

112 нче биттәге биографик белешмәне мөстәкыйль укып, сорауларга җавап бирү.

Биография, иҗаты турында мәгълүматны тулыландырып, презентация карау, укытучы сөйләве.

2. «Сабантуй» картинасы белән эш.

1) Картинаны игътибар белән карау. Фикер алышу.

— Картинада нәрсә сурәтләнгән? Бу — елның кайсы вакыты? Һава торышы, көн нинди? Табигать, агачлар нинди? Кемнәр бар? Алар ничек киенгәннәр?

— Картинаның уртасында (алгы планда, арткы планда) нәрсә?

— Нинди ярыш сурәтләнгән? Ике бабай нишлиләр? Чирәмдә утыручылар нишлиләр? Рәссам нинди төсләр кулланган? Картинаны карагач, нинди уйлар туа?

— Картина Г.Бәширов әсәрендәге кайсы өлешкә туры килә? Б.Рәхмәт шигыренә туры киләме?

3. Парларда эшләү: картина буенча 5 сорау язып, диалог төзү.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Яңа мәгълүмат алдыгызмы?

2. Дәрескә гомуми бәя. Үзбәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: а) дәрестә язган диалогны өйрәнеп сөйләргә;

ә) эш дәфтәрендә сораулар төзеп язарга;

б) «Сабантуй» картинасы турында яки Л.Фәттахов турында кыскача сөйләргә.

## 67 нче дәрес

**Тема:** «Сабантуй» дигән журнал бар.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — командада эшләргә, проект эше башкарырга өйрәнү.

Предмет — «Сабантуй» журналы белән таныштыру, сөйләм телен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — татар телен өйрәнүгә кызыксыну булдыру, үзара сөйләшеп, күмәк эшләргә өйрәтү.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 114—115 нче битләр), эш дәфтәрендә 58, 59 нчы битләр.

**Җиһазлау:** «Сабантуй» газетасы, «Сабантуй» журналлары.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Уңай психологик халәт булдыру.

***2. Актуальләштерү***

Укучыларның әзерләгән диалогларын тыңлау.

***3. Уку мәсьәләсен кую***

Бүгенге дәреснең темасыннан чыгып, укучылар белән бергә уку мәсьәләсе кую. («Сабантуй» журналы белән танышу, аның нинди журнал, анда нәрсә турында язмалар басылуын белү.)

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. «Сабантуй» журналы, аның тарихы, әһәмияте турында укытучы сүзе.

2. Дәреслектәге мәгълүматны уку. Эчтәлеген аңлауны тикшерү өчен, сорауларга җавап бирү.

3. Һәр партага (төркемгә) берәр журнал бирелә. Журналга күзәтү ясау, танышу.

4. Төркемнәрнең сорауга җавап бирүләре:

— Журналның сездәге санында нинди темалар яктыртылган? Нинди рубрикалар бар? (Шулай даими рубрикалар күренә.) Иң кызык язма?

5. Журналның Интернеттагы сайтына күзәтү (дәрестә Интернетка тоташу мөмкин булмаса, алдан картина кебек күчереп алып, презентация күрсәтергә була).

6. Алдагы дәрескә өй эше — төркем белән бер санны презентацияләү (проект эше). Дәрес ахырында шул эшкә әзерлек: төркемнәрдә укучылар эшне планлаштыралар, бүлешәләр.

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: проект эше — «Сабантуй» журналына реклама (презентация) ясарга.

### Укытучы өчен өстәмә материал

**1923 ел.** Июнь аенда ялкынлы комсомол җитәкчесе Шәһит Шаммазов Казандагы Габдулла Тукай исемендәге балалар йортында татар балаларының егерме кешелек беренче пионер отрядын оештыра. Отряд «Яшь пионер» исемендәге кульязма газета чыгара башлый.

**1924 ел, 10 октябрь.** «Яшь ленинчы»ның беренче саны чыга. Аның тиражы 1500 данә була. Газетаның тәүге редакторы Шәһит Шаммазов булса, беренче хәбәрчеләр арасында Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Әмирхан Еники, Хатыйп Госман һ.б. була. Яшь хәбәрчеләрдән Мөхәммәт Садри, Зәки Нури, Шәрәф Мөдәррис, Гали Хуҗиев, Мәхмүт Хөсәен, Мифтах Вәдүт, Мансур Гаяз соңыннан күренекле язучылар булып китәләр.

**1930 елда** газетаның җаваплы секретаре булып Фатих Кәрим эшли.

**1941 елның 8 июлендә** «Яшь ленинчы»ның сугышка кадәрге соңгы саны чыга. Бөек Ватан сугышы башлангач, газета чыгуыннан вакытлыча туктап тора. Әмма, «Пионер бите» булып, «Кызыл Татарстан» газетасында яшәвен дәвам итә. «Яшь ленинчы»ны оештыручылар һәм аның актив авторлары — Ш.Шаммазов, Л.Гыйльми, Г.Хәбибуллин, Г.Мөхәммәтшин, М.Җәлил, Ф.Кәрим, А.Алиш һ.б. фронтка китәләр һәм яу кырында ятып калалар.

**1961 елның 1 гыйнварында** «Яшь ленинчы» кабат чыга башлый. Аның редакторы итеп Венера Ихсанова билгеләнә. 60 нчы еллар башында пионерлар «Муса Җәлил», «Ян Юдин», «Николай Зарубин» исемле теплоходлар төзү өчен тимер ватыклары җыялар. Операциянең башында «Яшь ленинчы» газетасы тора. «Әдәплелек мәктәбе», «Тапкырстан иле» рубрикалары барлыкка килә. «Лачын» операциясе игълан ителә. Газета халык бәхете өчен көрәшкән Татарстан улларын һәм кызларын эзләп табыша.

**1963 ел.** Балалар шагыйре Шәүкәт Галиев газета укучыларга үз героен — Шәвәлине тәкъдим итә.

**1967 ел.** «Бертуган галстуклар» рубрикасы чит ил пионерлары турында сөйли.

**1974 ел.** «Туган ягым — яшел бишек» операциясе үткәрелә. Әлеге башлангыч белән танылган әдип, СССР Дәүләт бүләге лауреаты Гомәр Бәширов чыга. Ул балаларны табигатьне яратырга, аны сакларга өйрәтә. Бу башлангыч киң катлау укучыларыбызда зур яклау таба. Укучылар «Кырмыска», «Чишмә» операцияләрендә катнашып, табигатькә «җан» өрәләр. Шушы эшләр өчен газета Бөтенроссия табигатьне саклау оешмасының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

**1977 ел.** «Яшь ленинчы» призына малайлар арасында спорт ярышлары үткәрелә башлый.

**1982 ел.** Газета Тынычлыкны саклау комитетының Почёт грамотасы белән бүләкләнә.

**1986 ел.** Газетаның баш редакторы — Р.Миңнуллин.

**1991 елдан** газета «Сабантуй» исеме белән чыга башлый. 1991 — 1994 елларда түбәндәге рубрикалар барлыкка килә: «Татарстан тарихы», «Иман», «Яшь егетләр, яшь кызлар», «Бишенче тәгәрмәч», «Татар мөгаллимнәре» һ.б. Бу — илдәге үзгәрешләр белән бергә газетага да заманча яңа рух үтеп керү белән бәйле.

**1994 елда** «Сабантуй» («Яшь ленинчы») газетасы 70 еллык юбилее уңаеннан һәм матбугат өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев Указы нигезендә, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Шушы елны «Безнең яраткан әдипләребез» рубрикасы астында, күренекле шәхесләребезгә багышлап, ике газета бите күләмендә махсус сәхифәләр чыга башлый.

**1995 ел.** Газетаның Шәвәли, Фәнсөяр исемле геройларына замана балалары — Шукбай һәм Сиринә өстәлә. Март аенда газетаның баш мөхәррире Р.Миңнуллин Татарстан Дәүләт Советының даими комиссиясе эшенә китә. Баш мөхәррир вазифаларын башкару газетаның җаваплы секретаре Ләлә Гыймадиевага тапшырыла.

**1996 ел.** Сентябрь аенда Якутиядә яшәүче математик якташларыбыз Марина һәм Ринат Мөстәкыймовларның «Мөстәкыймовлар олимпиадасы» бирелә башлый. Шул ук айда Татарстан Язучылар берлегенең Алиш премиясе булдырылуы турында игълан ителә, аның беренче лауреатлары газетаның редколлегия әгъзалары Шәүкәт Галиев һәм Ләбибә Ихсанова була.

**1998 ел.** Бу ел «Сабантуй» газетасы өчен Алиш елы дип игълан ителә. Сентябрь аенда газета татар балалар әдәбиятын үстерүдәге казанышлары өчен Татарстан Язучылар берлегенең Алиш премиясе белән бүләкләнә.

**2004 ел.** «Сабантуй» газетасының мөхәррире итеп Айдар Гыймадиев билгеләнә. (http://sabantuy.net сайтыннан)

## 68 нче дәрес

**Тема:** «Сабантуй» журналы бездә кунакта.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет — командада эшләргә, проектны якларга өйрәнү.

Предмет — «Сабантуй» журналы белән таныштыру, сөйләм телен үстерү.

Шәхескә кагылышлы — татар телен өйрәнүгә кызыксыну булдыру, үзара сөйләшеп, күмәк эшләргә өйрәнү, актив яшәү рәвешен пропагандалау.

**Материал:** дәреслек (2 нче кисәк, 114—115 нче битләр).

**Җиһазлау:** «Сабантуй» газетасы, «Сабантуй» журналлары.

### Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

***1. Дәресне оештыру***

Дәресне башлау. Уңай психологик халәт булдыру.

***2. Уку мәсьәләсен кую***

Өйдә әзерләгән реклама яки презентация белән сыйныфташлар алдында чыгыш ясау.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Төркемнәрнең чыгыш ясаулары. Башкалар тыңлый, сораулар бирә, бәяли.

2. Чыгышларга гомуми нәтиҗә ясау.

3. Журналга мәкалә язу. (Тема, форма ирекле.)

4. Әзер мәкаләләрне уку, анализлау. (Уңышлы мәкаләләрне редакциягә җибәрү.)

**III. Рефлексив бәяләү**

1. — Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

3. Өй эше: мәкаләне язып бетерергә.

## 69—70 нче дәресләр — йомгаклау, кабатлау яки резерв дәресләр

КУШЫМТА 1. **Бүлекне йомгаклау өчен тестлар**

**Халык авыз иҗаты (мифлар, мәкальләр, әйтемнәр)**

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| 1. Халык авыз иҗаты әсәрләренең авторы кем?<br>а) Язучы;<br>ә) халык;<br>б) су иясе;<br>в) шагыйрь.<br>2. Халык авыз иҗаты әсәрләрен кая язганнар?<br>а) Китапларга;<br>ә) язмаганнар;<br>б) телдән сөйләгәннәр.<br>3. Халык авыз иҗаты жанрларын гына билгеләгез.<br>а) Повесть;<br>ә) мәкаль;<br>б) миф;<br>в) әкият.<br>4. Татар мифларындагы Өй иясе рус мифларындагы нәрсәгә охшаган?<br>а) Водяной;<br>ә) леший;<br>б) домовой;<br>г) баба-яга.<br>5. Татар мифларындагы Су иясе нинди?<br>а) Ышанучан;<br>ә) белемле;<br>б) усал;<br>в) ялкау.<br>6. Акыл бирү, сөйләмне матурлау өчен кулланыла тор | 1. Бу юллар халык авыз иҗатының кайсы төренә карый? «Борын борын заманда яшәгән, ди, булган, ди бер ...»<br>а) Табышмак;<br>ә) әкият;<br>б) миф.<br>2. «Кем эшләми, шул ашамый» — бу нинди жанр?<br>а) Мәкаль;<br>ә) әйтем;<br>б) такмак.<br>3. Мифлар ул —<br>а) кешеләрнең дөньяны башкача (фантастик) аңлавы, күзаллавы, фантастик образлар турында хикәят;<br>ә) сүз сәнгатенең халык тарафыннан иҗат ителгән, телдән-телгә күчеп йөри һәм саклана торган әсәрләр җыелмасы.<br>4. Су иясе сүзенең синонимын табыгыз:<br>а) Су кызы;<br>ә) Су анасы;<br>б) Су атасы.<br>5. Халык авыз иҗаты жанры гына булган рәтне билгеләгез:<br>а) Мәкаль, әйтем, әкият;<br>ә) хикәя, роман, такмак;<br>б) җыр, хикәя, табышмак. |

| | |
|---|---|
| ган кыска, тирән мәгънәле халык авыз иҗаты әсәрләре:<br>а) Әкият;<br>ә) миф;<br>б) әйтем ;<br>в) мәкаль.<br>7. Мәкальләрнең һәм әйтемнәрнең авторы кем?<br>а) Балалар;<br>ә) укытучы;<br>б) халык;<br>в) шагыйрь.<br>8. «Тәмле дә тел, тәмсез дә тел» — бу кайсы жанрга карый?<br>а) Мәкаль;<br>ә) әйтем;<br>б) табышмак.<br>9. «Җылы сөяк сындырмый» — бу кайсы жанрга карый?<br>а) Мәкаль;<br>ә) әйтем;<br>б) табышмак.<br>10. 2 мәкаль һәм 2 әйтем языгыз. | 6. Халык авыз иҗатына кермәгән сүзләр рәтен билгеләгез:<br>а) җыр, табышмак, роман;<br>ә) хикәя, роман, әйтем;<br>б) повесть, роман, шигырь.<br>7. Мәкальләрнең авторын билгеләгез.<br>а) Халык;<br>ә) язучылар;<br>б) шагыйрьләр.<br>8. Мәкальләрнең билгеләмәсен күрсәтегез.<br>а) Акыл бирү, сөйләмне матурлау өчен, тирән мәгънәле халык авыз иҗаты;<br>ә) Элек-электән килгән, ныклап урнашкан гореф-гадәт;<br>б) Сүзләре дә, көе дә халык тарафыннан иҗат ителгән.<br>9. Мифларны өйрәнеп, китап чыгарган язучы:<br>а) М.Җәлил;<br>ә) Ш.Галиев;<br>б) Г.Гыйльман.<br>10. 2 мәкаль һәм 2 әйтем языгыз. |

## Халык җырлары

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| 1. Халык җырлары төренә кергән рәтне билгеләгез.<br>а) Йола җырлары, лирик җырлар, романслар;<br>ә) тарихи җырлар, уен җырлары, йола җырлары; | 1. Г.Тукайның «Туган тел» җырына кем көй язган?<br>а) Фәрит Яруллин;<br>ә) Алмаз Монасыйпов;<br>б) халык. |

| | |
|---|---|
| б) такмаклар, йола<br>җырлары, опера җырлары.<br>2. Сөмбелә бәйрәме ул —<br>а) татар халкының йола<br>бәйрәме;<br>ә) рус халкының йола<br>бәйрәме;<br>б) чуваш халкының йола<br>бәйрәме.<br>3. «Кәрия-Зәкәрия» җыры<br>ул —<br>а) тарихи җыр;<br>ә) уен җыры;<br>б) йола җыры.<br>4. Г.Тукайның<br>«Туган авыл» җырына<br>көй иҗат иткән<br>композитор кем?<br>а) Рөстәм Яхин;<br>ә) Фәрит Яруллин;<br>б) Алмаз Монасыйпов.<br>5. «Туган тел» җыры<br>сүзләренең авторын<br>билгеләгез:<br>а) Габдулла Тукай;<br>ә) халык;<br>б) Муса Җәлил.<br>6. Рәшит Ваһапов кем ул?<br>а) Композитор;<br>ә) язучы;<br>б) җырчы.<br>7. Гимн ул —<br>а) тантаналы җыр,<br>дәүләт символы;<br>ә) тарихи җыр;<br>б) халык җыры.<br>8. «Минем яраткан<br>җырчым» дигән темага<br>җөмләләр языгыз. | 2. Рәшит Ваһапов кем ул?<br>а) Композитор;<br>ә) язучы;<br>б) җырчы.<br>3. «Әпипә» җыры ул —<br>а) тарихи җыр;<br>ә) йола җыры;<br>б) уен җыры;<br>в) бию такмагы.<br>4. «Көзге ачы җилләрдә»<br>җырының авторын билгеләгез:<br>а) Халык;<br>ә) Муса Җәлил;<br>б) Габдулла Тукай.<br>5. Халык җырлары жанрына<br>кергән рәтне билгеләгез:<br>а) тарихи җырлар,<br>уен җырлары,<br>йола җырлары;<br>ә) йола җырлары,<br>лирик җырлар,<br>романслар;<br>б) такмаклар,<br>йола җырлары,<br>опера җырлары.<br>6. Чуклеме бәйрәме ул —<br>а) рус халкының йола бәйрәме;<br>ә) чуваш халкының йола бәйрәме;<br>б) татар халкының йола бәйрәме;<br>7. Татарстан Республикасы<br>Дәүләт гимнының<br>авторларын билгеләгез:<br>а) Рөстәм Яхин,<br>Рамазан Байтимеров;<br>ә) Салих Сәйдәшев,<br>Габдулла Тукай;<br>б) халык.<br>8. «Минем яраткан җырчым»<br>дигән темага җөмләләр языгыз. |

## Кадерле син, Кеше туганым!

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| 1. Н.Исәнбәт<br>«Өч матур сүз» шигырендә нинди сүзләр турында әйтә?<br>а) Бәхет, дуслык, мәхәббәт;<br>ә) Әткәем, әнкәем, илкәем;<br>б) туган авыл, туган тел, туган туфрак.<br>2. Кайсы мәсәл кайсы язучыныкы?<br>а) М.Гафури 1) «Ат белән Эт»;<br>ә) И.Крылов 2) «Әтәч белән Сандугач»;<br>б) Г.Шамуков 3) «Арыслан белән Куян».<br>3. М.Гафуриның «Ана» шигыре<br>а) ананың баласын яратуы турында;<br>ә) ананың баласына уенчыклар алуы турында;<br>б) баланың анага булышуы турында.<br>4. Г.Тукай Шүрәлене<br>а) үзе уйлап тапкан;<br>ә) әзер мифны гына алып язган;<br>б) халык мифларындагы Шүрәлегә яңа сюжет уйлап тапкан.<br>5. «Шүрәле» балетының авторларын табыгыз.<br>а) Фәрит Яруллин 1) балетны сәхнәгә куя;<br>ә) Леонид Якобсон 2) көй яза;<br>б) Әхмәт Фәйзи 3) либретто яза.<br>6. М.Җәлил сугышта кем буларак катнаша?<br>а) Хәрби хәбәрче;<br>ә) укчы-радист;<br>б) редактор. | 1. М.Җәлил «Чәчәкләр» шигыре белән нәрсә әйтергә тели?<br>а) Чәчәкләрнең матурлыгын;<br>ә) батырларның үлемсезлеге;<br>б) чәчәкләрне өзмәскә кирәклекне.<br>2. Һәр әсәрдә вакыйга кайда бара?<br>а) «Туган туфрак» 1) Кырлай;<br>ә) «Шүрәле» 2) ишегалды;<br>б) «Әтәч белән Сандугач» 3) Каракош.<br>3. «Туган туфрак» хикәясе<br>а) табигать матурлыгы турында;<br>ә) туган җир кадере турында;<br>б) эти-әнигә ярдәм итү турында.<br>4. «Шүрәле» балетын сәхнәгә кем куя?<br>а) Леонид Якобсон;<br>ә) Фәрит Яруллин;<br>б) Габдулла Тукай.<br>5. «Шүрәле» балетының геройлары<br>а) Шүрәле, Клара, Былтыр;<br>ә) егет, Сөембикә, Шүрәле;<br>б) Сөембикә, Шүрәле, Фәрит.<br>6. Әхмәт Фәйзи кем ул?<br>а) «Шүрәле» балетына көй язучы;<br>ә) «Шүрәле» балетына либретто язучы;<br>б) «Шүрәле» балетына биюләр куючы.<br>7. М. Җәлил «Моабит дәфтәрләре» өчен<br>а) Ленин премиясенә лаек була;<br>ә) Советлар Союзы Герое исеменә лаек була;<br>б) күп акча ала.<br>8. М.Җәлил кайчан һәлак була?<br>а) 1945 елда;<br>ә) 1944 елда;<br>б) 1942 елда. |

| | |
|---|---|
| 7. М.Җәлилнең шигырьләр җыентыгы ни өчен «Моабит дәфтәре» дип атала?<br>а) Шул исемдәге шигырь бар;<br>ә) төрмә исеменнән;<br>б) шәһәр исеме.<br>8. М.Җәлил «Чәчәкләр» шигырен кайчан яза?<br>а) 1941 елда;<br>ә) 1943 елда;<br>б) 1945 елда.<br>9. Ә.Еники «Туган туфрак» хикәясендә нинди авыл турында яза?<br>а) Корысаз;<br>ә) Каракош;<br>б) Коркачык.<br>10. Ә.Еники — ул<br>а) шагыйрь;<br>ә) язучы;<br>б) драматург.<br>11. «Туган туфрак» хикәясендәге ялгызлык исемнәр:<br>а) Клара 1) йортны алган кеше;<br>ә) Хисами 2) тау исеме;<br>б) Чабылтау 3) бабайның оныгы, төп герой. | 9. М.Гафури әсәрләре генә язылган рәтне табыгыз:<br>а) «Туган авыл», «Ана»;<br>ә) «Әтәч белән Сандугач», «Ат белән Эт»;<br>б) «Әтәч белән Сандугач», «Ана».<br>10. Н.Исәнбәтнең «Өч матур сүз» шигыре нәрсә турында?<br>а) Матур кызлар турында;<br>ә) әти-әни, туган ил турында;<br>б) саннар турында.<br>11. Әсәрләрнең авторларын табыгыз.<br>а) Ә.Еники 1) «Әтәч белән Сандугач»;<br>ә) М.Җәлил 2) «Туган туфрак»;<br>б) М.Гафури 3) «Өч матур сүз»;<br>в) Н.Исәнбәт 4) «Чәчәкләр». |

## Энҗе карлар явып үткән...

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| 1. Г.Ибраһимов кайда туган?<br>а) Татарстанда;<br>ә) Башкортстанда;<br>б) Түбән Новгородта.<br>2. Т. Миңнуллин — кем ул?<br>а) Драматург | 1. Р.Вәлиева кайда туган?<br>а) Татарстанда;<br>ә) Башкортстанда;<br>б) Түбән Новгородта.<br>2. Т. Миңнуллин Мәскәүдә кайда укыган?<br>а) Театр училищесында; |

| | |
|---|---|
| ә) шагыйрь;<br>б) җырчы.<br>3. Чаңгы ярышында җиңгән аю турында кайсы шигырьдә язылган?<br>а) «Кечкенә чыршы»;<br>ә) «Минем кунагым»;<br>б) «Кызыклы хәл».<br>4. Кем Татарстан Дәүләт Советы депутаты иде?<br>а) Т.Миңнуллин;<br>ә) Г.Ибраһимов;<br>б) К.Нәҗми.<br>5. Яңа ел бәйрәменә нәрсә кирәк түгел?<br>а) Чыршы;<br>ә) Кыш бабай бүләкләре;<br>б) чаңгы.<br>6. Кайсы җөмлә кыш турында түгел?<br>а) Елгалар боз астына качты;<br>ә) Күктә кояш кыздырды;<br>б) Агачлар ак мамыкка төренде.<br>7. Кар турында сыйфатлар языгыз.<br>8. Әниегезгә Яңа ел котлавы языгыз. | ә) музыка училищесында;<br>б) педагогия училищесында.<br>3. Кайсы шигырьдә чыршыларны сакларга кирәклеге турында әйтелә?<br>а) «Кечкенә чыршы»;<br>ә) «Чыршының күлмәкләре»;<br>б) «Кызыклы хәл».<br>4. Кем күп еллар редактор булып эшли?<br>а) М.Фәйзуллина;<br>ә) К.Нәҗми;<br>б) Р.Вәлиева.<br>5. Яңа елда өстәлдә нәрсә булмый?<br>а) Ит;<br>ә) карбыз;<br>б) икмәк.<br>6. Кайсы җөмлә кар турында?<br>а) Елгалар боз астына качты;<br>ә) Күктә кояш кыздырды;<br>б) Агачлар ак мамыкка төренде.<br>7. Кыш турында сыйфатлар языгыз.<br>8. Дустыгызга Яңа ел котлавы языгыз. |

**Акыл — тузмас кием, белем — корымас кое**

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| 1. «Әбүгалисина» әсәрен кем язган?<br>а) Абдулла Алиш;<br>ә) Каюм Насыйри;<br>б) Фәнис Яруллин.<br>2. Габделхәй Сабитовның «Чүкеч» хикәясендә төп герой<br>а) Бакый; | 1. Абдулла Алиш кем ул?<br>а) Рәссам;<br>ә) балалар язучысы;<br>б) шагыйрь.<br>2. «Бердәнбер» шигыренең авторы<br>а) Фәнис Яруллин; |

ә) Барый;
б) Борис.
3. Гөлшат Зәйнашева кем ул?
а) Композитор;
ә) шагыйрә;
б) җырчы;
4. «Бердәнбер» шигыренең авторы
а) Фәнис Яруллин;
ә) Абдулла Алиш;
б) Равил Фәйзуллин.
5. «Аны музыкага укытырга, пианинода уйнарга өйрәтергә кирәк. Музыка мәктәбенә әзерләргә кирәк!» Бу өзек кайсы әсәрдән алынган?
а) Абдулла Алишның, «Әни ялга киткәч»;
ә) Мәгъсүм Латыйфуллинның, «Сәйдәшнең юл башы»;
б) Каюм Насыйриның, «Әбүгалисина».
6. Күп белергә теләп, мәгарә эчендә бер ел буе китап укып утыручы малайлар кайсы әсәр геройлары?
а) Мәгъсүм Латыйфуллинның «Сәйдәшнең юл башы»;
ә) Каюм Насыйриның «Әбүгалисина»;
б) Габделхәй Сабитовның «Чүкеч».
7. Абдулла Алиш кем ул?
а) Балалар язучысы;
ә) шагыйрь;
б) рәссам.
8. Бу әсәрләрнең кайсын притча дип атап була?
а) Гәбделхәй Сабитовның «Чүкеч» әсәре;
ә) Абдулла Алиш;
б) Равил Фәйзуллин.
3. Бакый — кайсы әсәрнең төп герое?
а) «Бердәнбер» шигыре;
ә) «Кояштагы тап» хикәясе;
б) «Чүкеч» хикәясе.
4. Әбүгалисина нәрсәләр эшләгән?
а) Егеткә булышкан, балалар укыткан;
ә) патшага булышкан, мунча төзегән;
б) патша кызына өйләнгән.
5. «Совет Армиясе маршы»н кем язган?
а) Рөстәм Яхин;
ә) Салих Сәйдәшев;
б) Нәҗип Җиһанов.
6. Салих Сәйдәшев кем ул?
а) Композитор;
ә) җырчы;
б) шагыйрь.
7. «Бик яхшы иткәнсең. Эшең безгә булса, өйрәнүең — үзеңә.» җөмләсе кайсы әсәрдән?
а) Каюм Насыйриның, «Әбүгалисина»;
ә) Абдулла Алишның, «Әни ялга киткәч»;
б) Габделхәй Сабитовның, «Чүкеч».
8. Дидактик-аллегорик характердагы гыйбрәтле кечкенә хикәя — ул:
а) Хикәя;
ә) экият;
б) притча.
9. К.Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре нинди жанрга керә?
а) Хикәя;
ә) экият;
б) кыйсса.

| | |
|---|---|
| ә) Гөлшат Зәйнашеваның<br>«Кем булырга?» әсәре;<br>б) Фәнис Яруллинның<br>«Кояштагы тап» әсәре.<br>9. «Эчтәлеген гадәттән<br>тыш кызыклы хәлләр,<br>төрле гыйбрәтле<br>*(поучительные)* вакыйгалар<br>тәшкил итә.<br>Аның нигезенә билгеле миф,<br>сюжет салына.» Бу<br>а) кыйсса;<br>ә) притча;<br>б) хикәя.<br>10. «Совет Армиясе<br>маршы»н кем язган?<br>а) Салих Сәйдәшев;<br>ә) Рөстәм Яхин;<br>б) Нәҗип Җиһанов. | 10. Бөтен эшне үзе эшләргә<br>өйрәнгән малай кайсы әсәр герое?<br>а) Габделхәй Сабитовның,<br>«Чүкеч»;<br>ә) Мәгъсүм Латыйфуллинның,<br>«Сәйдәшнең юл башы»;<br>б) Каюм Насыйриның<br>«Әбүгалисина». |

## Илдә илле дустың булсын

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| 1. Шагыйрь Дәрдемәнднең<br>чын исеме:<br>а) Сәгыйть Дәрдиев;<br>ә) Закир Рәмиев;<br>б) Мәхмүт Шакиров.<br>2. «Мокамай» поэмасында<br>Мокамай кем ул?<br>а) Автор үзе;<br>ә) авторның дусты;<br>б) авторның абыйсы.<br>3. «Серле алан» әсәре нәрсә<br>турында?<br>а) Җирдә тынычлык өчен<br>һәр кеше җаваплы;<br>ә) дусның кем икәнен<br>белергә кирәк;<br>б) барлык милләтләр<br>дус яшәргә тиеш. | 1. Мокамайның<br>чын исеме:<br>а) Мөхәммәтҗан;<br>ә) Мөхәммәтшакир;<br>б) Мөхәммәтһади.<br>2. «Серле алан»<br>әсәрендә уяулык<br>символы:<br>а) шарлар;<br>ә) малайлар;<br>б) Ябалак.<br>3. Алтын приискалары<br>булган шагыйрь:<br>а) Һади Такташ;<br>ә) Шәүкәт Галиев;<br>б) Дәрдемәнд.<br>4. Бу геройлар турында язган<br>авторларны билгеләгез: |

| | |
|---|---|
| 4. «Дуслык балы» шигырендә кайсы ике милләт вәкиле катнаша?<br>а) Рус белән татар;<br>ә) татар белән башкорт;<br>б) татар белән чуваш.<br>5. Әсәрләрнең авторларын күрсәтегез.<br>а) Дәрдемәнд 1) «Дуслык балы»;<br>ә) Ш.Галиев 2) «Дуслык, чын дуслык!»;<br>б) Р.Харис 3) «Ике туган»;<br>в) Э.Шәрифуллина 4 ) «Мокамай»;<br>г) Һ.Такташ 5) «Серле алан».<br>6. Әсәрләрнең төп геройларын күрсәтегез:<br>а) Мөхәммәтҗан 1) «Серле алан»;<br>ә) Әтәч, Тавык 2) «Дуслык балы»;<br>б) Барый, Нарый 3) «Мокамай»;<br>в) Татар, башкорт кешесе 4) «Ике туган».<br>7. Үзегезгә ошаган бер әсәр турында сорауларга җаваплар языгыз.<br>а) Сезгә нинди әсәр ошады?<br>ә) Аны кем язган?<br>б) Вакыйга кайда бара?<br>в) Анда төп геройлар кемнәр?<br>г) Алар нинди?<br>д) Алар нишлиләр?<br>е) Бу әсәр ни өчен ошады?<br>ё) Язучы нәрсә турында әйтергә тели? | а) Барый, Нарый 1) Һ.Такташ;<br>ә) Әтәч, Тавык 2) Ш.Галиев;<br>б) Мөхәммәтҗан 3) Дәрдемәнд;<br>в) Татар, башкорт кешесе 4) Р.Харис.<br>5. 2 малайның урмандагы маҗаралары турында әсәр:<br>а) «Мокамай»;<br>ә) «Серле алан»;<br>б) «Дуслык балы»;<br>в) «Дуслык, чын дуслык».<br>6. Укыган әсәрләрнең жанрын күрсәтегез:<br>а) «Ике туган» 1) шигырь;<br>ә) «Мокамай» 2) пьеса;<br>б) «Серле алан» 3) хикәя;<br>в) «Дуслык балы» 4) поэма.<br>7. Үзегезгә ошаган бер әсәр турында сорауларга җаваплар языгыз.<br>а) Сезгә нинди әсәр ошады?<br>ә) Аны кем язган?<br>б) Вакыйга кайда бара?<br>в) Анда төп геройлар кемнәр?<br>г) Алар нинди?<br>д) Алар нишлиләр?<br>е) Бу әсәр ни өчен ошады?<br>ё) Язучы нәрсә турында әйтергә тели? |

**Көлке көлә килә...**

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| 1. Кайсы шигырь Ш.Галиевнеке түгел?<br>а) «Курыкма, тимим!»;<br>ә) «Атлап чыктым Иделне»;<br>б) «Урман аланына баргач» | 1. Кайсы шигырьне Н.Мадьяров язган?<br>а) «Курыкма, тимим!»;<br>ә) «Атлап чыктым Иделне»;<br>б) «Урман аланына баргач». |

| | |
|---|---|
| 2. Урманда нишләргә ярамый?<br>а) Җәнлекләрне куркытырга;<br>ә) кошларны ашатырга;<br>б) җиләк җыярга.<br>3. Марат — кайсы әсәрнең төп герое?<br>а) «Курыкма, тимим!»;<br>ә) «Ике тиен акча»;<br>б) «Урман аланына баргач».<br>4. Диңгезче булган язучы:<br>а) В.Радлов;<br>ә) Ф.Шәфигуллин;<br>б) Ш.Галиев.<br>5. Малай Акбай белән Карабайны кайдан алып кайта?<br>а) Урман аланыннан;<br>ә) тау башыннан;<br>б) елга буеннан.<br>6. Әсәрләрнең авторларын күрсәтегез:<br>а) «Курыкма, тимим!» 1) Ф.Шәфигуллин<br>ә) «Ике тиен акча» 2) В.Радлов<br>б) «Шаян кеше» 3) Ш.Галиев<br>7. «Аннары малайлар да, кызлар да, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, шауларга, гөжләргә керештеләр» җөмләсе кайсы әсәрдән?<br>а) «Шаян кеше»;<br>ә) «Ике тиен акча»;<br>б) «Урман аланына баргач».<br>8. Бер әсәр турында җөмләләр төзеп языгыз. | 2. Урманда нишләргә ярый?<br>а) Гөмбә җыярга;<br>ә) агачларны сындырырга;<br>б) җәнлекләргә тияргә.<br>3. Кайсы әсәрдә аю авылга килгән?<br>а) «Курыкма, тимим!»;<br>ә) «Ике тиен акча»;<br>б) «Урман аланына баргач».<br>4. Татар мәктәпләре инспекторы булган галим:<br>а) В.Радлов;<br>ә) Ф.Шәфигуллин;<br>б) Ш.Галиев.<br>5. Акбай белән Карабайның кайчан дуслыклары бетә?<br>а) Кар яугач;<br>ә) малай алып кайткач;<br>б) көзгедә үзләрен күргәч.<br>6. Әсәрләрнең төп геройларын күрсәтегез:<br>а) «Курыкма, тимим!» 1) юлчы;<br>ә) «Шаян кеше» 2) малай;<br>б) «Акбай белән Карабай» 3) көчекләр.<br>7. «Аннары ул күз чите белән генә классташларына карап алды: Мөршидә апа гына түгел, бөтен класс аннан җавап көтә иде» җөмләсе кайсы әсәрдән?<br>а) «Шаян кеше»;<br>ә) «Ике тиен акча»;<br>б) «Урман аланына баргач».<br>8. Бер әсәр турында җөмләләр төзеп языгыз. |

**Һәр фасылың гүзәл, табигать**

| I вариант | II вариант |
|---|---|
| 1. Роберт Әхмәтҗанов кем ул?<br>а) Шагыйрь;<br>ә) язучы;<br>б) рәссам.<br>2. Гәрәй Рәхимнең «Апрель» хикәясе нәрсә турында?<br>а) Яз турында;<br>ә) апрель ае турында;<br>б) әнисе турында.<br>3. Гомәр Бәширов кем ул?<br>а) Халык язучысы;<br>ә) халык җырчысы;<br>б) халык шагыйре.<br>4. «Туган ягым яшел бишек» әсәрен кем язган?<br>а) Роберт Әхмәтҗанов;<br>ә) Гомәр Бәширов;<br>б) Гәрәй Рәхим.<br>5. Сабантуйга охшаган чуваш бәйрәме —<br>а) Сабан туе;<br>ә) Чуклеме;<br>б) Агатуй.<br>6. Сабан туеның төп ярышы —<br>а) ат чабышы;<br>ә) көрәш;<br>б) капчык киеп йөгерү.<br>7. «Сабантуй» картинасының авторы кем?<br>а) Бакый Урманче;<br>ә) Харис Якупов;<br>б) Лотфулла Фәттахов.<br>8. «Әдәби әсәрдәге табигать тасвиры, вакыйгалар сурәтләнгән урындагы реаль шартлар.» Бу — нәрсә? | 1. «Язгы сабан туйлары» әсәрендә көрәшче егет:<br>а) Галимҗан;<br>ә) Хәкимҗан;<br>б) Әхәт.<br>2. Җәйге иртә, бал кортлары турындагы шигырьнең авторы<br>а) Роберт Әхмәтҗанов;<br>ә) Гомәр Бәширов;<br>б) Гәрәй Рәхим.<br>3. Лотфулла Фәттахов кем ул?<br>а) Рәссам;<br>ә) җырчы;<br>б) композитор.<br>4. «Геройның тышкы кыяфәтен сурәтләү үзенчәлеге.» Бу — нәрсә?<br>а) Пейзаж;<br>ә) портрет;<br>б) хикәяләү.<br>5. Хәзер Сабантуй кайчан үткәрелә?<br>а) Яз җиткәч;<br>ә) чәчү эшләре беткәч;<br>б) кар эрегәч.<br>6. Кайсы ярыш Сабантуйда булмый?<br>а) Көрәш;<br>ә) ат чабышы;<br>б) урындык күтәреп йөгерү.<br>7. Г.Бәширов кайда туган?<br>а) Казанда;<br>ә) Башкортстанда;<br>б) Арча районында.<br>8. Кем киносценарийлар язган?<br>а) Гәрәй Рәхим;<br>ә) Гомәр Бәширов;<br>б) Лотфулла Фәттахов. |

| | |
|---|---|
| а) Пейзаж;<br>ә) портрет;<br>б) хикәяләү.<br>9. «Сабантуй» балалар журналы турында җөмләләр языгыз. | 9. «Сабантуй» балалар журналы турында җөмләләр языгыз. |

## ТЕСТЛАРНЫҢ ҖАВАПЛАРЫ

| | Халык авыз иҗаты | | Халык җырлары | |
|---|---|---|---|---|
| | I вариант | II вариант | I вариант | II вариант |
| 1 | ә | ә | ә | ә |
| 2 | б | а | а | б |
| 3 | ә, б, в | а | ә | б |
| 4 | б | ә | б | а |
| 5 | а,б | а | а | а |
| 6 | в | б | б | ә |
| 7 | б | а | а | а |
| 8 | а | а | | |
| 9 | ә | б | | |

| | Кадерле син, Кеше туганым! | | Энҗе карлар явып үткән... | | Акыл – тузмас кием, белем – корымас кое | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | I вариант | II вариант | I вариант | II вариант | I вариант | II вариант |
| 1 | ә | ә | ә | ә | ә | ә |
| 2 | а – 2, ә – 1, б – 3 | а – 3, ә – 1, б – 2 | а | а | а | б |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | а | ә | б | ә | ә | б |
| 4 | б | а | а | б | б | а |
| 5 | а – 2, ә – 1, б – 3 | ә | б | ә | ә | ә |
| 6 | а | ә | ә | б | ә | а |
| 7 | ә | а | | | а | ә |
| 8 | ә | ә | | | б | б |
| 9 | ә | б | | | а | б |
| 10 | ә | ә | | | а | ә |
| 11 | а – 3, ә – 1, б – 2 | а – 2, ә – 4, б – 1, в – 3 | | | | |

| | Илдә илле дустың булсын | | Көлке көлә килә... | | Һәр фасылың гүзәл, табигать! | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | I вариант | II вариант | I вариант | II вариант | I вариант | II вари-ант |
| 1 | ә | а | б | б | а | б |
| 2 | ә | б | а | а | б | а |
| 3 | а | б | ә | ә | а | а |
| 4 | ә | ә | ә | ә | ә | ә |
| 5 | а – 3, ә – 1, б – 5, в – 2, г – 4 | а – 4, ә –3, б –1, в – 2 | ә | ә | б | ә |
| 6 | а – 3, ә – 4, б – 1, в – 2 | а –3, ә – 4, б – 2, в – 1 | а – 3, ә – 1, б –2 | а – 3, ә –1, б –2 | ә | б |
| 7 | | | ә | ә | б | б |
| 8 | | | | | а | а |

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. *Аминева В.Р.* Типы диалогических отношений между национальными литературами (на материале произведений русских писателей второй пол. XIX в. и татарских прозаиков первой трети XX в.) / В.Р.Аминева. — Казань: Казан. ун-т, 2010. — 474 с.

2. *Амирханов Р.У.* Татарский народ и Татарстан в начале XX века: Исторические зарисовки / Р.У.Амирханов. — Казань: Татар.кн.изд-во, 2005. — 152 с.

3. *Арсланов М.Г.* Тылсым. Татар театры: режиссёрлар һәм драматурглар / М.Г.Арсланов. — Казан: Мәгариф, 2008. — 287 бит: фот.б-н.

4. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. — Казан: Мәгариф, 2007. — 231 б.

5. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда / төз. Р.Н.Даутов, Р.Н.Рахмани. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. — Т.I. — 751 б.; Т.II. — 735 б.

6. *Әминев А.Г., Әдһәмова Г.М.* Урта мәктәптә әдәбият укыту методикасы / А.Г.Әминев. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1977.

7. *Әминев А.Г., Сайкин Ш.Р.* V—VII классларда әдәбият укыту методикасы /А.Г.Әминев, Ш.Р.Сайкин. — Казан: Татар.кит. нәшр., 1965.

8. Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе: Шигырьләр һәм поэмалар. [Төз. һәм кереш сүз авт. Р.Х.Хәйбрахманов]. — Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшр. (ТаРИХ), 2005. — 416 б.

9. *Галимуллин Ф.Г.* Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү / Ф.Г.Галимуллин. — Казан, 1988.

10. *Гилязов А.М.* Три аршина земли; В пятницу вечером; [Сост. анал. ст. М.М.Хабутдиновой]. — Казань: Магариф, 2008. — 295 с.

11. *Гыйзәтуллина Э.Х.* Рус телле балаларгататар теле укытуда коммуникатив технологиянең уңышлы алымы буларак проектлар методы. Сборник тезисов Республиканской заочной научно-практической конференции педагогических идей и решений «Модернизация образования: вызовы времени» —Казань: Отечество, 2013.

12. *Еники Ә.* Сайланма әсәрләр / [Төз. һәм кереш сүз авт. Ә.Р.Мотыйгуллина]. — Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшр. (ТаРИХ), 2002. — 416 б.

13. *Есин А.Б.* Принципы и приёмы анализа литературного произведения: Учебное пособие. — 8-е изд. / А.Б.Есин. — М.: Флинта: Наука, 2007. — 248 с.

14. *Җамалетдинов Л.* Әкиятләр // Фольклор жанрларын анализлау. — Казан, 1986.

15. *Җамалиева Л.Ф.* Фольклорда уртаклык мәсьәләләре: Татар, башкорт һәм чуваш халык җырлары мисалында. Уку ярдәмлеге / Л.Ф.Җамалиева. — Казан: Алма-Лит, 2003.

16. *Җамалиева Л.Ф.* Татар фольклорчылары: методик кулланма / Л.Ф.Җамалиева. — Казан: ТДГПУ, 2009.

17. *Закирҗанов Ә.М.* Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре: Укытучылар өчен методик кулланма / Ә.М. Закирҗанов. — Казан: Мастер Лайн, 1997.

18. *Закирҗанов Ә.М.* Яңарыш юлыннан / Ә.М.Закирҗанов. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2008. — 303 бит.

19. *Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. — Казан: Казан университеты, 2011. — Т.I: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. — 230 б.; Т.II: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. — 198 б.

20. *Заһидуллина Д.Ф., Әминова В.Р., Ибраһимов М.И.* Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз: урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф.Заһидуллина, В.Р.Әминова, М.И.Ибраһимов. — Казан, 2007. — 112 б.

21. *Заһидуллина Д.Ф.* Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Метод. кулланма / Д.Ф. Заһидуллина. — Казан: Мәгариф, 2004.

22. *Исламов Ф.Ф.* Мәктәптә халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү /Ф.Ф. Исламов. — Казан, 1988.

23. *Исмәгыйлева С.Г.* Мәктәптә драма әсәрләрен өйрәнү / С.Г. Исмәгыйлова. — Казан, 1983.

24. *Исмәгыйлева С.Г.* IV—VIII классларда лирик әсәрләрне өйрәнү / Сания Исмәгыйлева. — Казан: 1985.

25. *Курбатов Х.Р.* Шигырь энҗеләре ничек барлыкка килә?/ Х.Р. Курбатов. — Казан: Фикер, 2002.

26. *Кутуй А.Н.* Неотосланные письма: повести, стихотворение в прозе; [сост. анал. ст. М.М.Хабутдиновой]. — Казань: Татар. кн.изд-во, — 216 с.

27. *Леонов С.А.* Речевая деятельность на уроках литературы в старших классах: Методические приёмы творческого изучения литературы: Методическое пособие / С.А.Леонов. — М.: Флинта: Наука, 1999.

28. *Лотфи Г.Ф., Сайкин Ш.Р.* Әдәби уку методикасы: V—VII классларда әдәбият укытучылар өчен кулланма. /Г.Ф.Лотфи, Ш.Р.Сайкин. — Казан: Таткнигоиздат, 1956.

29. Методика преподавания литературы: Учебник для студентов пед. вузов / Богданова О.Ю., Леонов С.А., Чертов В.Ф.; Под ред. О.Ю.Богдановой / О.Ю.Богданова, С.А.Леонов, В.Ф.Чертов — М.: Издательский дом «Академия», 1999. — 400 с.

30. *Мещеряков В.Н.* Жанры школьных сочинений: Теория и практика написания: Учебно-методическое пособие для студентов и учителей-словесников / М.Н.Мещеряков. — М.: Флинта: Наука, 1999.

31. *Мещерикова М.И.* Литература в таблицах и схемах / М.И.Мещерякова. — М.: Рольф, 2000. — 224 с. — (Домашний репетитор).

32. *Мухаметшина Р.Ф.* Изучение литературы в аспекте диалога культур / Р.Ф.Мухаметшина. — Казань, 2006. — 116 с.

33. *Мухаметншина Р.Ф.* Диалог русской и татарской культур в системе литературного образования: На материале школ Республики Татарстан / Р.Ф.Мухаметшина. — Казань: РИЦ «Школа», 2006. — 248 с.

34. *Нигъмәтуллин Ә.З.* Урта мәктәптә татар әдәбиятын өйрәнүнең фәнни-методик нигезләре / Ә.З. Нигъмәтуллин. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1983.

35. *Поварисов С.* Мәктәптә әдәби әсәрнең телен өйрәнү /С.Поварисов. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1978.

36. *Поварисов С.* Сүз һәм сәнгатьле сөйләм. Укытучылар, укучылар, студентлар, аспирантлар, язучылар һәм журналистлар өчен теоретик-методик кулланма./С.Поварисов. — Уфа: Башкортстан «Китап» нәшр., 1997. — 224 б.

37. Примерные программы по учебным предметам. Литература. 5—9 классы: проект. — М.: Просвещение, 2010. — 176 с. — (Стандарты второго поколения).

38. *Пропп В.Я.* Исторические корни волшебной сказки / В.Я.Пропп. — Л., 1946.

39. *Прыгунова Е.Н., Пазумова И.А.* Преподавание фольклора в редней школе. — Санкт-Петербург: «Паритет», 2001.

40. *Рәми И.* Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек) / И.Рәми, Р.Даутов. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. — 399 б.

41. *Романчева Е.С.* Введение в методику обучения литературе: учеб. пособие / Е.С.Романичева, И.В.Сосновская. — М.: ФЛИНТА: Наука, 2012. — С.14—34.

42. Рус телендә урта (тулы) белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1—11 нче с-лар [басма өчен Ч.М.Харисова, К.С.Фәтхуллова, З.Н.Хәбибуллина җаваплы] — Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. — 239 б.

43. Сынап карау программалары (авторлары Р.Х.Хәйдәрова, М.И.Малафеева; Ә.Р.Мотыйгуллина, И.М.Ибраһимова). — Казан: Мәгариф, 2003.

44. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Н.М.Йосыпова. — Казан: Мәгариф, 2006. — 319 б.

45. Татар театры (1906-1926). — Тулыландырылган 2 нче басма. — Казан: Мәгариф, 2003. — 308 бит.

46. Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр / Төз. Л.Җамалетдинов. — Казан, 1994.

47. Технологии и теория обучения литературе: учеб. пособие / под.ред В.А.Кохановой. — М: ФЛИНТА: Наука, 2011. — С.11–32.

48. *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек / Ф.И.Урманче. — Казан: Мәгариф, 2002.

49. *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты / Ф.И.Урманче. — Казан: Мәгариф, 2005. — 383 б.

50. Федеральный закон об образовании в Российской Федерации № 273-ФЗ от 29.12.2012. — Ростов н/Д., 2013. — 208 с.

51. *Фёдоров А.А.* Введение в теорию и историю культуры: Словарь / А.А.Фёдоров. — Уфа: Гилем, 2003. — 320 с.

52. Формирование универсальных учебных действий в основной школе: от действия к мысли. Система заданий: пособие для учителя/ [А.Г.Асмолов, Г.В.Бурменская, И.А.Володарская и др.]; под ред. А.Г.Асмолова. — 2-е изд. — М.: Просвещение, 2011. — 159 с.

53. *Хаков В.Х.* Мәктәптә язучыларның тел үзенчәлекләрен өйрәнү / В.Х.Хаков. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1984.

54. *Ханнанов Р.Г.* Төрки драматургия контекстында татар сәхнә әдәбияты (XIX гасыр ахыры — XX йөз башы) / Р.Г.Ханнанов. — Казан: ТДГПУ, 2010. — 193 б.

55. *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма.

— Тулыландырылган икенче басма / Ф.М.Хатипов. — Казан: Раннур, 2002. — 352 бит.

56. *Хәсәнова Ф.Ф.* Шагыйрь һәм заман / Ф.Ф.Хәсәнова. — Казан: Школа, 2010. — 296 бит.

57. *Хөсни Ф.* Сайланма әсәрләр / [Төз. һәм кереш сүз авт. Ә.Р.Мотыйгуллина]. — Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшр. (ТаРИХ), 2002. — 447 б.

58. *Черкезова М.В.* Проблемы преподавания русской литературы в инокультурной среде: методическое пособие / М.В.Черкезова. — М.: Дрофа, 2007.

59. *Эскальнек А.Я.* Основы литературоведения. Анализ художественного произведения: Практикум / А.Я.Эскальнек. — М.: Флинта: Наука, 2003.

60. *Яхин А.Г.* Әдәбият дәресләре: Укытучылар, югары уку йортлары студентлары, укучылар өчен методик кулланма / А.Г.Яхин. — Казан: Мәгариф, 2003.

61. *Яхин А.Г.* Система татарского фольклора / А.Г.Яхин. — Набережные Челны: НИСПТР, 2012. — 286 с.

Учебное издание

**Мотигуллина** Альфия Рухулловна
**Ханнанов** Рамиль Гумарович
**Гизатуллина** Эндже Хабировна
**Мифтахутдинова** Альфия Захраповна

**ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА**

Методическое пособие для преподавателей общеобразовательных организаций
основного общего образования с обучением на русском языке
(для изучающих татарский язык)

**6** класс

Казань. Издательство «Магариф — Вакыт». 2014
*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Мотыйгуллина** Әлфия Рухулловна
**Ханнанов** Рамил Гомәрович
**Гыйзәтуллина** Энҗе Хәбировна
**Мифтахетдинова** Әлфия Захраповна

**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ**

Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында
(татар телен өйрәнүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен7 нче сыйныф

**6** нчы сыйныф

Редакторы *Н.К. Нотфуллина*
Тышлык рәссамы *Д.Л. Нәүрүзова*
Оригиналларны компьютерда эшкәртүче һәм
компьютерда биткә салучы *Э.Ф. Нурмөхәммәтова*
Корректоры *М.З. Вәлиева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.08.2014.
Форматы $60 \times 84^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Прагматика» гарнитурасы.
Шартлы басма табагы 11,0. Тиражы 1000 д. Заказ

«Мәгариф — Вакыт» нәшрияты http: magarif-vakyt.ru, e-mail: valeevmx@mail.ru

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленного
электронного оригинал-макета в типографии филиала ОАО «ТАТМЕДИА»
«ПИК «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.
E-mail: idelpress@mail.ru